# Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 27 (1392) 15 июль 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

12

Ни аяныч, милләт азатлыгы өчен көрәшкән Бәхтияр Канкай батырны хәтта туган ягында да белүче юк дәрәҗәсендә.

14

Галәмгә очкан беренче космонавт – Юрий Гагаринның Җиргә төшкәч иешеткән беренче сүзе «Бисмилла» була.

18

Татарстанның кечкенә авылында туып-үскән Галимҗан Хөсәенов атаклы Мәскәү командасын лаеклы җитәкли.

# Һәрбер халык бәйрәм уйлап тапкан, Саклар өчен милли асылын!

## БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Иртәгә, 16 июль көнне, Ростов-Дон шәһәрендә узачак Көньяк Сабан туенда Актаныш районының «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле катнаша.

- Башкортстанның Дүртөйле районы Түбән Аташ авылында танылган композитор, популяр җырлар авторы Мөфтәдин Гыйләҗев музее ачылды.

- Татарстан һәм Россиянең халык артисты Рәшит Кәлимуллин кабат Россия композиторлар берлеге идарәсе рәисе итеп сайланды.

- «Казан утлары» китапханәсе сериясендә Лилия Гыйбадуллинаның «Рәкыйп Хәмитов. Копчёный» китабы басылып чыкты.

- Теләчедә «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе «Алмаш» дип исемләнгән яңа сериал төшерә башлады.

- Казанның «Инеш» ансамбле Удмуртиянең Шаркан районында узган «Быг-быг» фин-угор кухнясы фестивалендә катнашты.

- Дәүләт Думасында КПРФ фракциясе җитәкчесе, Казанга эш сәфәре белән килгән Геннадий Зюганов Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка «СССР төзелүнең йөз еллыгын билгеләп үтү йөзеннән» истәлек медален һәм истәлекле тәңкәсен тапшырды.

- Казанда Татарстан Фотографлар берлегенең «Сфера» галереясы ачылды.

- Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясында Б.Урманче исемендәге премия номинантларының әсәрләреннән күргәзмә эшли башлады.

### ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

**Рөстәм ЯМАЛИЕВ, Мәскәү татарлары һәм төрки халыклары милли конгрессы президенты җитәкчесе:**

***«Сабан туеның хәзерге вакытта әһәмияте йөзләгән тапкыр арта. Безнең шундый мәшәкатьле вакытыбыз. Халыкларны, диннәрне берләштерергә кирәк вакытта җитәкчеләр халык арасында. Сабан туе рухны күтәрә, берләштерә, киләчәккә өмет уята. Бу – безнең төп бәйрәм. Татар телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау өчен идеология рычагы ул».***

### СЫНАМЫШЛАР

Болыт килгәндә этәч кычкырса – көн аязырга ● Төш вакытында салават күпере чыкса, көн бозыла ● 21 июльгә кара җиләк өлгерсә, уракка төшәргә була ● Кура җиләге күп булса, арыш уңа ● Сорыкортлар, безелдәшеп, һавада бөтерелсә, аяз көннәр саклана ● Кич өрәңге яфракларында ябышкак сок чыкса, озакламый яңгыр ява ● Кичтән томан төшсә, көн аяза һәм җылыта.

### КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 19 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 18 минутта** офык артына күмелачәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 59 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **21 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **22 июльдә 16 сәгать 38 минут** тәшкил итәчәк.

### БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

**15 июль** – очучы, Советлар Союзы Герое Мәгубә Хөсәен кызы Сыртланованың тууына 110 ел (1912–1971).

**16 июль** – баянчы, Татарстанның халык артисты Рамил Сөләйман улы Курамшинга 75 яшь (1947);

– композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илһам Илгиз улы Байтирәккә 55 яшь (1967).

**17 июль** – драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәдиф Нәҗип улы Сәгъдиевкә 65 яшь (1957).

**20 июль** – Казан сәүдәгәре, иганәче Салих Сабит улы Гобәйдуллинның тууына 160 ел (1862–1935).

**20 июль** – балалар язучысы Алмаз Марс улы Гыймадиевка 50 яшь (1972).

### СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июльнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(13-20 июль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

### ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

**Бүген зөлхиҗҗә аеның 16 нчы көне**

## ҖАН АВАЗЫ

**Илгизәр ЗӘКИЕВ**

# «Гаиләдә» дип алданмыйк!

Философларны меңнәрчә ел борчыган сорау бар. Ул аңнымы, яшәешнеңме беренчел булуын ачыклаудан гыйбарәт. Яшәеш (бу очракта фәлсәфәдә вөҗүд дигән термин кулланырга яраталар) аңны билгели, аңның нигезендә ята дигән фикерне яклаучылар бихисап. Әйе, монда мантыйк бар. Маугли кебек, социумнан тыш туган балалар бик чикләнгән аңга ия. Хайваннар дөньясы кагыйдәләре өстенлек итә торган, үсештә артта калган илләрдәге кешеләрдә дә шулай. Ә уңышлы тирәлектә булганда, кеше үз-үзен башкаларның уңышын үзенә сеңдерә, кызыксынып, үзе дә уңышлырак, тырышрак була бара. Бала үзе яшәгән җәмгыятьнең нигез принципларын, фикерләрен, тормышка карашын, нормаларын кабул итә. Аңның яшәешне билгеләгән очраклары да юк түгел анысы. Әйтик, ниндидер эчкече гаиләдә туып-үскән бала мәктәпне яхшы тәмамлап, югары уку йортында укый, галим, эшмәкәр яки оста табиб була. Димәк, ул үз аңын эшкә җигеп, яшәешне үзгәрткән. Ләкин, килешәсезме, андыйлар бармак белән генә санарлык. Шуңа күрә бу карашны яклаган галимнәр шактый аз.

Татар телен саклау мәсьәләсе соңгы елларда философлар баш ваткан сорауга турыдан-туры бәйләнә башлады кебек. Җәмгыятьтә карашлар нәкъ ике төрле лагерьга бүленә. Аларның беренчесе яшәешнең аң нигезендә ятуын яклый, ягъни телнең саклануы һәм үсеше өчен, беренче чиратта, аны куллану даирәсе, ана телен укыту һәм ана телендә белем алу кирәклеген алгы планга куя. Икенче төркем исә боларны, әйтерсең, борынгы заман галәмәте итеп күрә һәм туган тел гаиләдә өйрәнелергә тиеш дип тәкрарларга маташа. Янәсе, балачакта гаиләдә өйрәнгәч, кеше үзенең татар икәнен аңлап, гомер буе туган телендә сөйләшергә омтылачак, чит җирләргә китсә дә, татарлыгын җуймаячак. Менә шул икенче төркемнең фикере көннән-көн популярлаштырыла бара, чөнки ул зур-зур җитәкчеләр чыгышында еш яңгырый. Хәтта совет заманындагы вәзгыятьне үз сүзләрен раслау өчен үрнәк итеп тә китерәләр. Имеш, ул чорда Казанда татар телендә укыта торган бер генә мәктәп эшләп калган, аңа карап кына башкалада тел үлмәгән, чөнки гаиләдә әти-әниләр татарча сөйләшкән. Хәтта үзен үрнәк итеп китерүчеләр дә бар: «Мин рус мәктәбендә укыдым, тик өйдә гел татарча сөйләшкәч, телне онытмадым». Ләкин сез туган телегезне нинди дәрәҗәдә беләсез соң? Университетта үз фәненнән имтиханда өчледән югары билге куймый торган профессор турында ишеткәнегез бардыр. «Бишлелек итеп, ягъни иң югары дәрәҗәдә барысын да Алла гына белә. Мин, профессор, дүртлелек беләм. Димәк, сез, студентлар, әлегә өчледән артык югары күтәрелә алмыйсыз», – дип әйтә торган булган ул. Рус мәктәбендә укып, гаиләдә татар телен ипи-тозлык үзләштергән әфәнде татарча тартып-сузып өчле куяр дәрәҗәдә сукалый. Ә ул балаларына нәрсә өйрәтеп калдыра ала? Күп дигәндә, икеле куярлык (берле түгел) итеп! Рус мәктәбендә укып тәрбияләнгән урта буын хәзерге интернет, социаль челтәрләр заманында татар классик әдәбиятын укып үзен камилләштерәчәк дисезме?! Татар әдипләре һәм шагыйрьләреннән Тукай, Такташны һәм исемнәре урамнарга бирелгән тагын бер-ике кешене генә атый ала алар. Аның каруы, почмак саен бөек Тукай дип сөйләргә тартынмыйлар.

Шәһәрләрдә, район үзәкләрендә рус мәктәбен (русча укыткан мәктәпне) тәмамлаган тулы бер буын тулысынча диярлек маңкорт рухлы итеп тәрбияләнде. Нәкъ менә шундыйлар милли телләрнең кирәксезлеге өчен чәчрәп чыгып чыгыш ясый, нәкъ менә шундыйлар балаларын, яхшырак җиһазландырылган дигән сылтау белән, зуррак рус мәктәбенә илтеп бирә, нәкъ менә шундыйлар, «мәктәптә татар телен укыту сәбәпле рус теленә зыян китерәләр», дип шикаятьләр сырлый.

Совет чоры белән хәзергене чагыштыруның хатасы җәмгыятьтәге вәзгыятьне, хәзерге заман тенденцияләрен исәпкә алмаудан да гыйбарәт. Бүген балага зур мәгълүмат ташкыны агыла. Социаль челтәрләрдән, ватсап, телеграм ише мессенджерлардан һәм тагын әллә кайлардан ташып торган рус телендә дистәләрчә гигабайтлы мәгълүмат кешегә татарча суларга да урын калдырмый. Тәүлегенә 24 сәгать эшләп торган мультфильм каналлары, көнбатыш киноларының тәэсирен чыгарып ташлап булмый. Иң нәни тамашачы психологиясен исәпкә алып ясалган мультфильмнар бала аңына аеруча тиз йогынты ясый. Әти-әни белән татарча сөйләшү өчен, тәүлектә берничә минут вакыт табыла микән?! Менә шушы шартларда гаиләдә камил рәвештә татар теленә өйрәтү турында сүз йөртү мөмкинме? Гаилә хәзерге заманда һичничек тә тел мохите була алмый.

90 нчы елларда татар телен мәктәпләргә кайтару чорында Казанда, Чаллыда бер-бер артлы гуманитар юнәлешле милли гимназияләр ачылды. Аларның үз милләте өчен тугрылыклы, телгә, әдәбиятка хөрмәтле шәхесләр тәрбияләүдә роле зур булды. Дөрес, бу гимназияләрдә күп фәннәр барыбер ярым русча, ярым татарча укытылды. 90 нчы еллар ахыры, 2000 еллар башында ул мәктәпләр-гимназияләрнең күбесе төгәл предметларны бөтенләй русча укытуга күчеп бетте. Ә физика, математика, хокук, медицина һәм башка бик күп юнәлешләрне сайлаган югары уку йортында инде егетләрне-кызларны тулысынча русча дәресләр каршы алды. Шунлыктан тел-әдәбиятны шактый тирәнтен үзләштергән хәлдә дә, бу егетләрнең-кызларның фикер сөреше хәзер русча бара. Моның аермачык мисалын күптән түгел Г.Камал театры күрсәтте. «Яңа татар пьесасы» конкурсында җиңгән «Сагынырсызмы?..» әсәрен Алабугада татар гимназиясен тәмамлаган, аннары юридик белем алган Артур Шәйдуллин иҗат иткән. Тик спектакльнең башыннан ахырына кадәр аның «русча» икәнлеге сизелеп тора. Рус телендәге калыплашкан гыйбарәләрнең калька тәрҗемәләре, татар колагына ятышсыз җөмләләр тулып ята. Бу спектакльнең тегеннән-моннан чәленгән эчтәлегенә, темасына кагылмыйк. Анысы – икенче мәсьәлә. Тамашаның рус интернет-басмаларында мактап телгә алынуын аның русча бик анык, аңлаешлы, матур яңгыравы белән дә бәйле икән ләбаса. Өстәвенә, Камал театрында хәзер башкалада, район үзәкләрендә туып-үскән тулы бер буын тупланды. Алар чынлыкта әнә шундый «ватык» телне дөрес, чын татар теле дип кабул итә дә. Телне гаиләдә тәрбияләүнең нинди нәтиҗәгә китергәнен менә хәзер әдәбиятта да, хәтта театрда да күрәбез.

Ләкин тагын да аянычы киләчәктә булачак. Моның сәбәбе бик гади. Хәзерге татар әдәбиятында Р.Галиуллин, Р.Мөхәммәтшин, Г.Батталова, Л.Гыйбадуллина, Ф.Гыйләҗев кебек матур, асыл татар телендә иҗат итүче буын бар. Алар барысы да диярлек авыл-район мәктәпләрендә татарча укыган, татарча фикерле. Ә 2000 еллардан соң фәннәрнең бөтен республикада диярлек русча укытылуын искә алсак, тел байлыгы, татарча җөмлә төзелеше (!) белән сокландыра торган язучылар башка булмаячак дигән сүз. Быел татар теленнән республика имтиханын Татарстанда нибары бер кыз – Балтач районы Норма урта мәктәбе укучысы Әдилә Шәйхетдинова гына тапшырганын да өстәсәк, вәзгыять тагын да аныграк аңлашыла төшәр.

Татар телен саклау эшендәге тагын бик зур алдану аны балалар бакчасында гына сеңдерергә тырышудан гыйбарәт. Әлеге караш бакчаларда татар төркемнәре оештырып, сабыйларны кече яшьтән үк татар мохитендә тәрбияләүне күздә тота. Күптән түгел узган татар теле укытучылары җыенында Татарстан мәгариф министры Илсур Һадиуллин да чыгышында «алтыда белгән ана телен алтмышта да онытмас» дигән мәкальне искә алды. Ләкин югарыда әйтеп үткән мәгълүмат ташкыны аркасында балалар бакчасында бераз татарча сукалый башлаган сабый башлангыч сыйныфларда ук русчага күчә. Икенчедән, Казанда балалар бакчаларында чын татар (татарча тәрбия, татарча дәресләр бирә торган) төркемен санап чыгар өчен бер кул бармаклары җитәчәк. Кәгазьдә алар бихисап.

**(Дәвамы 4 нче биттә).**

Җидегән — вакыйгалар, хәбәрләр, яңалыклар

# ТӘШВИШЛЕ КИЛӘЧӘК

Киләчәкне планлаштыруга караш төрлечә. Аны файдасыз гамәл, диючеләр дә күп. Рус халкында хәтта «Хочешь рассмешить Бога – расскажи Ему о своих планах» дигән әйтем дә бар. Иҗтимагый аңдагы мондый аерма, күрәсең, татарда диннең иҗтиһади-тәүхиди асылын ментал дәрәҗәдә тою-сиземләүдән дә килә. Ихтимал, шуңадыр, бүгенге чынбарлык һәм глобаль колачлы төп тенденцияләрдән чыгып, алдагыны кайгырту һәм киләчәкне ничектер фараз кылырга омтылу да безнең менталитетка күбрәк туры килә. Чөнки андый гөманлау инде, аның нәтиҗәсе кешенең фанилыктагы төп вазифасына (Җир хуҗасы булуга) җавап бирмәгән очракта, адәми затка иҗтиһат капкаларын киңрәк ачып гамәл кылу, булган хаталардан арыну һәм бөтен егәрен үзенең Җирдәге миссиясен үтәүгә юнәлдерү мөмкинлеге дә бирә.

Ә нинди соң ул билгесез киләчәк? Кешелекне алда ниләр көтә? Моңа анык җавап әлегә булмаса да, танырга кирәктер, кешелек тарихында бу хактагы гөман кылуларга һәм алдан күрүләргә кытлык юк: изге китаплардагы ачылышлардан һәм урта гасырлардагы күрәзәчеләрдән (Нострадамус, Раньо Неро һ.б.) башлап, һәртөрле идея вә концепцияләр (либерализм, тоталитаризм, коммунизм һ.б.) һәм бүгенге көннең геосәяси проектларына («Зур Европа», «Глобаль Британия», «Бөек Кытай хыялы», «Зур Евразия» һ.б.) кадәр – һәммәсе дә киләчәкне кайгыртып эшләнгән һәм эшләнә. Изге китаплардагы ачылышлар һәм күрәзәчеләр әйткәнне, «колакларыннан тартып», төрле юллар белән үз өстенлеге вә җиңүенә юраган шарлатаннар да җитәрлек. Бу җәһәттән, сизелә ки, иҗтимагый аңны сәяси максатларга яраклы үзгәртүдә аерым илләрнең махсус органнары да читтә калмый. Бәгъзеләр исә Җирдәге барлык проблемаларны яңа технологик тормыш урнаштырып кына да хәл итмәкче. Кыскасы, аныклык әлегә бик булмаса да, кешелек үз киләчәгенә битараф түгел кебек. Әмма хак юл күренми һәм, ни гаҗәп, төп сораулар да җавапсыз кала килә.

Ә киләчәкне конкрет елларга бүлеп фараз кылуда игътибарны янә «күкләр сәясәте» («небополитика») тарафдарлары (алар үзләрен шулай атый) ясаган нәтиҗәләр җәлеп итә. Изге язмаларда әйтелгәннәргә таянып һәм «Ахырзаман алышы» («Битва Конца») инде 2001 елда ук башланды дигән фикергә килеп (ә иң кызыклысы - галимнәрнең 2040 еллар тирәсендә дөнья хуҗалыгы NBIC-конвергенциянең җиденче укладына күчәчәген фараз кылуын да исәпкә алып) алар инсаниятнең Җирдә яңа яшәү принцибына күчү вакыты 2040 еллардан башланыр, дигән нәтиҗә ясый. Ул гына түгел, әлеге «замана күрәзәчеләре» хәтта аңа кадәрге вакыт аралыгын да конкретлаштырырга җөрьәт итә. Алар фаразынча, 2027-2035 елларда кешелек дөньясы икегә бүленәчәк һәм, бөтендөнья «кан вә туфрак» режимының G2 төркеме рәвешендә үзара килешенеп, якынча 8 ел чамасы кыен шартларда яшәргә мәҗбүр булачак. Бу чорда глобаль кризистан чыгу процессы энерготехнологик инновацияләргә, 6 нчы технологик укладның когнитив (аналоглы) һәм креатив (цифрлы) өлешләренә бүленүгә һәм биш геосәяси көч үзәге формалашуына китерәчәк, имеш. Менә алар: Кытай империясе (үзәк); Евразия Берлеге (көнчыгыш); Ислам Хәлифәлеге (көньяк); Атлантик конфедерация (католик дөнья халыкларының «папа империясе» – көнбатыш); Төньяк расаның ак халыклар альянсы (WASP – төньяк). Тагын 6 ел (2035-2041) - «хәйләле акыл»ның мотлак рухсыз һәм үтә дә материалистик патшалыгы чоры. Шуннан соң инде, 2041-2044 елларда Дәҗҗал (Антихрист) хакимлеге урнашуы белән, Көнбатышның кояшы сүреләчәк һәм «яңа күк йөзе вә яңа җир» дөреслегенә антропологик борылыш башланачак икән. Мәдәниятләр һәм дини тәгълиматлар синтезының ошбу планетар борылышына Россиянең көчле держава булып (күрәсең, ниндидер могҗиза белән) киләчәге дә әйтелә.

Әлбәттә, мондый «алдан күрү», күбрәк, кофе куесында багуны хәтерләтә. Киләчәк исә андый шөбһәдән тагы да тәшвишлерәк булып күренә. Әмма кеше үз язмышына битараф кала алмый, ул хакыйкатькә, гадел яшәешкә омтыла. Илаһи миссияле милләт буларак, зур җаваплылык бу җәһәттән татарга да йөкләнә. Бүгенге кыен хәлләрдән чыгу һәм кешелек киләчәгеннән ышанычлы итү өчен ул нәрсә эшләргә тиеш соң? Насыйп булса, бу һәм башка мөһим мәсьәләләр турында сүзебезне инде киләсе язмаларда дәвам итәрбез.

**Фоат УРАЗАЙ.**

## Төмәнәккә сынчылар җыелды

Туймазы районы Төмәнәк авылында «Бабай утары» этнографик музей комплексында икенче тапкыр сынлы сәнгать сөючеләрнең «Бабай утары-2022» агач сынчылар фестивале үз эшен башлап җибәрде. Анда Башкортстаннан, Татарстаннан, Оренбург өлкәләреннән килгән 12 сынчы үзләренең көчен сынап карый. Татар халык әкиятләре, бәет персонажларыннан торган сыннар киләчәктә «Бабай утары» музей комплексының төрле почмакларында урын алачак.

## «Исәнмесез!» бүләк алды

Режиссер Илдар Ягъфәровның «Исәнмесез!» тулы метражлы фильмы Псковта узган «Западные ворота» III Халыкара кинофестивалендә җиңде.

Ягъфәров кинокартинасы халыкара конкурста төп призны «Вертолет» якут фильмы һәм Кыргызстаннан «Дорога в Эдем» фильмнары белән бүлеште. Жюри рәисе, танылган режиссер Владимир Хотиненко әйтүенчә, жюри бер генә картинаны аерып чыгара алмаган, шуңа күрә өч конкурсантка тигез бәя бирергә карар кылынган. В.Хотиненкодан тыш, фильмнарны РФ халык артисты Александр Лазарев, оператор Сергей Астахов һәм кино белгече Михаил Трофименков билгеләгән.

«Исәнмесез!» киносы бу көннәрдә Алтайда Шукшин фестивалендә катнаша.

Кино сәнгате өлкәсеннән тагын бер сөенечле яңалык. Татарстан фильмнары Казан кинофестиваленең барлык номинацияләренә дә кертелде.

Нина Кочеляева җитәкчелегендәге XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең сайлап алу комиссиясе «Милли конкурс» номинациясе фильмнары исемлеген игълан итте.

Сайлап алу комиссиясе әгъзасы Тимур Шәйхуллин сүзләренә караганда, комиссия әгъзалары арасында фильмнар сайлаганда, Татарстан кинокартиналарын конкурс программасына яки милли программага кертү буенча дискуссия чыккан.

Биш номинациянең һәркайсына Татарстан фильмын кертү турында коллегиаль карар кабул ителгән. Аерым алганда, Төркия, Иран, Һиндстанда төшерелгән һәм башка тулы метражлы кинолентадар белән берррәттән «Тарлан» фильмы тәкъдим ителде.

«Кыска метражлы уен фильмы», «Документаль кыска метражлы фильм» һәм «Документаль тулы метражлы фильм» номинацияләрендә Татарстан кинематографиясе Рифат Миндубаевның «Галиябану», Марсель Мәхмүтовның «Габдрахман» һәм Булат Минкинның «Сосновый ключ» эшләре белән катнаша.

Казан кинофестиваленең конкурс программасы һәр номинациядә 10 фильмнан тора. Быел дөньяның 44 иленнән барлыгы 625 гариза теркәлгән.

## Бишбалтага сәяхәт

Борынгы татар бистәсе – Бишбалтаның тарихи әһәмиятенә игътибар җәлеп итү өчен, Ачык университет һәм Бөтендөнья татар яшьләре форумы бистә һәм аның зиратлы буйлап экскурсия оештырды.

Экскурсияне тарих фәннәре кандидаты Айрат Фәйзрахманов һәм Казанны өйрәнүче, журналист Рәдиф Кашапов алып барды.

Сәфәр Столяров исемендәге парктан башланды. Алга таба экскурсия маршруты Бишбалта осталары һәйкәле, «Серп и молот» заводы, Бишбалта мәчете, 15 нче татар гимназиясе, Балыкчы яки Тиволи бакчасы, Шамил Тарпищевның теннис академиясе, 2 нче Бишбалта һәйкәле, Алафузовлар мирасы, Бишбалта бистәсе урамнары һәм тарихи мәчет урыны, Бишбалта зиратында дәвам итте.

Бишбалта бистәсе Хәсән Туфан, Һади Такташ, Гадел Кутуй исемнәре белән дә билгеле. Бирендә шулай ук Сара Садыйкованың бабасының йорты да сакланган.

Бишбалта бистәсендә тарихи-туристик комплекс ясау кирәклеген журналист Ленар Гобәйдуллин белдерде. «Башка кешеләргә, татарның үзенә күрсәтер өчен тарихи комплекс булдырырга кирәк. Музей эшләп куярга, мәчетләргә истәлек такталары куярга, туристик маршрутка кертергә була», – диде ул.

**Әнҗе ГАБДУЛЛИНА.**

## Татар галимен онытмыйлар

Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев Кыргызстан Республикасына эш сәфәре белән барды. Бишкәк шәһәрендә танылган галим, биология фәннәре докторы, профессор, Кыргызстан Республикасы Фәннәр академиясе әгъзасы Әнвәр Гәрәевкә стела ачылды. Тантаналы чарада Кыргызстан Республикасы Хөкүмәте рәисе урынбасары Эдиль Байсалов, Бишкәк шәһәре мэры Эмилбәк Абдыкадыров, «Туган тел» татар-башкорт мәдәни үзәге җитәкчесе Гөлсинә Үлмәскулова, галимнәр, депутатлар һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты.

Васил Шәйхразиев, тантанага җыелучыларны сәламләп, татар галименең исемен мәңгеләштергән, Ә. Гәрәев хезмәтләрен югары бәяләгән өчен республика җитәкчелегенә рәхмәт белдерде. Э.Байсалов үз чыгышында Ә.Гәрәевнең эшләре һәм исеме киләчәктә дә онытылмаячак дип белдерде.

Танылган галим тумышы белән Татарстаннан. 1936 елда ул Краснодар авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, Кыргызстанга күчеп китә. Кыргызстанда үзе җитәкләгән лаборатория хезмәткәрләре белән берлектә, күптөрле җимеш агачлары, чәчәкләр һәм башка төр үсемлекләрнең 5500 төрен уйлап таба.

Кыргызстан шартларында мул уңыш бирә торган алма, груша, абрикос һәм башка җиләк-җимешнең 7 мең төрдәге фондын булдыра. Зур әзләнүләр алып барып, 100 дән артык хезмәт яза. Кыргызстанда Әнвәр Гәрәевнең күпьеллык эшчәнлеген югары бәяләп, ул җитәкләгән Ботаника бакчасына галим исеме бирелә.

**1 нче биттә** – Әлки районының Сихтермә-Хузангай авылында узган «Уяв» чуаш мәдәнияте бәйрәменнән бер күренеш. Фото: president.tatarstan.ru

# Йолаларга бай «Уяв»

Әлки районының Сихтермә-Хузангай авылында чуаш мәдәниятенең «Уяв» милли республика бәйрәме узды.

Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, КПРФ партиясе Үзәк Комитеты рәисе Геннадий Зюганов, Чуашия Республикасы башлыгы Олег Николаев, Ульяновск өлкәсе губернаторы Алексей Русских, Татарстанның Чуаш милли-мәдәни автономиясе рәисе Дмитрий Самаренкин һ.б. дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре төп кунаклар булды.

Рөстәм Миңнеханов «Уяв» бәйрәменә чуаш милли киеменнән килде. Ул кунакларны рус, татар һәм чуаш телендә сәламләде.

«Әлеге бәйрәмнең традицияләре безнең алда үз тамырлары белән еракларга китүче үзенчәлекле чуаш мәдәниятенең зур дөньясын ача. Уяв русларның – Каравон, татарларның – Сабан туе, удмуртларның – Гырон-Быдтон, мариларның – Семык, мордваларның Валда Шинясь бәйрәмнәре белән бер үк дәрәҗәдә республикабызның мәдәни брендына әверелде!» – дип белдерде ТР Президенты.

Бәйрәм кунаклары чуаш халкының борынгыдан килгән туй, хәрби хезмәткә озату, кичке җыен, сабыйга исем кушу кебек йолалары белән танышты.

Мәйданчыкларның берсендә Сихтермә-Хузангай авылында, кендек анасы буларак, яңа туган сабыйларга исем кушу йоласын кылучы Алмапике Григорьева йоланың үзенчәлекләре, бүген чуаш яшьләренең сабыйларына кушу өчен нинди исемнәргә өстенлек бирүе, чын чуаш исемнәренең югалып баруы турында сөйләде.

Бүгенге көндә кендек анасы бала тудыру процессында катнашмый, әмма йола буенча яңа туган сабыйга исем кушу бәйрәменә чакырыла, дип аңлатты Григорьева.

«Нәселдәге иң өлкән зат (еш очракта авылга бер яки берничә сабыйларга исем кушучы кендек анасы була) сабыйны кулларына ала, баланың телен бал һәм май белән буйый һәм Тура Алласына баш иеп дога кыла. Моннан соң сабыйның ата-анасы балага сайланган исемне атый. Кендек анасы догалар кыла-кыла балага әлеге исемне куша», – дип сөйләделәр кунакларга. Алар чуаш халкының борынгыдан килгән йоласы – «Уяв» бәйрәме иртәсендә табигый көчләрдән мул уңыш сорап яңгыр чакыру йоласының шаһите булды.

Чуаш йолалары буенча, «Уяв» бәйрәме иртәсендә, таң белән башлау белән, яланда җыелып яңгыр чакыралар. Иртәнге сәгать өчләр тирәсендә яланга чыгып, күмәкләшеп зур казанда яңгыр боткасы пешерәләр. «Кагыйдә буларак, һәр авылда билгеле бер карчык – им-томнар укып, җаен-рәтен белеп ботканы пешерүче бар. Гадәттә, бу –авылның иң өлкән, иң тәҗрибәле, иң төпле карчыгы», – дип аңлатты йоланы оештыручылар.

Быел яңгыр боткасын Сихтермә-Хузангай авылының иң өлкән кешесе – 81 яшьлек Галина Альмукова пешергән. Аның оныгы – Илиана Альмукова бәйрәм кунакларын әлеге ботка белән сыйлады һәм яңгыр чакыру йоласының үзенчәлекләре, яңгыр боткасын пешерү нечкәлекләре хакында сөйләде.

Йола үтәлгәннән соң чуаш халкы көн дәвамында Уявны бәйрәм итә һәм, әлбәттә, табигый көчләрнең яңгыр яудырачагына ышана. «Бу көн гадәттәгечә һәр ел саен бик әссе булып килә. Ә кичен, чуаш халкын куандырып, гаҗәеп рәвештә яңгыр коеп ява», – дип сөйләде оештыручылар.

# Очучыга һәйкәл куелды

9 июльдә легендар очучы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәевнең туууына 100 ел тулды. Бу уңайдан Геройның кече ватаны – Башкортстан Республикасы Илеш районының Югары Яркәй һәм Ташчишмә авылларында тантаналы чаралар узды.

Югары Яркәйдә Муса Гәрәев музее территориясендә һәйкәл ачылды. Тантаналы чарада Башкортстанның Дәүләт Җыены – Корылтае рәисе Константин Толкачев, район хакимияте башлыгы Илдар Мостафин, РФ Дәүләт Думасы депутаты Рафаэль Мәрданшин һ.б. катнашты.

Геройга һәйкәл муниципалитетның хәйрия фонды хисабына ясалды. Таш сынның авторы – Магнитогорск шәһәреннән Сергей Елкин.

Уфадагы Республика Хәрби дан музеендә очучының 100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган «Башкортстан лачыны» дигән күргәзмә ачылды, анда мактаулы кунаклар чакырылган иде. Алар арасында М. Гәрәевнең хатыны Светлана һәм улы Евгений булды.

Күргәзмә 17 октябрьгә кадәр эшләячәк.

# Фестиваль елдан-ел зурая

М. Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында Корбан гаете уңаеннан, традиция буенча, «Корбан Фест» гаилә фестивале үткәрелде. Ул быел Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибәте тарафыннан башкалабызда яшәүчеләр һәм кунаклар өчен бишенче тапкыр уздырылды. Әлеге чара Коръән аятьләре уку белән башланды. Бәйрәмнең сценарие ислам дине таралу тарихын яктыртуга юнәлдерелгән иде. Алып баручы Айрат Заһриев, Ибне Фадлан кебек киенеп, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителү тарихы турында сөйләде.

Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов, фестивальдә катнашучыларны һәм кунакларны мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләп, Корбан бәйрәме белән тәбрикләде. Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин Корбан бәйрәмен «безне бер-беребезгә ярдәм итәргә, бер-беребезнең хәлен белергә һәм бер гаилә булып яшәргә чакыра» дип билгеләп үтте. «Корбан Фест» кунакларын шулай ук Казан шәһәренең баш мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, «Вера в будущее» хәйрия фонды җитәкчесе Морат Әхмәров, «Ханский дом» компаниясе җитәкчесе Ильяс Гыймадов котлады.

Оештыручылар кунаклар өчен бай бәйрәм программасы әзерләде. Бәйрәмнең башыннан алып ахырына кадәр парк территориясендә бөтен гаилә өчен күңел ачу чаралары үткәрелде.

● Токиода калдыкларны эшкәртү системасы гаять нәтиҗәле эшли: барлык яна торган чүп яндырыла, төтене фильтрлар аша үткәрелә, ә көле цемент җитештерүдә файдаланыла, шуңа күрә дөньяның иң зур шәһәрләреннән берсендә бер генә чүплек тә юк.

● Тирес коңгызы – дөньяда иң көчле бөҗәк. Сынау вакытында O.taurus үз авырлыгыннан 1141 тапкыр авыррак йөкне күчерергә сәләтле булуын дәлилләгән – бу кешенең тагылмалы йөк машинасын күтәрүенә тәңгәл.

● A, E, D һәм K витаминнарына бай атланмайның 1 килосын ясау өчен 27 литр сөт кирәк. Дөньяда елына 5 миллион тоннадан артыграк атланмай кулланыла.

# «Гаиләдә» дип алданмыйк!

**(Ахыры. Башы 2 нче биттә).**

Ә асылда, төркемдә татарча аңлап бетермәгән (фамилиясе безнеңчә булып та) бер генә бала булса да, тәрбияче гел русчага күчә. Ләкин тагын да аянычы шунда: татар төркемнәрен туплаганда, баланың татар телен аңлыйммы-юкмы икәнлегенә, татар гаиләсеннән булу-булмавына игътибар бирелми, автомат рәвештә алып барыла торган чират Иван Ивановны татар балалары йөрергә тиешле төркемгә тәгаенли. Ә аның әти-әнисе ишегалдындагы бакчада балага урын табылуына шат кына. Сезнең балагыз рус бит дип кире кагып карасыннар, хәзер гауга куптарылачак. Татар төркемнәрен туплауда анык шартларны, чикләүләрне каткый канун нигезендә кертергә кирәклеге көн кебек ачык. Шунсыз балаларны бакчадан ук татарча өйрәтү турында уйлыйсы да юк.

Интернетта, социаль челтәрләрдә татар теле турында сүз чыкканда, руслар, маңкортлар «Изучайте свой язык в семье, калякайте вон, на кухне, не лезьте со своим татарским в школы, в университеты» дип чәчрәп чыга (ни кызганыч, андыйларны бер генә прокуратура да тикшерми, милләтара ызгыш кубаруда да гаепләми), чөнки алар шул рәвешле татарның тамырын корытып була икәнен бик яхшы белә.

Фәлсәфәдә яшәеш аңны билгели дигән канун, телебезне саклау мәсьәләсендә дә бик төгәл чагыла. Телебезнең кулланылуы, өйрәнелүе, анда белем алу мөмкинлеге (мәҗбүрилеге) генә аның саклануын һәм үсешен тәэмин итә ала. Ә телне кеше ихтыярына, гаиләдәге теләккә генә калдырсак, аның аерым шәхесләр тарафыннан аңлы рәвештә генә кулланылуына юл куйсак, инкыйраз көтә. Шуңа күрә телне гаиләдә саклау кирәклеге, аны 3-6 яшьлек чагында өйрәтеп калдыру турында сүз куерту урынсыз да, зыянлы да.

# Һәр халыкның мәдәнияте – кыйммәтле хәзинә

**2022 ел - Россия халыкларының сәнгате һәм мәдәни мирасы елы дип игълан ителде. Күп милләтле дәүләттә төрле этносларның традицияләрен һәм мәдәни казанышларын саклауга игътибар бирү – мөһим күренеш. Әмма бүгенге глобализация чорында «мәдәният» төшенчәсенең эчтәлеген һәм ничек үзгәрә баруын аңлау зарур. Бу хакта Татарстанның күренекле галиме, академик Рүзәл Юсупов белән әңгәмә кордык.**

**– Рүзәл абый, Сезнеңчә, Россия халыкларының мәдәни үсешендә иң әһәмиятле эш нидән гыйбарәт?**

– Иң мөһиме – җәмгыятьнең гомумән мәдәниятен күтәрү ихтыяҗы. Ул соңгы 30 елда, икътисад кебек үк, шактый түбәнәйде. Алар бер-берсе белән бәйләнештә. Икътисад, халыкның мәдәни дәрәҗәсе югары булмаса, яңа үрләр яулый алмый. Мәдәният – тормышның нигезе, ул белемлелекне һәм тәрбиялелекне дә, эстетик хәзинәләрне аңлый белеп, ишәйтә баруны да күздә тота. Белемсез, тәрбиясез, тупас кешеләр нәтиҗәле, югары технологияле җитештерү оештырырга сәләтле булмый, һәм җәмгыятьтәге төрле матди байлыклар белән тәэмин итү өлкәсендә зур уңышларга да ирешә алмый. Димәк, җәмгыятьне алга җибәрү өчен мәдәният кирәк. Менә шунда мирасның кыйммәтле байлык икәне күренә дә инде, чөнки безнең ерак әби-бабаларыбыз төзеп калдырган нигезләргә таянырга кирәк була. Булганны, «нигезеннән үк җимерер, өр-яңадан төзергә» дигән караш ялгыш булып чыкты, без бу хатаны әлегә кадәр төзәтәбез.

Халыкларның мәдәни мирасын бербөтен итеп күзаллау дөрес түгел. Милли мәдәниятләр турында аерым-аерым фикер йөртергә кирәк. Мин үзебезнең татар мәдәнияте һәм күрше территорияләрдә яшәүче халыкларның мәдәниятләре хакында сөйли алам. Һәм мин, борчылып, милли сәясәттә җитди проблемалар күп, дип әйтәм.

**– Нинди проблемалар?**

– Татар сәнгатенә килгәндә, шул хәвеф күзгә ташлана: дәүләт идарәсе органнары аны башкаларныкына охшатырга омтыла. Мәсәлән, Татарстан Мәдәният министрлыгы, «Үзгәреш җиле» дигән татар җыры фестивален оештыру өчен, Мәскәүдән артистлары өчен традицион татар мәдәниятен, татар телен яхшы белми торган концерт бригадасын чакыра башлады. Бу хәл күп кешегә ошамый. Халык музыкасын җиренә җиткереп башкару өчен, чын татар моңы хөкем сөргән мохиттә үсәргә кирәк. Ул моң бик үзенчәлекле: анда халыкның сагышы, өметләре дә, куаныч-шатлыклары, авыр тормышы мизгелләре, күңел түрендәге хисләре дә чагылыш таба. Мәскәү артистларына андый тойгылар хас түгел. Үзебезнең менә дигән җырчыларыбыз, музыкантларыбыз, оркестрларыбыз була торып, зур финанс чыгымнары ясап, ни өчен читтән кешеләр чакырырга? Аңлашыла, Мәдәният министрлыгы, башкаладан калышмыйча, концертларны гомум Европа дәрәҗәсенә җиткерергә тырыша. Ләкин кирәкме икән бу?!

Икенче җитди проблема – татар эстрадасының сыйфат мәсьәләсе. Безнең эстрада, милли үзенчәлеген югалтып, югары һөнәри музыкадан компьютерда чыгарыла торган көйләр җыелмасына әверелә, чын сәнгатьтән аерыла бара. Аяныч хәл. Артистларга артык зур ирек бирелде, күз-колак булып, юнәлеш бирүче һәм тикшереп торучы органнар юк, һәм, шушы халәттән файдаланып, музыка сәнгатенең максатын акча эшләүдә генә күрә башладылар.

Менә шуңа күрә мин мирасны саклау мәсьәләсен гомуми әхлак сыйфаты белән бәйләп карыйм. Әхлак югары дәрәҗәдә булганда халык гасырлар буена барлыкка китергән рухи хәзинәләргә: музыкага, әдәбиятка, фольклорга ихтирамлы мөнәсәбәт хөкем сөрә. Татарстанда яшәүче милләттәшләребезнең үзара ата-аналары, әби-бабалары телендә яртысы гына аралашканда һәм күбесе үз телләренә балаларын өйрәтергә теләмәгәндә, югары әхлак, милли үзаң кебек югары материяләр турында сөйләп буламы соң? Күп кешеләрнең бай тарихлы, югары мәдәниятле, хезмәтчән, уңган халкының камил телен яхшы итеп өйрәнмәвен һәм сөйләшмәвен, мәдәниятенең, гореф-гадәтләренең, матур традицияләренең кадерен белмәвен ничек аңларга була? Үз халкыңны лаеклы, алдынгы милләт итеп саклау өчен, милли горурлык кирәк. Аның башка милләт кешеләрен түбәнсетә, кимсетә торган мин-минлек сыйфаты белән бернинди дә уртаклыгы юк. Сүз зур казанышларга ирешкән нәсел-нәсәбәләреңне, дәүләтеңне, мәдәниятеңне, гореф-гадәтләреңне һәм матур традицияләреңне олылау, аларның кадерен белү турында бара. Идел Болгарстаныннан бирле безнең җиребездә дәүләт төзелешенә, әдәбият, сәнгатькә, фәнгә зур өлешләр керткән күпме генә данлыклы шәхесләр яшәмәгән. Бөек Ватан сугышында күп меңләгән татар уллары, фидакярлек үрнәге күрсәтеп, орден-медальләр белән бүләкләнгән, 150 каһарман егет Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек булган. Без күрше чуаш, мари, мордва, удмурт һ.б. халык вәкилләренең дә күркәм гамәлләренә шатланабыз.

Хәзер тиешле пропаганда, информацион сәясәт, тәрбия эше ярдәмендә Россия халыкларының мәдәниятен якларга һәм сакларга кирәк. Бераздан соң булырга мөмкин.

**– Бу игелекле эштә катнашырга җәмгыять үзе ни дәрәҗәдә әзер, аңа халык сәнгате кирәкме икән?**

– Бик тә кирәк. Чын халык сәнгате һәркайда да кыйммәтле. Мәскәүдә дә, Лондонда да, бөтен җирдә дә. Без белорус, украин, итальян, испан җырларын да, төрле халык биюләрен дә яратып тыңлыйбыз һәм карыйбыз. Чит ил кешеләре дә Россия халыкларының мәдәни казанышлары белән кызыксына. Татарстанның җыр, бию һәм музыкаль фольклор ансамбльләре чит илләрдә чыгыш ясаганда, залда буш урыннар булмый. Халыкка интернациональ дип атала торган сәнгать кызык түгел. Башка ил кешеләре Россия, элекке Советлар Союзы, Урта Азия, Кавказ халыкларының чын музыкасын тыңларга тели. Чөнки бу музыкада, чын халык сәнгатендә матурлык, яшәү мәгънәсе, эчтәлек бар. Глобальләшүнең табигый процессы, ягъни милли үзаң үсеше аша аралашу менә шушы рәвешле бара.

**– Димәк, глобальләшү ул бертөрле фикер йөртү, яшәү рәвеше түгел, киресенчә, күптөрлелекне ныгыта бару аша бердәмлекне саклау?**

– Нәкъ шулай. Глобальләшү милли мәдәниятләрнең һәм этносларның үсеше җирлегендә, аларның бер-берсенә тәэсир итүе һәм үзара баетышуы аша бара. Берсен-берсе бетерү аша түгел. Бу хакта дөньяның акыл ияләре яза. Америка, Канада дәүләтләре аз санлы, хәтта ике йөз, өч йөзләп кенә саналган этносларны да саклап калырга тырыша. Чөнки анда үз халыкларының тарихларын, традицияләрен, рухи хәзинәләрен, шулай ук табигатьне кадерлиләр, үз милләтенә ихтирам рухында тәрбияләнгән кешеләр, тирә-юнь мохитне пычратмыйлар һәм аңа зыян китермиләр.

**– Димәк, үзенең нәсел-тамырларыннан аерылган кеше үзенчә, үз дигәнчә яши башлый һәм аңа ни эшләсә дә ярый дип уйлый?**

– Шулай булып чыга шул. Кеше тупаслана, каты бәгырьлегә әверелә. Исебезгә төшерик: мәдәнияттәге иң яхшы нәрсәләр халык иҗаты нигезендә барлыкка китерелгән. Пушкин да, Тукай да, шуннан илһам алып, сюжетларын шуңа таянып корган. Салих Сәйдәшев, халык арасында йөреп, аның моңнарын, җырларының нигезләрен шуннан өйрәнгән.

Халыкның иҗади казанышларын саклау ул – кешелеклелек сыйфатларын ныгыту, каты бәгырьлелекне, миһербансызлыкны булдырмау чарасы. Шуңа күрә, андый казанышларга ирешү өчен, күркәм традицияләрне, тарих һәм мәдәният ядкарьләрен, телләрне саклау өчен көрәшергә кирәк.

Россия Фәннәр академиясе академигы Роберт Нигъмәтуллин әйткәнчә, медицинада, кеше бик нык һәм өметсез авыру булганда да, аның гомере өчен көрәшәләр. Әгәр дә без кешелеклелек, цивилизациялелек нормаларын сакларга телибез икән, мәдәниятка дә шундый караштa булырга тиеш. Кайсыдыр бер этнос кешеләренең саны кими, телләре югала икән, бу хәлгә ваемсызларча, тыныч кына карап торырга кирәкми. Шактый нык таралган «бөек халык», «бөек тел» дигән атамаларны бик сак, уйлап кулланырга кирәк. Әһәмиятсез, вак халыклар һәм телләр булмый. Дөньядагы һәрбер тел кыйммәтле, һәр телнең уңай яклары, нәфис әдәбият әсәрләре иҗат итәрлек, тормыш күренешләренең иң матур, иң серле һәм иң катлаулы сыйфатларын белдерерлек мөмкинлекләре бар. Мин, телләр турында язганда, кайчакта шундый метафора кулланам: кайсы болын матуррак, төрле төстәге чәчәкләр үсеп утырганымы, әллә бер төстәгеләре генәме? Әлбәттә, төрле төстәге чәчәкләр үсеп утырганы. Төрле төзелешле телләрне чагыштырып өйрәнгән галим буларак, шиклә̆нми әйтә алам: һәр телнең үзенә генә хас уңай, матур үзенчәлекләре, зур мөмкинлекләре һәм хәзинәсе бар. Мәсәлән, безнең татар телендә башка телләрдә булмаган бик күркәм мәгънәле ана теле дигән тәгъбир бар. Бер телнең кайсыдыр мәгънә төсмерен, нindидер хасияте төгәлрәк белдерү мөмкинлеге бар икән, икенче бер телнең башка төрле төшенчә, предмет, мәгънә үзенчәлекләрен тулырак тәгъбир итү чаралары була. Яки бер телдә кайсыдыр эстетик, метафорик категорияләрне, яшәешнең нindидер төшенчәләрен белдерү өчен мөмкинлекләр зуррак булса, башка телләрдә икенче төрле мәгънә, хис, тәэсирләрне тәгъбир итү өчен уңышлырак чаралар күбрәк була. Шуңа күрә барлык телләр дә әһәмиятле һәм кирәкле.

Сүз телләрнең һәм мәдәниятләрнең бетүе турында түгел, бәлки аларның үзгәрүе, бер-берсенә уңай тәэсир итүе турында барсын иде. Ләкин бу процессны ашыктырырга ярамый. Милли асылыбызга: тарихыбыз, телебез, мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез, традицияләребезгә илтифатсыз мөнәсәбәттә, ваемсыз карашта булсак, глобальләшү, интернациональләшү процессын тизләтәчәкбез. Ә нигә кирәк ул? Үз җае белән, табигый рәвештә генә барсын бу процесс. Төгәлрәк итеп әйткәндә, глобальләшү миллиләкне саклап үстерү аша барырга тиеш. Моның өчен без барыбыз да җаваплы.

Корреспондент
**Диана ГАЛЛӘМОВА.**

# Моң патшасы

**Сүземне бер истәлектән башлыйм. Рамил Курамшин бервакыт А.Шутиковка мөрәҗәгать итә. Һәм аңа үзе язган баян һәм халык уен кораллары оркестрлары өчен концертиносының партитурасын күрсәтә. Шушы әсәр дирижерда зур кызыксыну уята.**

Ул турыда Анатолий Иванович менә нәрсәләр сөйләде: «Рамилнең оста баянчы-солист һәм талантлы аккомпаниатор-концертмейстер икәнен белә идем. Аның иҗаты белән радио һәм телевидение аша даими кызыксынып бардым. Ләкин ул мине композитор буларак кызыксындырды һәм мин бик теләп аның әсәрен башкарырга алындым. Моның тагын бер сәбәбе бар иде: татарча репертуар кытлыгы. Башта без аны радиога яздык, аннары Татарстан телевидениесеннән һәм Үзәк телевидениедән яңгыраттык. Бу – 80 нче еллар башы иде. Концертинодан тыш Р.Курамшин эшкәрткән «Әпипә»не һәм «Эрбет»не репертуарыбызга керттек һәм безнең репертуарыбызны тулыландыруда зур көч куйганы, тырышлыгы өчен, мин дирижер һәм, гомумән, музыкант буларак Рамилгә зур рәхмәтлемен. Автордан яңа әсәрләр иҗат итүен теләп калам».

Соңрак, бу «батырлык»ны миңа да кабатларга, консерваториядә бергә укыган А.Шутиков белән үзем язган «Баян һәм оркестр өчен концерт»ны юбилей кичәмдә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында башкарырга насыйп булды. Мондый зур күләмле әсәрләрнең зур сәхнәләрдән, телевидение экраннарыннан яңгыравы татар баян сәнгатенең зур җиңүе иде. Тарихта мин беренче тапкыр «Татар баянчылары» исемле китап яздым. Р.Курамшин бу китапта үзенең лаеклы урынын алды. Бу – тагын зур җиңү булды.

Рамил Курамшин – татар баян музыкасын үстерүгә фидакярләрчә хезмәт иткән баянчыларның берсе. Аның иҗат юлы алтмышынчы елларның икенче яртысында башланып китә. Баянда уйнау сәнгатенең соңгы казанышларын һәрдаим үзләштерә барып, бу яңалыкларны ул кыю рәвештә үз иҗатында да куллана. Аның баян өчен язган күпсанлы пьесаларын музыка мәктәпләрендә дә, музыка училищеларында да, Казан консерваториясе студентлары да бик яратып уйный.

Р.Курамшин 1947 елның 16 июлендә Горький өлкәсенең (хәзер Нижний Новгород өлкәсе) Кызыл Октябрь районында укытучы гаиләсендә туа. Әтисе Сөләйман ага җыр һәм рәсем дәресләре алып бара, ә энисе Фәриха апа башлангыч мәктәп укытучысы була. Алар гаиләсендә гел җыр, музыка яңгырап тора. Рамилгә – биш, ә абыйсы Рафаилгә җиде яшь тулган елны әтиләре аларга ике рәтле гармун (хромка) сатып ала һәм улларына берничә көй өйрәтә. Шул өйрәтү җитә кала – малайлар, бер-берсе белән ярыша-ярыша гармунда уйный башлый. Мәктәп укучыларының концертларын әйтеп тә торасы түгел. Хәтта авыл яшьләре концертларына да Рамил белән Рафаилне баянда уйнарга гел чакыра торган булалар. Ә инде әтиләре белән сәхнәгә өчәүләп уйнарга чыксалар – авыл халкы аларны алкышларга күмә, кабат-кабат уйнауларын сорый.

Алгарак китеп шуны әйтергә кирәк: Рафаил Курамшин 1972-1975 елларда Г.Тукай филармониясендә Габдулла Рәхимкулов һәм Флера Сөләйманова катнашында концерт бригадасында эшли. Радиода һәм грампластинкаларда шушы җырчыларга уйнаган байтак язмалар бар. Хәзерге вакытта Мәскәүдә яши.

Урта мәктәпне тәмамлаганда, Рамил алдында «Кая барырга, кем булырга?» дигән сорау тормый. Баянда уйный башлаган елларда ук, күзе Казанга төбәлгән була. Аның уйларын бүтән сорау борчый: «Музыка мәктәбен тәмамламаган авыл малаен музыка училищесына кабул итәрләр микән?» Шушы уйлар белән ул Казанга китә. Ләкин ул килгәндә, музыка училищесына кабул итү имтиханнары тәмамланган була инде. Аңа педагогика институтының музыка факультетына укырга керергә киңәш итәләр. Рамил имтиханнарны уңышлы гына тапшырып, КДПИ студенты булып китә. Ләкин профессиональ баянчы булырга теләү хыялы аңа тынгылык бирми һәм ел ярым шушы институтта укыгач, ул музыка училищесына күчә.

Училищеның икенче курсын тәмамлап килгәндә, Рамил радиодан чыгышлар ясый башлый. Ул анда баян өчен үзе язган пьесаларын һәм татар халык көйләрен эшкәртеп уйный: «Баян өчен пьеса», «Шаяру», «Концерт пьесасы», «Төймә», «Карабай», «Җыен көе». Укыган елларда ук, Рамилгә төрле концертларда Ф.Насретдинов, И.Ишбүләков, Р.Билалова, В.Шәрипова, Х.Гыйниятова, Ә.Галимова, Г.Рәхимкулов, З.Басыйрова кебек күренекле җырчыларга да уйнарга туры килә.

1968 елда училищены тәмамлагач, Р.Курамшинны Г.Тукай филармониясенә эшкә җибәрәләр. Ул елларда филармониянең художество җитәкчесе булып эшләгән Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Рамилнең уйнавын ишеткәч, аңа зур өметләр баглый һәм, еллар үткәч, аның турында болай дип әйтә: «Рамил – үзеннән элекке буын баянчыларның эшен дәвам итүче генә түгел, ә камилләштерүче музыкант».

Башта аңа җыр һәм бию ансамблендә эшләргә туры килә. Бер ел үткәннән соң, аны Илһам Шакиров җитәкчелегендәге концерт бригадасына чакырып алалар һәм анда ул егерме елга якын хезмәт куя. Татарстанда һәм татарлар яши торган бик күп төбәкләрдә гастрольдә йөри. Төрле концертларда, радио-телевидение чыгышларында һәм грампластинкага язылганда күп кенә җырчыларга уйный. Ләкин аккомпаниаторлык хезмәте генә Рамилне һич канәгатьләндерми. Ул уку елларында ук башлаган эшен дәвам итә, баян өчен пьесалар яза һәм шуларны радиога барып уйный. «Чәчтем бодай», «Бишле бию», «Сирәкмирәк», «Җәйге авыл урамында», «Ташлар аттым Болакка», «Күңелле гармунчы», «Эрбет», «Баек», «Авыл яшьләре», «Бию», «Киндер сукканда», «Әпипә», «Гармун-патефон», «Җаек күгәрчене» кебек әсәрләре баянчылар арасында зур популярлык казана.

1980 елны Р.Курамшин телевидениенең музыкаль редакциясенә барып, баянда аерым концерт бирергә теләге барлыгы турында тәкъдим ясый. Казан телевидениесендә әлегә кадәр мондый концерт беркайчан булмаганга күрә, редакция хезмәткәрләре башта бу тәкъдимгә сагаебрак карыйлар. Ләкин Рамилнең тәвәккәллеген һәм ихлас күңелдән тамашачы алдында баянның абруен күтәрергә тырышуын күреп, ризалашалар. Концерт уңышлы үтә. Бер елдан соң, яңа программа әзерләп, Рамил тагын шундый ук чыгыш ясый һәм аның бу концертын телевидение фондына кабул итәләр. Шулай итеп, Рамилнең җиңел кулы белән, телевидениедән аерым чыгышлар өчен бүтән баянчыларга да юл ачыла.

Рамил Курамшин оркестр белән зур күләмле әсәр уйнау хыялын 1975 ел башында Рөстәм Яхинга ачып салырга җөрьәт итә. Рөстәм абый тыңлап тора да: «Рамил энем, син бит үзең дә баян өчен бик әйбәт әсәрләр язасың. Тырышып кара. Миңа калса, бу эшне дә үзең үк булдыра алырсың», – дип куәтли. Мөхтәрәм композиторның җылы сүзе Рамилдә ышаныч тудыра. Һәм ул, тәвәккәлләп, эшкә тотына. Шул елның апрель-май айларында ул «Баян белән оркестр өчен концертино» дип аталган әсәрнең клавирын тәмамлый. Соңрак оркестр өчен партитурасын да үзе яза. Татар баян музыкасында беренче зур күләмле әсәр ул. Казан дәүләт мәдәният институтының халык уен кораллары оркестры белән берләктә Р.Курамшин бу әсәрен радио һәм телевидение фондына яздыра. 1988 елның ноябрь аенда Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрендә халыкара конкурс лауреаты, РСФСРның атказанган артисты, Мәскәү баянчысы Ю.Востреловның концертлары вәгъдә ителә. Ләкин концертка кадәр 15-20 көн кала, аңардан «авыру сәбәпле бара алмыйм» дигән телеграмма килә. Концертның абонемент билетлары сатылган, кичектерергә ярамаганлыктан, филармония җитәкчеләре, «Ул баянчы урынына син концерт бирә алмассыңмы?» – дип, Рамилгә мөрәҗәгать итә. Бу көтелмәгән тәкъдимгә Рамил башта аптырабрак калса да, үз мөмкинлекләрен барлап алгач, ризалык бирә һәм шушы кыска гына вакыт эчендә программа әзерләп, гастрольгә китә. Зур уңыш белән үткән концертта ул татар халык көйләрен, татар композиторларының әсәрләрен уйный. Бер чыгыштан соң сәхнә артына рус милләтеннән булган музыка мәктәбе укытучылары кереп: «Без әлегә кадәр мондый матур татар көйләрен ишеткәнебез юк иде», – дип рәхмәтләр әйтә.

1987 елда Р.Курамшин тагын бер күләмле әсәрен – баян белән оркестр өчен икенче концертиносын тәмамлады.

Соңгы елларда ул җырлар да яза башлады. Җыр яратучыларга аның «Өй артыгыз гөлбакча», «Кичер, болыным», «Кайтса әгәр яшь чагым», «Хушлашмый китәм», «Аерылулар бигрәк авыр», «Үлмәс моңнар», «Бала чагым чыккан каршыма», «Җомга азаны» кебек җырлары билгеле. Р.Курамшин баянда, шушы уен коралының бөтен киң диапазонының һәм зур мөмкинлекләрен кулланып, виртуоз характердагы әсәрләр язып уйнаса, ә аның җырлары, киресенчә, халкыбыз җырлары кебек тирән моң белән сугарылган.

Мәгълүм ки, халык көйләренә һәм җырларына игътибар соңгы елларда кими бара. Р.Курамшин, газета-журнал битләрендә шушы проблемага багышланган мәкаләләрен бастыра, халкыбызның йөзен югалтуга илтә торган бу афәттән котылу юллары турында уйлана...

Татар музыкасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен 1984 елда Рамил Курамшинга «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде, соңрак Татарстанның халык артисты булды.

Өлкән яшьтә булуына карамастан, Р.Курамшин әле дә сафта – халкыбызга, милләтебезгә җиң сызганып, армый-талмый хезмәт итә. Аның берничә китабы дөнья күрде, ноталары белән басылганнарын музыка уку йортларында баянчылар бик теләп башкара. Шуның ачык мисалы – Арчада Рамил Курамшин исемендәге баянчылар конкурсы. Димәк, Р.Курамшинның иҗаты яши, аның язган әсәрләре киләчәк буыннарга, гасырларга калачак...

**Кирам САТИЕВ,**
Татарстанның халык артисты.

## АЛГА БАРА БУ ГОМЕР!

Киң итеп сулыш алалмый,
Ярты гасыры узылган
Калада гомеремнең;
Шулай да тупасланмыйча,
Сакланган нечкә кыллары
Моң сарган күңелемнең.

Яши-яши күпме җирләр,
Күпме шәһәрләр гизелгән,
Диңгезләрдә йөзелгән;
Ә гомерем такыясы,
Кырда үскән, гади генә
Күкчәчәктән үрелгән...

Түземлекне сыный-сыный,
(Кайчак түзми, елый-елый!),
Акыл керткән башкала;
Очраган боз күңелләләр,
Табылган гомерлек яр да –
Тормыш корган кыз бала.

Көзен өзелә яфрак, кеше гомере
Өзелергә мөмкин көзсез дә...
Маңгайларга язып куйган тәкъдир-
Үзгәртергә кеше көчсез лә!

Мәңгелеккә килмәгән берәү дә!
Мәңгелек ул- вакыт агышы.
Язлар, җәйләр бизи яшәешне,
Ә көзләр ул-гомер сагышы...

Яфрактан да хәтта туфрак кала!
Ә кешедән- дәвамлы нәсел!
Бер гөнаһсыз сабый килә Җиргә,
Аңлау өчен яшәү мәгънәсен...

## БУ ҖИРДӘ БЕЗ КУНАК КЫНА

Бу дөньяда без тик кунак кына –
Яшик чама белеп, тыйнак кына.
Иң зур байлык булсын безнең өчен
Алтын түгел, бары саулык кына.

Әлфинур ВАФИНА

Ә тамчының хәтта ташны
Тишәргә сәләте бар –
Кайнар шигъри хисләремә
Җанда гына урын тар!

## МОНДА ДА БАР...

*Яфракларым җил иркендә...*
*Туфрагымнан ерак мин.*
*Бүтән агач кәүсәсенә*
*Ялганган бер ботак мин...*
Госман САДӘ.

Монда да болытлар бар ул –
Яшене дә камчылый...
Яңгыры салкын күзләрдән
Яшьләр булып тамчылый...

Монда да болыннар бар ул,
Тик алар чит-ят сыман...
Чит болында чүп үлән мин-
Чәчкә булалмыйм-сулам...

# *Җәйге җиңел күлмәгемне киеп, Атлап кермәк идем алтын көзгә...*

Борчу-мәшәкатькә тулып,
Бәхетле мизгелләр булып,
Бик тиз уза гомерем;
Гәүдәм калада булса да,
Күкчәчәкле, аяз күкле
Кырны гизә күңелем...

Шул кырларда йөреп кайткач,
Җанда яшәү көче арткач,
Киң сулыш ала күңел;
Күкчәчәкләргә үрелеп,
Яшәү җырын көйли-көйли,
Алга бара бу гомер!

## АТЛЫЙ БЕРӘҮ ГОМЕР КӨЗЛӘРЕНӘ...

Җәйге җиңел күлмәгемне киеп,
Атлап кермәк идем алтын көзгә...
Ни кызганыч, алтын көз, дигәнем,
Күренеп кенә киткән икән күзгә!

Җәйге күлмәгемне төреп куйдым-
Моңсу булып китте күңелемә...
Ышанасы килә, үткән җәйнең
Һичничек тә соңгы түгеленә!

Шул җәйләрне якынайту өчен
Киләләр бит инде көзләр, язлар!
Нигә читкә тибәрергә көзне,
Җәйдә генәме соң җылы назлар?!

Вакытлыча гына, тик бик азга
Юмартланып ачыла көз кочагы:
Көлтә-көлтә нурлар сибә кояш –
Көзнең күзләр камашырлык чагы!

Дога укый-укый, сәҗдә кылып,
Шул кочактан җылы көчләр алып,
Атлый берәү гомер көзләренә,
Затлы шәлен иңнәренә салып...

## ЕЛЫЙ ЯФРАК...

«Өзеләм бит! – диеп елый яфрак, –
Ник булмый соң җәйдә калырга?»
Мәрхәмәтсез көзге җил котыра,
Аны йолкып, җиргә салырга...

Вакытлыча асылынып тора-
Төшәр җиргә, шунда тапталыр...
Гөлләр үсү өчен, ул яфрактан
Яңарган туфраклы җир калыр...

Кунак кына икән без бу җирдә,
Яшәү тәмен табыйк һәрбер көндә.
Яратып һәм яратылып яшик,
Ялгыз калу язмасын һичкемгә.

Ялгызларның хәлләренә керик,
Ятимнәрнең күңелләрен күрик,
Хәсрәтленең кайгысын бүлешик,
Бер-беребезгә ярдәмгә килешик.

Яшик әле җанны каралтмыйча,
Без бу җирдә бары вакытлыча,
Кеше булып кала белсәк иде,
Бу дөньяда соңгы сулышкача.

## ӘЛЛӘ ҖИЛЛӘР ЯРСУ, ӘЛЛӘ ҮЗЕМ...

Никтер бүген тәрәзәдә көзем...
Әллә урам моңсу, әллә үзем.
Карлар да бит әле эремәгән –
Ә кыш инде гүя җуйган йөзен.

Көзен өзелмичә калган яфрак
Җилдә сыкрый, тәрәзәмә тиеп...
Әллә пышылдыймы ачы җилгә:
«Яз килгәнне көтеп яшим!» – диеп?

Никтер бүген тәрәзәдә көзем...
Әллә җилләр моңсу, әллә үзем.
Кар аклыгын җуя язган инде –
Кыш әзерли саубуллашу сүзен.

Саубуллашу сүзе буран булып,
Яңа карлар булып, җиргә ятар.
Моңсу күңелемә шатлык өстәп,
Тәрәзәмдә яран гөлем атар.

Әллә кышлар моңсу, әллә үзем,
Әллә җилләр ярсу, әллә үзем.
Язны көтәм, куып гомер көзен...
Тәрәзәдә бүген ике көзем...

## КӨЧЛЕ, ДИЛӘР...

Көчле, диләр, холкы кырыс, диләр,
Сүз башларга кайчак кыймыйлар.
Җылы сүзгә шундый мохтаҗ бит мин!
Никтер шуны алар тоймыйлар...

Көчле, диләр, артык горур, диләр,
Горурлыгым – тышкы кабыгым.
Күңелемнән шигырь булып чыга
Нечкә күңелле сабыйлыгым...

Көчле, диләр, көчле булмый хәл юк –
Тормыш йөген бар бит тартасым!
Таянам тик салкын акылыма –
Беләм шулай көчем артасын!

Сөюем дә тик шигырьләремдә...
Яратуым – бары хыялда...
Көчлеләрдән хәтта мәхәббәт тә
Курка, килеп, туарга җанда!

Ирне санлап, сабыр гына яшим,
Бала-оныкларны яратам!
Яшәвемнең мәгънәсе аларда,
«Балаларым!» – диеп җан атам!

«Балаларым!» – диеп сулыш алам,
Алар, диеп, кайчак ут йотам...
Күңел генә сыза, янган шәмдәй,
Тик хыялда мин бит яратам...

Көчле, диләр, ә бит көч-куәтне
Аллаһ күптән язган колына –
Тормыш йөген тарту вазифасын
Ул биргән көчлеләр кулына!

## МИН – ХАЛКЫМНЫҢ БЕР ТАМЧЫСЫ

Мишә дулкыннары сыман,
Күңелдән дулкынланып,
Туган авылым Явлаштауга
Кайттым сезне сагынып.

Ачык йөзле якташларым,
Якын сез күңелемә.
Сезгә булган хөрмәт хисе
Кайный йөрәк түрендә.

Авылның нәкыш-бизәге
Сез бит ул эшчән халкым!
Шул халыкның бер тамчысы
Булуыма мин шатмын!

Монда да бар текә таулар –
Никтер, меңәсе килми...
Үз тауларым сагындыра –
Алар күңелдән китми!

Монда да инешләр бар ул,
Диңгез сыман Идел дә...
Ә барыбер шыртлакалы
«Урта Дугай» күңелдә...

Монда да Ай ялгыз күктә,
Ялгыз уйлый күңел дә...
Ятим коштай булмас идем,
Очсам мин үз күгемдә.

## МОҢЛЫ БЕР ҖЫР ЯЗЫП

Сөекле туган якларым,
«Шәм» ягы урманнары,
Арышлары тук башаклы,
Иксез-чиксез кырлары.

И минем газиз авылым,
Син – минем йөрәк парәм,
Сагынуымны басарга
Авылыма кайтып барам.

Наратлык елгасы буйлап,
Айкап йөрим тауларны,
Сихри моң булып тарала
Наратларның шаулавы.

И син, «Бөтнек» чишмәкәем,
Челтер-челтер агасың,
Шул челтерәүләрең белән
Күңелемдә каласың!

Авылымны, туган җирне
Кочагыма тутырып,
Китеп барам,йөрәгемдә
Моңлы бер җыр тудырып.

И кадерле туган җирем,
Син – минем йөрәк парәм,
Сүрелмәсярату белән
Еракка китеп барам.

# МӘХӘББӘТ –

**Язучы Вакыйф Нуриев белән бер бинада эшлибез, үткәндә күрешкәләп-күлешкәләп торабыз. Вакыйф абый–күп кенә зур язучыларны шәхсән белгән, аралашып торган, алар турында истәлекләр язган кеше. Ул шактый матбугат чараларында эшләп чыккан, язучылыкка һәм журналистикага гомерен багышлаган. «Казан утлары» дөньясына кереп китүенә дә тугыз ел булган инде.**

**– Вакыйф абый, сезнең гаилә Мөхәммәт Мәһдиев белән якыннан аралашкан икән...**

– Әнием 45 ел буе мәктәптә эшләде, гомере буе укытучы булды. Башлангычларны, аннан тарих, заманында немец телен дә укытты. Әни Арча педагогика училищесында Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахуновлар белән бер төркемдә укыган. Гариф абый белән Арчада очрашулар вакытында күрешкәлиләр иде, ә Мөхәммәт абый белән бигрәк тә дус булдылар. Ул безнең күрше Гөберчәк авылыннан. Мөхәммәт абый безгә кайтып йөри иде. Безнең мәктәпкә дә кайткалады, авыл халкы белән дә очрашканнарын хәтерлим, эти белән дә дус иделәр. Гел аралашып яшәделәр. Аның Гөберчәккә кайтканын ишетсә, әни дә күчтәнәчен алып барып килә иде. «Казан утлары» журналында минем «Мәһдиев һәм…» дигән бәян-хатирәм чыкты, китабымда да истәлекләр басылды.

**– Мөхәммәт Мәһдиев нинди кеше иде?**

– Бик чибәр, төз буйлы. Аңа хатын-кызлар еш гашыйк булгандыр дип уйлыйм. Тәмләп сөйли белә, юмор хисенә бай иде. Мин журналистикада укыдым, ул татар теле бүлегендә укытты. Бер үкенечем калды – аның гаҗәеп лекцияләрен тыңлый алмадым. Ул вакытта тарих-филология факультетында «Әдәби сүз» дигән стена газетасы чыга иде. Озын,15-20 метр чамасы була иде ул. Стенаның буеннан-буена сузыла иде. Мәһди аның баш мөхәррире, мин урынбасары булдым. Аның белән бергәләп 3-4 ел эшләргә туры килде. Аннан күп нәрсәгә өйрәндем.

**– Нәрсәләргә өйрәндегез аннан?**

– Мәсәлән, бер очрак. Көз көне укырга килдек, газетаны чыгарырга кирәк. Башкаларны авылга бәрәңгегә җибәрделәр, ә безгә газетаны тапшырдылар. Ничек чыгарырга? Студент тормышында яңалыклар юк, былтыргысы коелып беткән, 15 метрны тутырырга кирәк... Шунда Мәһди «Былтырның хисабы» дигән мәкалә язып килде. Тукайның да «Былтырның хисабы» дигән мәкаләсе бар, анда үткән елда булганнарны яза ул. Мөхәммәт абый үзенең мәкаләсе астына «Тукайдан түгел» дип язып куйган да, студентлар тормышында үткән ел булган барлык кызыклы вакыйгаларны җыеп язган. Ничек исенә төшереп, туплап бетергәндер! Нәҗип Нәккаш (Исмәгыйлев) ул вакытта безнең стена газетасының рәссамы иде, Мөхәммәт абый аның турында: «Нәҗип бер тәүлектә 26 сәгать икәнен исбатлады»,- дип язды. Ничек исбатлады? Моның өчен ике сәгатькә иртәрәк торырга кирәк икән. Менә шулай кызык кына, Мәһдиевчә яза иде. Безнең төркемдәшләр Апас районы Каратун авылында бәрәңгедә иде. Безгә дә нидер язарга кирәк бит – чыгып киттек үзебезнекеләр янына командировкага. Фотограф итеп Таһир Мәхмүтовны алдык, бер төркемдә укыйбыз, ул шуннан фотожурналист булып китте... Кичкә Каратунга барып җиттек, студентларны эзләп таптык, иртәгәсен алар белән кырга барып, репортаж ясадык. Ул материал Мөхәммәт абыйга ошаган иде, шул истә калган. Һәр яз көне вуз газеталары арасында конкурс була иде, безнең газета гел беренче урынны алды.

**– Әтиегез нинди кеше иде, Вакыйф абый?**

– Әти – инженер-механик, фронтовик, гомер буе колхозда эшләде. «Үлемсез полк»та ел саен аның портретын күтәреп чыгам, быел әле Мәдәният министрлыгыннан да шалтыратып чакырдылар. Әти Псковтагы легендар десант дивизиясендә хезмәт иткән. Сугышта бер төркем җыелып төшкән фотолары бар. Бөтенесенең киеме чиста, әтидә генә ике медаль – шуңа гаҗәпләндем... Нинди медальләр булган, шуны да сорашып калмаганмын. Ул 180 тапкыр парашют белән сикердем дип бик горурлана иде. Олыгайгач, оча сөяге авырта башлады, 1991 дә вафат булды. Авыруларын шул сугыш, парашют белән сикерүләр нәтиҗәсе дип уйладым. Сугышта ярты ел гына була, ләкин сугыштан соң десантчыларга җиде ел хезмәт итәргә туры килә. «Бөтенесенә кайтып китәргә, безгә җиде елга калырга, дип әйткәч, каттык та калдык», - дип әйтә иде әти.

**– Ничә бала үстегез?**

– Апам һәм мин. Апа 1993 елда мәрхүм булды. Бик яшьли – 34 яшендә китеп барды. Көтмәгәндә яман авыру килеп чыкты да, нишләргә дә белмичә калдык.

**– Әниегезне дә бик караган-сыз икән...**

– Әни 90 ны тутырып җәйне чыкты да августта китеп барды. Биш ел миндә торды. Кызым Аидага Казанның Салмачы бистәсендә йорт салдык, аннан аны ерак дип сатып, Казанның үзәгендә төзедек. Әни соңгы елын кызымда, шул йортында торды. Ул да заманында оныгын бик караган иде. Әни бөтен авыруларын җиңеп аякка басты. «Аллага шөкер, бер җирем дә авыртмый», – дип йөри иде. Көннәрдән бер көнне кызым шалтырата: «Әбинең температурасы 40 ка мендe», – ди. Мин озакламый барып та җиттем. Мин килгәч өзелде дә инде...

**– Оныкларыгыз бармы?**

– Кызымның балалары бар, Аллага шөкер. Артур исемлесе 5 яшьтән хоккейга йөри башлаган иде, менә шушы көннәрдә 18ен тутырды. Быел Идел буенда үзенең яшьтәшләре арасында иң яхшы вратарь дигән исемне алды. Икенче оныгым Роланга 10 тулды. Үземнең улыма 31 яшь, минем белән тора.

**– Ник өйләндермисез?**

– Иптәшләре дә, үзе дә өйләнергә ашыкмый, компьютерга текәлгәннәр. Хәзерге яшьләрдә нинди гадәттер ул, аңламыйм... Университетның тарих бүлеген тәмамлады, роботлар ясау белән шөгыльләнә иде, әле хәрби операцияләр белән бәйле рәвештә кыскартуга эләкте.

**– Үзегез ничә яшьтә өйләндегез?**

– 22 дә. Хатыным Ләйлә белән 34 ел тордык, җиде ел элек вафат.

**– Нык авыр кичердегезме?**

– Бик авыр. Ләйлә көтмәгәндә китеп барды. Эштән кайтты, кәефе бик әйбәт түгел иде, чәйләр эчте. Төнлә авыртынып уянды, ашыгыч ярдәм чакырттык, алып киттеләр, мин РКБга озата бардым. Үт куыгында таш бар иде, берсе бик зур иде, табибләр дә алдырырга кирәк дип әйтте, алдырам дип йөрде, өлгерә алмады. Өянәге кузгалды. Вакытында операция ясасалар, алып та калган булырлар иде, бәлки. Бер табиб та шулай диде. Үлеме бик үкенечле булды аның. Ахыр чиктә дүрт операция кичерде, берсеннән алып чыгалар, икенчесенә алып кереп китәләр. Аннан ашказаны асты бизенә зыян килеп, шуннан китте. Өч ай хастаханәдә ятты.

**– Кайда эшли иде?**

– Бүгенге татар конгрессы бинасы урынында балалар бакчасы иде, Ләйлә шунда мөдир булды. Көчле кеше иде. Әнисеннән яшьли ятим калган, әтисе китеп барган. Ятим калып та үзенд укырга көч тапкан. Казан кызы иде.

**– Вакыйф абый, әйдәгез, язучылык турында да сөйләшик әле. Сезнең биографиягезне карап чыктым, сез эшләмәгән бер журнал да калмаган диярлек. «Сәхнә», «Салават күпере», «Идел», хәзер «Казан утлары»... Кайсы чор сагындыра?**

– «Яшь ленинчы». Без яңа укып бетергән балалар, ул вакытта шундый кызыклы коллектив, Роза Туфитуллова баш мөхәррир иде. Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм гел шунда. Мөдәррис абыйны штатка ала алмыйлар иде, ул ирек яратты. Госман Садә, Нияз Акмал, Эльс Гаделев, Рәйсә Яхина, Саймә Ибраһимова белән бергә эшлибез. «Чаян»нан Фаил Шәфигуллин белән Мәгъсүм Хуҗин төшә. Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Нури Арслан килә иде. Ул вакытта «Яшь ленинчы» икенче язучылар берлеге кебек иде, бөтен язучы шунда булды. Бездәй яңа килүчеләрне әти-әниләрчә кайгырту бар иде, үзебез дә аларны хөрмәт иттек. Анда әдәби әсәр чыгару да зур дәрәҗә саналды, таләпләр зурдан булды. Күңелле чор иде.

**– Яшьлегегезне сагынудыр бу?**

– Шулайдыр. Без ул чорда язучыларга шундый зур шәхес итеп карадык. Нәби Дәүли белән сөйләшеп утырганнар һаман истә, Илдар Юзеев белән соңгы көненә кадәр аралашып яшәдек. Кеше буларак гади иделәр, аларның олпатлыгын кайта-кайта күбрәк тә аңлыйсың икән. Бүген дә яхшы язучылар, көчле журналистлар бар, аларны да хөрмәт белән кабул итәргә кирәк.

**– Сез хәзер «Казан утлары»нда баш мөхәррир урынбасары. Югарыда санап киткән шәхесләр кебек көчле әсәрләр язучылар бүген бармы? Кайсылары әдәбият дәреслекләренә керәчәк?**

– Андый әсәрләр бар. Соңгы 4-5 елда әдәби конкурслар үткәрәбез, аларның ярдәме нык тиде. Бер елны «Татнефть», икенче елны Сәламәтлек саклау министрлыгы, аннан ТР Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә, тагын Җиңүнең 75 еллыгына багышлап та үткәрдек. Бу конкурслар безнең журналны туендырып торучы чишмәләр булды. Премияләр саллы иде, язарга стимул булып торды, көчле әсәрләр килде.

**– Мактап кына утырмыйк инде, берәрсен сүгик әле...**

– Менә бүгенге көндә әдәби тәнкыйть язучы юк. Элек Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, Мөдәррис Вәлиев, Фәрваз Миңнуллин, Мансур Вәлиев бар иде. Фәрваз Мөхәммәт Мәһдиевнең бөтен әсәрләренә бәя биреп барган. «Казан утлары»нда тулы бер тәнкыйть бүлеге булган. Хәзер Рәфикъ Шәрәфиев, Тәлгат Галиуллин язгалап тора, әлеге жанр үлеп бара...

**– Әдәби тәнкыйтькә үпкәлиләр идеме соң?**

– Үпкәләү элек тә булган инде. Язучыларга туры карап: «Син нишләп шулай яздың?» – дип әйтә алганнар. Шәйхи Маннурлар туры сүзле булган, җыелышларны да ташлап чыгып киткәннәр... Хәзер бернәрсәгә эч поша – язучылар бер-берсенең әсәрен укымый. Яхшы әсәрләр языла, «Язучылар арасында бәя бирүче булдымы?» –дип шалтыратам. «Юк, миңа беркем дә шалтыратмый», – диләр. Тәнкыйтен әйтмиләр инде, ләкин мактап та әйтмиләр. Әсәрләре чыккан авторлар бәя алмыйча кала.

**– Тагын нәрсә җитми әдәбиятка?**

– Юмор һәм сатира жанры юк. Ул журналистикада да, әдәбиятта да юк. Фельетон жанры үлде. Ә заманында «Чаян»ны шул гына тотты бит. Бүген без юмор, сатира сәхифәсен көчкә алып барабыз. 2012 елда «Яңа базар» конкурсы булып алды, шуннан бирле юмор килгәне юк. Нәрсәдән шулай икән ул? Тормыш авырмы? Һәр кеше аерым, үз эченә бикләнеп яшәгәннәнме? Алай дисәң, сугыш чорында да юмор булган.

**– Язучыларның әсәрләрен нык эшкәртәсезме?**

– Эшкәртелә шул. Үзем эләкмәдем ул чорга, ләкин Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗевләр һәр сүзе өчен көрәшкәннәр. Редакторга ошамыйча, аның берәр сүзен төзәтәсе булса, үзләренә шалтыратып рөхсәт сораганнар, килештереп эшләгән-

# КӨН ДӘ КИРӘК

нәр. Ә бүген китергәннәрнең яртысын кыскартырга кирәк. Өченче ел отпускка чыккач, икенче көнне үк иртәнге якта эштән бер кыз шалтырата. «Вакыйф абый, кил, бер романны саласы бар, 200 битен кыскартырга кирәк»,- ди. Шулкадәр кыскартырга кирәк булгач, ул романны үзегә чамалап карагыз инде. Килдем дә авторына шалтыратам, язучының үзеннән башка әсәрен кыскарту – кулын кисеп ташлаган кебек бит инде. Авторы: «Теләсә нишләтегез, теләсә ничек кыскартыгыз, чыгарыгыз гына», – ди. Менә шундый мөнәсәбәт. Берсе Камил Кәримов эшләгәндә тәмамланмаган әсәр алып килгән. Камил: «Тәмамлап бетереп китер инде безгә», – дигәч, «Әй, үзең тәмамла инде шунда», –дип китеп барган. Бөтенесе дә алай түгел, әлбәттә. Сүз тәмен, язуның кадерен белүчеләр дә бар.

**– Яшь шагыйрьләр бармы?**

– Шагыйрьләр элек-электән әдәбиятка төркем-төркем килгәннәр. Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Ренат Харис – бер төркем, Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Газинур Морат, Ләбиб Лерон – икенче төркем, Рүзәл Мөхәммәтшин, Лилия Гыйбадуллина, Йолдыз Миңнуллина, Фәнил Гыйләҗев – тагын өченче төркем. Алардан соңгы төркем кайчан килер икән? Монда бераз озынрак пауза булырга мөмкин. Шунысы бар – яшьләр арасында прозаиклар аз булды: Рөстәм Галиуллин, Ландыш Әбүдәрова, Айсылу Имамиева. Ләкин соңгы вакытта яшь шагыйрьләр дә прозага кереп-кереп ала, шуңа сөенәм. Рүзәл Мөхәммәтшин конкурста «Лалә» дигән хикәясе белән җиңде, Лилия Гыйбадуллинаның повестен укып утырам әле.

**– Вахит Имамов интервью вакытында: «Кайбер язучылар берлеккә керү белән язудан туктый»,- дигән иде. Мондый күренеш бармы?**

– Менә 360 язучының исемлеге язылган кенәгә. Шуннан мәктәпкә очрашуга барырга дәрәҗәле кеше эзли башласаң, таба алмыйсың. Кайсы авыру, кайсы Казаннан читтә, кайсы карт, кайсы бөтенләй билгесез кеше... Үзем дә алты ел Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып эшләдем, бу хәлләр башымнан кичте.

**– Берлеккә кергәч тә язудан туктауның нинди сәбәбе бар икән?**

– Язучылар союзына нинди максат белән керүләренә карый инде. Зөлфәт Хәкимне, мәсәлән, «Әйдә, рәхим ит, союзга кер инде»,- дип чакырып, кодалап алдылар, үзе сорап йөрмәде. Хәзер күбесе керергә ашкынып тора. Бервакыт мин язучылар берлегендә эшләгәндә Чүпрәледән бер бабай килде. Өстәлемә китапларын тау кадәр итеп өеп куйды. Сыйфаты да чамалы гына, аны кем укыгандыр, ләкин язган инде... «Бабай, сиңа союз нәрсәгә, күпме язгансың бит инде», – дим. «Союзга керсәң, сез үлгәч бушлай таш куясыз икән», – ди. Менә аның максаты! Кергәч сүнгән, беткән язучылар күп... Монда кергәч, яхшы итеп язарга кирәк дип куркып калалар микән? Әллә канәгатьләнеп, бүтән эшлисе юк дип уйлыйлардырмы?..

**– Күп язучыны эчү дә харап иткәндер?**

– Талантны бөтенләй юкка чыгарып булмыйдыр, минемчә. Аракы эчү – ул безнең буынның фаҗигасе булды инде. Кайсы буынга сугыш, кайсына ачлык, ә менә безгә эчүчелек эләкте. Сугыштан соңгы чорларда авылларга керә башлап, безнең бәләкәй чакта тамыр җәйде ул. Юклык чоры, аракы да дефицит. Кич белән клубка берәрсе җибәреп чыкса: «О, каян тапкан?» – дип аны король дәрәҗәсенә күтәрәләр иде. Шулай итеп модага кереп китте ул…

**– Хатын-кыздан башка көнкүрешне ничек алып барасыз? Авыр түгелме?**

– Башыңа төшсә, әллә нәрсәләр пешерәсең икән ул. Хатыным исән чакта йомырка гына кыздыра беләм идем. Хәзер нәрсә генә пешермим... Бу ялда базарга барып, форель башы алып кайттым. Шуны яхшылап чистартып, тәмле итеп уха пешердем, аңа 17-18 төрле тәмләткеч салдым. Шуның берсе генә булмаса да, минем күңел тыныч түгел инде, кибеттән алып кайтмыйча тынычланмыйм. Башка төрле аш белән дә шулай. Башта базардан итен сайлыйм, кабырга ашы яратам инде, итен күп салам. Оныклар килсә, минем ашларны икешәр тәлинкә ашыйлар. Бавыр алып кыздырам, кәтлит, гүләш, коймак... Барысын да җиренә житкереп эшлим, ирләр тотынса, шулай пешерә инде.

**– Нык гашыйк булучан кешеме сез, Вакыйф абый?**

– Әйееее…Менә синең дә күзләрең матур, күз карашың шулкадәр серле!

**– Яшь барган саен хисләр сүреләме?**

– Бик сүрелми шул. Һаман үзеңне яшь вакыттагы кебек хис итәсең. Аннан көзгегә карыйсың да, «әй, юләр» дип куясың. Ләкин гашыйклык хисен бер дә йозакка бикләп куясы килми икән.

**– Сезне бер матур кызга гашыйк булган дип сөйләделәр әле.**

– Кем икән ул?

**– Диана исемле...**

– Әәә... Аңа – 33, миңа – 63. Безнең 30 яшь аерма.

**– Ничек таныштыгыз?**

– Хатыным үлгән ел. Мин кара плащтан урамнан кайтып барам, яңгыр да төшкәли. Баш һәрвакыт түбән иелгән, аяк очына гына карап йөрим. Ул вакытта иртән әле ничек тә чыгып китәсең, ә кичен өйгә кайтырга күңелсез, моңсу. Каядыр кереп, ярты буханка ипи дә алдым. Җиңү Проспекты белән Фучик урамындагы ике арада агачлык кебек җир бар, анда кеше дә йөрми, шайтан таягы үсә. Шуннан бер кыз әкрен генә, биегән кебек бара. Минем моңа ачу килде! Кем генә йөрмәс монда, бәлки мин берәр маньяктыр. Шуннан мин аның артыннан куып җитә башлагач, ул кинәт кенә, һөҗүмгә әзерләнгәндәй борылды... Танышып киттек. Минем дә әзрәк күңелне күтәрәсе килә бит, авыр чак, шундук аны «Марокко» дигән ресторанга чакырдым. Өч тапкыр кияүдә булган, стриптизер булып Мәскәүдә эшләп кайткан. Турыдан сөйләве, берни дә яшереп тормавы ошады. Чәчәк кибетенә кердек, бер лилия алырга кушты, мин өчне алдым. Шуннан китте инде...

**– Нинди соң ул? Чибәрме?**

– Җыеп әйтсәк, аның бөтен җире ясалган. Борынын Израильдә, иренен Испаниядә ясатып кайттым, дип сөйли иде. Күзенең төсе дә төрле көнне төрле төстә, линзаларын алыштырадыр, күрәсең. Мин аның гел төрле кыяфәттә булуына озак ияләнә алмадым.

**– Озак очраштыгызмы?**

– Очрашу дип, ул минем кыздан да җиде яшькә яшьрәк, житди мөнәсәбәтләр түгел инде ул... Аралашуын хәзер дә аралашабыз, көн саен хәерле иртә теләп смслар яза, менә бүген дә иртәнге биштә язган. Сирәк кенә очрашабыз. «Казан утлары»ның 100 еллыгына килде, редакциядә булгалый, бакчама килә иде. Хатын үлгәннән соң ел ярым депрессия халәтендә яшәдем, ул мине тормышка кайтарды, тормыш бизәге булды. Диага (Вакыйф абый аны шулай дип йөртә икән) моның өчен рәхмәт.

**– Аңа гашыйк булдыгызмы?**

– Юктыр, 30 яшь аерма шактый зур. Әнә, Ренат Ибраһимов мең яшәрмен кебек сөйләшә иде, «Тагын бала алып кайтабыз әле», – дип торды. Китте дә барды, берсеннән-берсе кечкенә балалары калды, хәзер хатынына авыр. Иң оптималь вариант – 10-20 яшь аермадыр.

**– Яңадан өйләнәсегез килмиме?**

– Яхшы хатын туры килсә, өйләнер идем. Дин өйләнергә куша. Миңа бер хәзрәт: «Син зираттан хатыныңны күмеп кайтканда ук өйләнү хакында уйларга тиеш идең, дин парлы булуны хуплый»,– диде. Моңа каршы килеп булмый.

**– Язучыларга мөрәҗәгать иткәнегез булмадымы соң?**

– Тәкъдимнәр күп булды. Яулыклы, диндәге хатын-кызлар белән таныштырырга теләделәр. Сүз дә юк, ул дөрес юл, ләкин мин аңа әзер түгел.

**– Вакыйф абый,чын мәхәббәт кешенең тормышында берәү генә буламы?**

– Кешенең тормышында мәхәббәткә һәрвакыт урын калырга тиеш. Көтмәгәндә, теләсә каян килеп чыксын иде ул…

***Лилия ЗАҺИДУЛЛИНА.***

intertat.tatar

# КАЙТЫР ЮЛЛАР

Адлер ТИМЕРГАЛИН

**(Дәвамы. Башы 26 нчы санда)**.

– Сез кем исеменнән сөйлисез? –дип сорады, ниһаять, капитан.

– Үз исемемнән.

– Сезне кем диик соң?

– М-м... шушы планетаның хуҗасы дип санагыз. Яки... илче. Барыбер.

Алиса, капыл гына борылып, илченең мәгърур йөзенә карады. «Бер генә хис тә юк моның йөзендә...»– дип уйлады ул, ачуы кузгалып.

– Ә без ышанмасак?

– Ышанырга туры килер, – диде илче.

Чыннан да аңа ышанмыйча мөмкин түгел, һәр сүзе мәгънәле һәм көчле иде аның.

– Яхшы, – диде капитан һәм кулындагы касканы коры мүк өстенә куйды. – Без риза. Тик шулай да без кем кулыннан ярдәм алуыбызны белергә тиештер бит? Илче иңнәрен сикертеп куйды.

– Минем кулдан.

– Алайса без риза түгел! – дип кычкырып җибәрде шул чак пилот.

Һуманоид аңа сөзеп кенә карап алды. Кешеләр психологиясенә, мәгънәсез тискәрелеккә ул һаман ияләнеп җитә алмый иде бугай әле.

– Тыңлагыз, алайса, – диде ул һәм күпне белгән укытучы-хәлфә кыяфәтен алды. – Без – изоляционистлар, ягъни без галәмдәге башка дөньялар, бүтән культура һәм цивилизацияләр белән элемтә тотмыйбыз, чөнки бу элемтә безгә бернинди дә файда бирми. Без Бөек Божра барлыгын да беләбез, ләкин аны... кире кагабыз. Без тормыш-тереклекнең мәгънәсен, ямен һәм, әйтергә яраса, ләззәтен башка нәрсәдән таптык, һәм без үзебез урнаштырган тәртипнең бозылуына юл куймаячакбыз.

– Нинди тәртип?

Капитанның бу соравы бик кырыс яңгырады.

– Белмим, төшенерсезме икән... Сез аңлаган мәгънәдә яшәмибез без.

– Ә ничек? – диде Алиса, сискәнеп.

– Без актив тормыштан, эш-хәрәкәтләрдән ваз кичтек, м-м... туташ.

– Сез ни генә эшлисез соң?

– Берни дә эшләмибез. Тагы сораулар бармы?

– Бар. Бик күп, – диде капитан һәм утырган җиреннән торып, илче каршысына килеп басты. Шунысы гаҗәп, үзе шактый өлкән яшьтә булса да, бу минутларда аның төз гәүдәсе ничектер яшьрәк тә, көчлерәк тә тоелә иде.

– Сорагыз, – диде вәкил.

– Әгәр инде сез эштән баш тарткансыз икән, шәһәрләрне сезгә кем төзеп бирде? Сезгә... азык-төлекне кем әзерли дә, кем киендерә?

– Хәзерге вакытта автоматлар. Элек исә без үзебез, дөресрәк әйткәндә, безнең борынгы ата-бабаларыбыз эшләгән.

– Хөкүмәт-мазар бармы сездә?

– Юк, бөтен эш-хәрәкәтләр координациясен үзәк автомат башкара.

– Шайтан алгыры! Һм... сездә мәхрүм ителгәннәр, ятимнәр, я булмаса тормыштан канәгать булмаган кешеләр бармы?

– Юк.

– Авырулар, зәгыйфьләр дә юкмы?

– Юк, капитан. Бездә язмыш һәркемнең үз кулында. Язмышны һәркем үзе сайлап ала.

– Ничек?

– Кеше туып, акыл ягыннан җитлеккәч тә, аңа миллионнарча язмыш төрләреннән – махсус перфоленталардан үзенә яраклысын, күңеленә хуш килгәнен сайларга рөхсәт ителә. Ул бер лентаны сайлый һәм шундагы программа буенча... яши.

– Әгәр теләмәсә? Фикере үзгәрсә?

– Аның фикере үзгәрми, хөрмәтле капитан. Үзгәрә алмый.

– Гаҗәп.

Һуманоид дәшмичә генә сәяхәтчеләрне күздән кичерде.

Алиса үзенең соравы белән икенче яктанрак аңлашырга тырышып карады:

– Сез бәхетлеме? – дигән авыр сорау бирде ул.

– Тормыш юлын үзебез сайлагач, сездәге бәхет төшенчәсенең безгә кагылышы юк, – дип шома гына кулдан ычкынды илче.

Ул үпкәли дә, үртәлә дә белми иде бугай. Бөтенесен дә аңлагандыр бәлки? Без дә бит бала-чага шуклыгына ачуланмыйбыз.

– Безнең тормышыбыз хис-тойгылар һәм кичерешләр белән тулы, тик ул хисләр турыдан-туры тышкы мохиткә – сезнең чынбарлыкка дип әйтимме – бәйләнмәгән...

– Нинди сәер тормыш соң ул, аңлатып бирсәгез иде!

– Гипнотормыш... Без йоклыйбыз һәм төш күрәбез.

Аяз көнне яшен суккан кебек булды. Бер мәлгә бөтен дөнья тынлыкка чумды. Гүя җил кинәт кенә басылды да, болытлар бозланып катты, әле генә чәчри-чәчри янган ялкын телләре хәрәкәтсез калды. Монда тормыш сүнеп, вакыт үзе үк туктаган кебек иде... Йокыдагы тормыш!

– Димәк ки, сез, мәрткә киткән кебек, галлюцинацияләр дөньясында яшисез? – дия алды, ниһаять, капитан.

– Әйе, тотрыклы һәм өзлексез галлюцинацияләр. Әйтергә кирәк, бу төш чынбарлыкның үзе кебек үк реаль һәм эзлекле. Без гомер буе төш күрәбез; бала чакта уйнап-шаярып үсәбез, укыйбыз, мавыгабыз, бәхәсләшәбез, көрәшәбез, фәнни ачышлар ясыйбыз, сөябез.

– Планета түгел, психик авырулар йорты бу! – дип кычкырып җибәрде пилот, тыела алмыйча, һәм йодрыкларын йомарлады... – Сары йорт! Юләрләр йорты!

– Ялгышасыз, – диде аңа илче. – Ялгышасыз, пилот Грин. Мин сезне гафу итәм, чөнки сезнең бу ялгышыгыз белмәүдән килә... Без – карт җәмгыять, – дип дәвам итте ул. – Без күпне күргән, күпне кичергән... Вәхшилек тә, коллык чоры да, юксыллар һәм аксөяк изүчеләр чоры да баштан узган. Без җәмгыятьне үзгәртеп корып, тигез һәм шәфкатьле тормышка ирешә алдык. - Бу сүзләрне әйткәндә илченең мәрмәрдәй ак йөзеннән беренче кат нинди дер бер шәүлә йөгереп узды. – Әмма, ләгънәт төшкән шикелле, гасыр саен бер яман нәрсәгә – диктатурага әйләнеп кайттык.

– Диктатурага?

– Диктатура. Тирания. Деспотизм. Без төзегән ирекле һәм хөр җәмгыять аерым кешеләрнең мәкере һәм хәйләсе каршысында көчсез булып чыкты. Гаделлеккә ирешүебез була, яшь буын, борынгы кыргый инстинктларга бирелеп, бөтенесен ватып-җимереп ташлый...

Капитан борын астыннан гына нидер әйтеп куйды.

– Шулай хөррият белән уйнап, кат-кат төп башына утыргач, без тормышны тамырдан үзгәртү уена килдек.

– Әйтерең бармы – шәп чара!

– Һәм хәзер картларча, тыныч кына, хатирәләр белән яшибез.

Тәрәккыят шулай борма юллар, тар сукмаклар буйлап бара. Бөтен җир йөзен басып китеп, миллион еллап буе хаким булып яшәгән гигантозаврлар, тереклек көчләрен сарыф иткәч, кырылып бетәләр; мәгърибе белән мәшрикъларны яулаган Искәндәр Македонга да чик куела, христиан дине, бар булган мөмкинлекләре төкәнгәч, сәхнәдән төшә... Цивилизацияләр белән дә шулай. Юлдан язмыйм дисә, ул Бөек Божрага кушылырга тиеш. Ә бу планетадагылар, меңләгән башка җәмгыятьләрдән йөз чөереп, төпсез упкынга егылып төшкәннәр. Гипнотормыш дигәннәре әфьюн исереклеге белән бердер, күрәсең.

– Сездә аерым шәхесләр сакландымы соң?

– Нигә сакланмасын! – дип, шундук җавап бирде илче капитанга. – Бу яктан, ихтимал, һәммәсе нәкъ сездәгечәдер. Менә мин, мәсәлән, йокы халәтендә атаклы сунарчы идем...

– Бу үле мохиттә чебен-черки дә калмаган ич! – диде Алиса, әйләнә-тирәгә күрсәтеп. – Ярый әле агачлар бар...

– Планетада киек заты калмаганга унбиш мең ел инде, туташ.

– Шулай булгач?

– Мин моннан биш мең гасыр элек яшәгән сунарчы тормышы белән яшәдем: кылыч тешле юлбарыслар, йөнтәс борынмөгезләр, кыргый атлар ауладым.

Һуманоид, үзенең хәтәр маҗараларын искә төшереп булса кирәк, елмаеп җибәрде. Бу аның беренче елмаюы иде.

– Гаиләгез бармы? – дип сорады капитан, илчене каш астыннан гына күзәтеп.

– Ике балам бар. Улым үзенә тормыш юлы сайлады инде. Гипнопрограмма буенча, билгеле.

– Кызыгыз ничек?

– Кызым бала гына әле. Ул инкубаторда ята, бала чак уеннары баскычын кичерә. Әнисенә охшаса, каты табигатьле булыр төсле. Берәр борынгы шаһинә ролен сайламаса ярый инде.

– Шаһинә?

– Әйе, туташ. Кайберәүләр патша ролен ала, җәлладлар, сихерчеләр дә булгалый. Гипнотормышта кем нәрсә тели, барысына да ирешкән кебек була...

– Сез шушы йокы халәтендә үзара элемтә тотасызмыни?

– Безнең элемтә бик чикләнгән, капитан. Һәм аның кирәге дә юк. Минем улым безнең уртак гипнопрограммада кабилә шаманында өйрәнчек... Алар әнә теге Котып йолдызын дөньяның кендеге дип, үзләрен кендек бабасы дип саныйлар.

–-Ниткән программа бу?! – диде пилот. – Чынлыкта... чын тормышта... сезнең улыгыз бармы соң? Әллә анысы да төштә генәме?

– Бар. Улым нәкъ үземә охшаган, чөнки ул биоген ысул буенча дөньяга килгән. Йоклап ятсак та, безнең организм картая бит. Шуңа күрә нәсел калдыру – безнең өчен тормышта да мәҗбүри шарт.

Уңайсыз тынлык урнашты. Капитан сүзне икенче якка борып җибәрде:

– Тормыш программасын сезгә кем әзерли?

– Хисап машинасы.

– Һәм сез шул үле автомат төзегән киртәләрдән чыга алмыйсызмы?

– Нигә чыкмаска? Ихтыяр көче һәм очраклы хәлләр принцибы саклана бит. Программада очраклы үзгәреш булу белән, без уянабыз, ләкин күпчелек тизрәк тагы йокыга талырга ашыга. Шул ук автомат безгә үз-үзебезгә кул салырга ирек бирми.

– Ни өчен?

– Төп иҗтимагый программадан тайпылмас өчен. Бездә халык саны төгәл исәпкә алып барыла һәм билгеле бер чиктән арттырылмый. Планетаның табигый байлыкларыннан файдалану, бөтен экономика шуңа бәйле. Ятакта булсак та, безнең кан системасына туклыклы матдәләр бирергә кирәк бит. Ә ата-бабаларыбыз күп калдырмаган: урманнар аз, планетабызның табигый иярченен дә атом мичендә якканнар...

– Озын сүзнең кыскасы, сез туган көнегездән алып биологик үлемегезгә – чын үлемегезгә! – кадәр биләүдә төш күреп, хыялланып ятасыз?

– Ул төш үзенең реальлеге белән сезнең чынбарлыкка тигез, капитан. Анда кара урманнар шаулый, боланнар утлап йөри, бомбалар шартлый, кан коела.

**(Дәвамы киләсе санда)**.

Зиннур МАНСУРОВ

# АЧЫ ТӘҖРИБӘ КЫСАГА СЫЙМАС



## I

●Болгавыр заман үзеннән-үзе генә килми, аны кеше шушындый хәлгә төшерә.
●Көчеш чоры һәрвакыт яхшыга гына илтмәс.
●Чын демократия аерым илләрдә көчләүсез, милли гореф-гадәт кебек, табигый рәвештә үсеш алырга тиеш.
●Кешеләр кайвакыт казаны үзләре чакырып китерә.
●Бер кеше тудырган зур проблеманы, гадәттә, күмәкләшеп хәл итәргә туры килә.
●Тарихтагы буталчык хәлләр – шайтан аягын сындырырлык.
●Тәвәккәл сәргаскәр: «Меңләп кул белән төзелә торган кальгане нибары бер баш белән җимереп була».
●Халыклар дуслыгы чәчәк атканда шайтани груһта аллергия башланыр.
●Ил белән идарә итәргә маташучы шамакайлар урыны циркта, чөнки бирелә кирәгеп куячак тимер читлек тә бар.
●Ачы тәҗрибә кысага сыймас.
●Даимән максатка омтылу һәртөрле уңыштан мөһимрәк.
●Тормыш тәҗрибәсендә үрнәк тә, гыйбрәт тә булырга мөмкин.
●Ата-баба горефен төгәл сакласаң, хакимлек кануннарына да сыешырсың.
●Демограф: «Женси мәсьәләләр калкытып куелмаган чорда гаилә саен 8-10 ар бала, женси бәйләнешләр турында ачыктан-ачык сөйләнгән заманда 1-2 шәр бала үсә».
●Атны борынгылыкта ук йөкләтелгән файдалы эш-хезмәттән читләштерү алгарышка омтылучы кешеләр мисалында да кабатланырга мөмкин.
●Илдәге акыллы кешеләрнең исәбе алынса, ялганга чыккан күрсәткечләр күптин-күп булачак.
●Көянтәле үлчәү тәлинкәсенә урнаштырган очракта явызлык яхшылыкны ихтыярсыздан өскә күтәрәчәк.
●Үле килеш дөньяга килгән идея корбаннар таләп итмәве белән кыйммәт.
●Безнең шәхси тәҗрибәгә нигезләнгән инану гомуми карашлардан югарырак тора алмый.
●Кеше үзенең тәрҗемәи хәлен яшьли лаеклы рәвештә язарга әзерләнсә, тора-бара аның тормыш сәхифәләре тарих китабына кереп китәргә мөмкин.
●Хезмәтендә чик-чаманы белмәгән тарихчы баштүбән торучы күрәзәне хәтерләтә.
●Адәм баласы әүвәл «Мин тормышка гашыйк!» дип белдерә, аннары ул тормыш хакында зарлы шикаятьләр яза башлый.
●Үзенә бәйле бихисап зарны ишетеп торган тормыш әле якын вакытта гына капыл төзәлергә уйламый.
●Кемнәрдер өендәге хисапсыз байлыкны күрсәтмәс өчен, кемдер фәкыйрьлеген белгертмәү теләгеннән кунак чакырмый.
●Тарихи затларны берьюлы күрергә теләсәң, тиләләр йортына зиярәт кылуың җитәчәк.
●Үзеңне үтә тәрбияле зат итеп санасаң сана, әмма җәмгыять сине ак карга кыяфәтендә күрмәсен.
●Балалар башта хакны матур итеп әйтү сәләтен күрсәтә, аннары җәмгыять аларның ихласлы сөйләшен төрлечә бозылуга этәрә.
●Табигатькә төзәтмә кертергә маташу – илаһи гамәлгә тыкшыну галәмәте.
●Беркатлы мантыйкчы: «Гомер озынлыгы зурайган саен изге гамәлләр ишәергә тиеш».

## II

●Урман ешлыгында ниндидер сынга охшаш нәрсәләр безне сокландыра, табигатьнең илаһи камиллектәге күренешләре исә артык хәйран итми.
●Яңа заманның рухи кыйммәтләренә дөрес бәяне берничә буын вәкилләре генә бирә ала.
●Талип «бишле»гә имтихан биргәч, тәкъдир сынавы елмаеп куяр.
●Үзеңне хаклы дип исәпләсәң, әйткәнеңдә нык тора алырсың.
●Кайбер кызыктыргыч идеянең асылына иблислек әгъвасы кушылырга мөмкин.
●Карашларның чын төрлелеге хакыйкатьне дә хушландырыр.
●Тормыштан сабак алучылар белемнәре белән масаймас.
●Талымсыз мәннән зәвык эзләмә.
●Театр сәхнәсендә уйналган тормыш язмыш ханымны ышандыра алмый.
●Сабыйның бераз иртәрәк дөньяга килүе тәкъдирнең тәртибе бозылу булып саналмас.
●Маятник төсле уңга-сулга тирбәлгән бишек гомер сәгатенең саный башлаганын искәртер.
●Язмышың белән килешеп яшәү өчен гаять олы сабырлык таләп ителә.
●Эчтәге каланчаң туры булса, сине кыек көзгеләр куркытмас.
●Шәхси тормышында кулланып бетермәгән гыйлеме буенча адәми затның әдәплелек дәрәҗәсен ачыкларга мөмкин.
●Тормыш турындагы һәртөрле күзаллауда, яшәешнең үзе белән чагыштырсак, чынбарлыкны бозулар кычкырып тора.
●Һәрвакыт отышка ирешү беренчел максатны аңлатмас.
●Энтомология белгече: «Нибары бер көн яшәүче күбәләкләр күзлегеннән караганда, кешеләргә бирелгән гомернең озынлыгы иксез-чиксез булып тоела».
●Яшәү мәгънәсе турында, башыңны күтәреп, күкләрдән укырга тырыш.
●Яшәешнең кыйммәте базарда билгеләнмәс.
●Эшнең уңайга китүе өчен бераз кирелек тә зарур.
●Башында бердән артык уйны йөртсә, андый инсан гамьле булып саналыр.
●Адәм заты чынбарлыкта, кошлардан аермалы буларак, канатларын эчтә тота.
●Кемдер өчен терәк булу сине җиргә ныграк бәйләр.
●Ир белән хатын арасында кайнар мәхәббәт кенә түгел, төптән уйлап эш итүчән дуслык та булырга тиеш.
●Тол хатынның мендәрен сыксаң, хәсрәт диңгезе барлыкка килер.
●Антрополог: «Оҗмах күренеше кешенең тарихи хәтерендә сакланырга тиеш, чөнки Адәм белән Һаваның җәннәттән сөрелүе мәгълүм».
●Лөгыйнь зат гадәтләренә ияләнмәс өчен адәм баласына киребеткәнлек тә хаҗәт.
●Ялагайлык күрсәткән затның шәхси фикерен сорамыйлар.
●Кайнар башлы адәм заты салкын канлы була алмас.
●Үзе һәрнәрсәнең астын өскә китереп яши, үзе хәтта баштүбән дә тора алмый.
●Сак бул, күкрәк сугып шыпырынган чакта укаң коелып төшәргә мөмкин.
●Эчендә ниндидер җеннең утыруын тоючы бендә зарур чакларда үз-үзе белән көрәшергә теләмәс.
●Гомерне тәгаен бәя биреп бетергесез илаһи бүләккә тиңлибез, вәләкин хөкүмәт аның акчалата хакын бик ансат билгели.
●Дөньяда күпне бирергә гадәтләнсәң, ахирәттә үзеңә күпне алырсың.
●Иске зиратны киңәйткән чакта жирнең күкрәге кысылып куяр.
●Акыллы баш гөманы: «Кемдер сул иңбашын салындырып йөри икән, димәк, аның теркәп барылган яман гамәлләре күбәеп киткән».
●Җәһәннәмдә шикаятьләр кенәгәсе булмачак.
●Яшәеш мәгънәсен аңлар өчен хисап көнен көтәргә кирәкми.
●Вакыт ашкын елгадай тиз-тиз акканда, мәңгелек иксез-чиксез дәрьядай җәйрәп ятар.
●Вакытка мәңгелек килеп кушылса, сәгатьләр акрын йөргәндәй тоела.
●«Иртәгә» кәлимәсе күбәләккә ошамас.
●Гомер башта озын әкият шикелле, соңынтын кыска төш кебек тоела.
●Ышанычы ике дөньяны да колачлый.
●Китап битләре арасына кыстырып куелган яфрак кәгазь ясарга киселгән урманнарны кызганып саргаер.
●Кәгазь хисап көненәчә барысына да түзәр.
●Күпчелек кеше рухи азык дигәннәрен ашау-эчү әйберләренә караганда азрак куллана.
●Бармактан суырып язу фокус күрсәтүне аңлатмас.
●Иҗат әһелендә ихласлык кимеп китсә, аның илһам чишмәсе йомылырга мөмкин.
●Бәдән көчеңә өстенлек хаҗәт чакта акыл көчең сагаеп куяр.
●Кайвакыт акыллылык белән ахмаклык арасында да зур әһәмият бирерлек ачыш ясалырга мөмкин.
●Патша заманында татар гаиләләренең олы сулар тирәсеннән куылуына бәйләме – безләрнең милли музыкасында баркарола өслүбендә язылган әсәрләр чагыштырмача азрак.
●Көндәлек тормыштагы бихисап мәсьәлә мәктәптә укыган балаларча чишелә: йә дөрес итеп, йә хата ясап.
●Кайчак шундый һавалы режиссер кәмәше очрап куя ки, ул хәтта язмыш тәртибен дә үзенчә үзгәртер иде.
●Хәтта тәкъдир буенча аккан шәхси тормышыңда да син һәрвакыт баш герой була алмаска мөмкин.
●Сәхнәдә күпләр оста итеп уйный алмый, тәкъдир кушкан рольне күпләр яхшы башкара.
●Грим бүлмәсендәге язу: «Идиот роленә керсәң, аннан чыгарга онытма».
●Гадәти һөнәрчене «Алтын куллы!» дип мактагач,атаклы футболчының аяклары ирексез көнләшеп куячак.
●Зирәк кеше күңелсезлеккә таруын да бик кызыклы рәвештә сөйләп бирер.
●Мәңгелек турында уйланырга теләсәк, әүвәле җаныбызны тыңларга өйрәник.
●Яхшы әхлакый җирлектә генә күңел алгысып үсәргә мөмкин.

## III

●Омбудсмен: «Кеше хокукларын бозу ана карынында ук башланып китә, чөнки нарасый бу дөньяга үз ихтыяры белән килми».

# Салават һәм

●Олы Ыктамакта тарих музее да урнашкан сәнгать мәктәбе.

●Олы Ыктамак янындагы тау өстенә С.Юлаев һәм аның көрәштәшләре истәлегенә куелган һәйкәл. Анда хаксыз рәвештә Бәхтияр Салаватның ярдәмчесе дип күрсәтелгән.

●Красноуфимск крепостен саклаучы казак һәм туп һәйкәле.

**(Дәвамы. Башы 26 нчы санда).**

Мәчетле районының тарих музее Олы Ыктамактагы сәнгать мәктәбенең бер почмагында гына урнашкан. Аның мөдире Нәзирә ханымга Пугачев явында татарлар катнашуын тасвирлаган «Сәет батыр» атлы китабымны, бер кочак «Мәдәни җомга» газетасын бүләк иттем, атаклы Бәхтияр Канкай углын да искә алган булдым. Нәзирә ханым: «Бездә Бәхтияр исемен телгә алучы да юк шул!» – дип авыр сулады да тынды. Ялгышмаганмын, бирегә Бәхтияр исеме сыңар тыкрыкка да кушылмаган, музейда аның татар рәссамнары ясаган портретыннан күчермәләр дә юк. «Бәлки, туган авылында табылыр», дигән сукыр өмет белән Акага юл алдык.

Юлда Әзекәй дигән авыл янынннан үтеп китәсе бар, ул иң беренчел мәлдә Кече Ака атын йөрткән икән. Бәхтиярнең шушы Әзекәй, Урта һәм Олы Ака, Богалыш авылларыннан тәүге отряд туплап чыгуын тарихи документлар буенча нык хәтерлим. Алда Урта Ака дигән күрсәткеч ялтырауга ук, машинаны шул тарафка бордык. Олы һәм Урта Акалар бер-берсенә терәлеп диярлек тора, үзәк урамнары аша бер очтан икенчесенә өч чакрым барасы. Олы Аканың Советская урамында гына да йортлар саны 170 тән арткан. Бәхтиярнең Красноуфимск кирмәненә бер меңгә якын җайдаклы отряд җыеп килүе мәгълүм. Шушы урамнар буйлап яуга киткәннәр бит, дип уйланып, ялт-йолт каранабыз. Урта Акада XX гасыр башында төзелгән агач мәчет басып кала. Олы Аканың Ленин урамында моннан 150 ел чамасы элек калыккан һәм Факиһә исемен йөртүче таш мәчет бүгенге байларны да сокландырырдай төзек һәм сау-таза. Ләкин шул ук Ленин урамында элек Хафиз бай Хәбибуллин яшәгән ике катлы йорт хәзер җимерек хәлдә. XIX гасырда Петербургтагы Исаакий соборын төзү өчен йөз меңнәрчә тәңкәләк әбунә биреп дан алган татар баеның йорты революциядән соң да әле дистә еллар буена балалар бакчасы булып хезмәт иткән. Ныклап саный башласаң, Ака авылында җимерек һәм ташландык йортлар саны йөздән артып китә. Яңа йортлар берәнсәрән генә. Авылның эчкерәк урамнарында, Урта Акада асфальт бөтенләй юк. Авыллар читендә берникди мастерской яки ферма ише каралты-куралар күренми. Урта Ака урамында Екатеринбург номерлары таккан бер затлы машина белән «терәлешеп» үттек. Бәрәкалла, Ака авылларының күпчелек ир-егетләре 38 чакрымдагы Красноуфимск һәм аннан 50 чакрымдагы Екатеринбург калаларында эшләп йөри икән. Тора-бара, билгеле ки, шунда төпләнәләр. Ә Ака авыллары инде яртылаш бушап калган. Элеккеге колхоз җирләренең яртысын 8 чакрымдагы Габдулла авылы фермерлары сатып алган. Боларда, әйтик, безнең Балык Бистәсе районының Тәб. Чаллы авылындагы шикелле гаилә фермасын төзегән, брусчатка асауны көйләгән эшмәкәрләр дә юк. Бәхтияр чорында ил айкаган, кулында ут уйнаткан асыл ирләр нәселе коргаксыган...

Соңгы өмет белән мәктәпкә юнәләбез. Өч катлы мәһабәт бина капиталь ремонтка ябылган. Подрядчик булып алынган оешма берьюлы сигез объектта эш майтара, иң очсызы – дәүләт учреждениесе, ахрысы. Әүвәл килеп мәктәпнең тәрәзә-ишекләрен, түшәм-идәннәрен сүтеп ташлаганнар да, урам яктан беренче катын минераль мамыклы плитәләр белән тышлый башлаганнар. Мәктәп директоры Рәдис Әхмәтханов, аптыраганнан, чапкыч белән ихатадагы үләннәрне чабып йөри, борыны нык салынкы.

– Монда өч-дүрт ирне генә дежурга калдырдылар да баерак оешмага китеп югалдылар. Яңа уку елын яңартылган мәктәптә каршыларбыз, дигән хыял чынга ашмас сыман. Мәктәп эшләми тордымы, тагын дистәләгән бала йә район үзәгенә, йә Красноуфимскига күчеп китмәгә. Болай да мин 30 ел элек килгән чакта 350 баладан мәктәптә 128 укучы гына калды бит инде. Бетә, бетә безнең данлы Ака...

«Ата казыгыз күкәй саламы?» – дигән сыман итеп, Бәхтияр Канкай улы турында сораштырам. Җавап мәгълүм инде: «Сыңар тыкрык та аның исемен йөртми, каһарманлыгы турында да ишетеп белүче юк»...

Шушы авылда туып-үскән Булат Дәүләтбаев атлы филология фәннәре кандидаты 1992 елда «Олы Ака» атлы китап чыгарган булган, автор үзе ике ел элек вафат булырга да өлгергән. Китабында авыл тарихына багышланган файдалы мәгълүматлар да шактый, ләкин ул да Бәхтиярдән бигрәк Салават алдында тез чүккән, чөнки Башкортстанда «Салават иң бөегебез!» дигән бер мәдхия генә яшәүгә лаек шул. Үзем китапны укырга тырышам, ә эчтә ут. «Салават бригадир дәрәҗәсенә ирешкән, ә полковник Бәхтияр, көрәштәше булып, аңа буйсынып йөргән. Үзенең туган төбәгендә кечкенә отряд җыйгач, Салават Олы Акада туктап, 15 көн буена үз янына яңа яугирләрне туплаган... Салават Красноуфимскида да бер марҗа кызы белән типтереп алган, тегесе бала тапкач, аны бер авылдагы кешеләргә калдырып киткән, имеш...»

Салаватның хәтта Рогервик крепостенда да комендант кызы белән «типтереп», тегесенең «бала табуы» турындагы әкиятләрне моңа кадәр дә дистәләгән тапкыр укыган бар иде. Салаваттан мифик герой ясаулары тәмам шаккатыра. Кул-аякларына тимер зынҗыр тагылган, борыны киселгән, яңакларына һәм маңгаена «мөһерләр» сугылган Салаватның буе 147 сантиметр гына булган бит! Шул ир-атка дворян вә немец кызлары гашыйк булаламы? Нинди очсыз әкият сөю соң бу?!.

Бәхтиярнең язмышына кайтсак, ул 1773 елның октябрь аенда ук авылдашы Габделкәрим Күзкәев белән пугачевчылар сафына барып кушыла. «Падишаһ Петр Федорович хәзрәтләре»нең фәрманы буенча Бәхтияр – полковой старшина, Габделкәрим – йөзбашы дәрәҗәсе алып, 3 декабрьдә туган якларына отряд туплау һәм крепостьларны яулау өчен озатыла. Алардан бер атна чамасы соңрак полковник дәрәҗәсен һәм писарьлыкка татар егете Габдерәшит Галиевне ярдәмче итеп алган Салават та Оренбург янындагы Бирдәдән Шайтан-Көзәй волостена юлга чыга. Салаватка Себер юлындагы 19 волостьтан отряд туплау авыр бирелгәндер, чөнки ул хәтта бертуган Мөхәммәткилде, Якшыкбәт һәм Сөяримбәт Габдрәковлар гаиләсен өйләренә бикләп, үзенә буйсынмаган өчен яндырып үтерергә «мәҗбүр» була. Шулай да, Салават Себер юлындагы 7 старшинаны, шул исәптән Кущин волостендагы башкортлар башлыгы Илчегол Иткулов белән татар-мишәр старшиналары Габдулла Туктаров белән Сөләйман Күзкәевны үз отрядына кушып куюга ирешә.

Ә Бәхтияр әүвәл үзенең Кущин волостендагы Ака, Габдулла, Әзекәй, Богалыш авылларында йөзләгән җайдак туплый, аннары кул сузымында яткан Кызылбай авылында аны 400 дән артык яугир белән тулыландыра. Көнгер, Уса, Ижау, Пермь, Сарапул, Уфа, Минзәлә тарафларына да «падишаһ» эмиссарлары озатылган була бит, һәр якта фетнә уты кабына. Хөкүмәт карамагындагы вак отрядлар Көнгер белән Уфа калаларына бикләнә. Әле сугыш-фетнәләрсез чорда да казаклар саны 300 дән артмаган Красноуфимск крепосте тулысынча диярлек яклаучысыз-саклаучысыз кала. Бу хәбәрне Сарана һәм Сиргән заводларында яңа сугышчылар һәм корал-туплар җыеп йөргән Бәхтияр колагына да илтеп җиткерәләр. Бәхтиярнең Красноуфимскига төбәп килүен ишетүгә үк, крепость коменданты Н.Бахматов крепостьтан 18 чакрым ераклыкта, кулына ипи-тоз тотып, аны каршыларга чыга. Шунда ук Бәхтияргә бернечә ат, ике пистоль (турок) бүләк итәләр. 9 гыйнвар көнендә Бәхтияр отряды крепость эченә берники атышларсыз гына барып керә. Ләкин 1736 елда полковник Котлыгмөхәммәт Тәфкилев тарафыннан нигезләнгән крепость эчендә комендантан тыш сакчы-казаклар да бар бит әле. Шулар арасыннан комиссар Д.Попов, казак есаулары, аталы-улы Григорий һәм Афанасий Овчинниковлар, казакларның элеккеге атаманы Максим Калашник 4 тупны, 24 пот дары һәм ядрәне, шәраб һәм тоз сатудан тупланган акча (монета) тулы 96 күн капчыкны яшереп куйган булалар. Ул капчыкларны табып алуга ук, Бәхтияр әлеге дошманнарның барысын да зинданга ташлаттыра, үзе кирмәндә башлык рәвешен ала. Нәкъ шул көнне Бәхтияргә полковник (!) Салават кул астындагы отрядның Кызыл Ярдан 110 чакрымдагы Котыш авылында торуы турындагы хәбәрне җиткерәләр. Комендант Бахматов белән Бәхтияр аны Красноуфимскига килергә чакырып, 19 яшьлек чаң кагучы Макар Попов белән Әбләзи Саккулов атлы җайдакларны юллый.

12 гыйнвар көнне Красноуфимскига якынлашып килгән Салават отрядын крепостьтан 12 чакрымда, юл өстенә чыгып каршылыйлар. Бәхтияр Салаватка ике туп, атлар бүләк итә. Ләкин Красноуфимск эченә үтеп керүгә үк, Салават белән Бәхтияр арасында дошманлык башлана. Чөнки полковник дәрәҗәсендә булганга күрә, үзен күркәдәй хис иткән Салават, Д.Попов һәм М.Калашник биргән 100 сумлык ришвәт хисабына, әсирләрне зиндannan азат итә. Бәхтияр аларның дошман һәм шымчылар икәнен исбатлап ярсый башлагач, инде аның да 8 мылтыгын, 2 пистолен, 12 сум акчасын, 2 атын талап, үзен зинданга ыргыталар, хәтта дар агачына асып куюбелән дә янайлар. Башкорт отрядларының рус авылларын талап йөрүе турындагы хәбәрләр Пугачевның Уфадан 12 чакрымдагы Чесноковка авылында штаб башлыгы булган Чика-Зарубинга да барып ирешкән була. Милләтара ызгышны туктату өчен, Зарубин Красноуфимскига Иван Кузнецов атлы казакны махсус эмиссар итеп озатырга мәҗбүр була, ул «барча рус һәм азиат гаскәрләренең юлбашчысы» дигән дәрәҗә белән дә олылана.

15 гыйнварда Көнгергә юнәлсәләр дә, фетнәчеләр аны 19 ы көнне генә тәүге тапкыр штурмлап карый (Бәхтияр Салаватка иярми, февраль ахырына кадәр Красноуфимск крепостенда кала). Андагы бәрелешләр 26 гыйнварга кадәр сузыла, ахыр чиктә Гагрин һәм Папава җитәкчелегендәге карательләрнең берләштерелгән ике отряды фетнәләрне кала тирәсеннән куып

●Олы Ака авылында революциягә кадәр үк салынган Факиһә мәчете.

●Олы Акада ремонтка туктатылган урта мәктәп. Алда – аның директоры Р.Әхмәтханов.

# Бәхтияр ватанында

●Олы Акада элек Хафиз бай Хәбибуллин яшәгән ташландык йорт.

тарата. Салаватның исә яулар барышында аягы яралана һәм ул туган авылы Тәкәйгә кайтып китә. Карательләр Красноуфимск янына килеп җиткәч, Салават башлык итеп калдырган Гайнә волосте (бүгенге Барда районы) старшинасы Чүрә Рәсүлов һәм Түбеләс волосте старшинасы Собханкул Килтәков 30 гыйнвар көнне узган яуда әсирлеккә төшә (аларны 17 февральдә Көнгер каласында асып үтерәләр). 19 февральдә кабатланган яңа яуда Кызылбай авылыннан Салаватка кушылган башкорт старшинасы Илчеголның туганы Ишмән Иткулов һәлак була. Фетнәчеләр Красноуфимскидан 40 чакрымдагы Богалыш авылына чигенә. Богалыш янында җәза отряды башлыгы подполковник Папава белән бәрелешләр Салават кабат бирегә әйләнеп кайтканнан соң, 17 мартта янә кабатлана. Ләкин фетнәчеләр кулында кирәкле сандагы туплар да, алар өчен ядрә һәм дарылар да булмый, ахыр чиктә отрядлар авылларга тарала.

Салаватның башбаштаклыгы турында шикаять язган Бәхтияр, гаделлек эзләмәкче булып, Оренбург янындагы Бирдә бистәсенә юнәлә. Ләкин хәерчегә (һәм татарга) һәрчак җил каршы шул. Карательләрнең сугышчан генераллар кул астында юлланган ике зур армиясе, 23 март көнне бердәм һөҗүм ясап, Бирдә бистәсенә һәм Уфа янындагы Чесноковка авылына тупланган фетнәчеләр гаскәрен тар-мар итә. Башкорт гаскәрләренең баш атаманы Кинҗә Арсланов (Салават өстеннән дә башлык генерал!) тәкъдиме буенча, Пугачев үз янында калган биш йөзләп фетнәче белән Урал тауларына менеп кача. Падишаһны күрүгә ирешмәгән Бәхтияргә янә туган ягына, әүвәл бүгенге Кыйгы районына әйләнеп кайтырга туры килә. Ул кайтуга, Уралдагы әллә ничә крепостьны яулап Белоретта тукталган Пугачевтан яңа фәрман килеп ирешә. Бәхтияр яңа отряд туплаудан тыш, әле үз төбәгендә дары ясау өчен кирәкле күкерт белән селитра җитештерү эшен җайга салырга тиеш була. Табылган күкерт һәм дары Олы һәм Урта Ака, күршедәге Әзекәй авылларындагы аерым хуҗалык базларына туплана. Бәхтиярнең бу гамәлен полковник Салават колагына тишәләр, ул Кущин волостеның башкорт-лар старшинасы Илчегол Иткуловны юллый, тегесе исә Бәхтияр отрядына кушылган һәм дары туплауда катнашкан ирләрне камчылар белән тотып яра башлый. Ахыр чиктә яклау эзләп, Бәхтияр 9 апрельдә үз отряды белән рус атаманы Иван Белобородов командасына барып кушыла. Күрәсең, Бәхтияр белән Белобородов дары-күкертләрнең бер өлешен Пугачев гаскәренә дә җибәреп өлгергәндер. 28 апрельдә аларның икесенә дә полковник дәрәҗәсе бирелү турында «падишаһ» фәрманы килеп төшә. Берничә көннән соң алар Уклы-Карагай крепосте янында Пугачев гаскәренә килеп кушыла (Ә байтак еллар узганнан соң Олы Ака авылының базларыннан, идән асларыннан дистәләгән капчык дары һәм күкерт табалар, ләкин алар дым суырып, ташка әйләнгән була).

Бәхтияр май ае дәвамында Пугачев гаскәрендә хәрәкәт иткәннән соң, өч мең кешелек үз отряды белән Бөре каласы өчен сугышларга озатыла. Бу төбәктә хәрәкәт итүче отряд башлыкларыннан Елдәк крепосте мулласы Гадел Бигашев, Барда һ.б. төбәкләрдән килгән Аладин Биктуганов, Әбди Абдуллов, Арслан Рангулов, Балтач Сәетов (Бикмәт авылыннан), Бүләк Якупов, Габделҗәлил Рыскулов, Яркәй Кадермәтов (Яңавыл районының Ишбулды авылыннан), Бәйки Туйкиев полковник Бәхтиярне үзләренең юлбашчысы итеп кабул итә. Берләштерелгән биш мең кешелек гаскәр 5 июньдә – Бөре крепостен, 9 июньдә янәшәдәге Әнгәсәк шәраб заводын яулап ала. 15 июньдә бирелдәге фетнәчеләр гаскәрен куып тарату өчен полковник А.Якубович җитәкчелегендәге карательләр корпусы килеп җитә, ләкин Сатаниха авылы янындагы канлы яудан соң, Якубович кабаттан Уфага таба чигенеп качарга мәҗбүр була. Моннан тыш, әле Сукаяз, Тимкә, Туктар, Атар, Күрзә, Чалкак авыллары янында да карательләр ягына чыккан сатлык старшиналар туплаган отрядлар белән бәрелешләр була. Әмма Пугачев төп гаскәре белән июнь ахырында Уса, Көнгер, Воткинск, Ижау крепость һәм заводларын яулап ала. 23 июнь көнне ул С.Юлаев, К.Усаев һәм тагын 2 полковникны Башкортстан җиренә, яңа фетнә учаклары кабызу һәм Уфа каласына һөҗүм оештыру өчен озата. Шул көннәрдә Бәхтияргә дә аерым фәрман – Пугачев гаскәрен Уфа провинциясендә хәрәкәт итүче җәза отрядларының һөҗүменнән саклау бурычы җиткерелә. Бәхтияргә үз отряды белән Борай, Балтач, Яңавыл, Дүртөйле якларында хәрәкәт итеп, Пугачев гаскәренең тылын сакларга туры килә.

29 июньдә Пугачев Татарстан җиренә аяк баса. 4 июнь кичендә Бәхтияр дә өч мең кешелек отряд белән Мамадыш каласында «падишаһ»ның төп гаскәренә килеп кушыла. Җиңү артыннан җиңү яулап барган Пугачев янына иске таныш полковник килеп тез чүгү дә хуш килгәндер. Пугачев Бәхтиярне һәм аның писаре Әбүбәкер Теләчевны үзе тукталган йортта кунарга калдыра. Шул ук көнне аңа бригадир дәрәҗәсе бирә һәм икенче таңда, яңа отряд туплау һәм янә тылны саклап хәрәкәт итү өчен, Кама буендагы районнарга юллый.

Бәхтияр Мамадыш, Балык Бистәсе, Теләче, Питрәч районнары аша үтә һәм ике атнадан соң ук ике мең кешелек яңа отряд туплауга ирешә. Аңа Тегермәнлек авылы крестьяннары 96 кешелек отряд белән үзләре килеп кушыла. Аннары Бәхтияр Шиланка авылы крестьяны Гаврила Лихачев төзегән отряд белән берләшә, фетнәчеләр саны инде өч меңнән дә арта. Ләкин азатлык уты белән янган фетнәчеләр өчен дә кара төн якыная шул. 15 июньдә Казан янында Пугачев гаскәрен тулысынча тар-мар итәләр. Пугачев үзе Идел аръягына качып котылса да, ике мең крестьян яуда һәлак була, биш мең кеше әсирлеккә эләгә. Инде хәвеф узып китүен тоеп, җәзачы генераллар Кама буенда хәрәкәт итүче Бәхтияр отрядына каршы подполковник С.Неклюдов җитәкчелегендәге махсус корпус юллый. Бер-берсен күралмаучы ике көч әүвәл Балык Бистәсенең Байтирәк, аннары Мамадыш районының Җөри авылы янында бәрелешә. Сәнәк-чалгы белән коралланган крестьяннар туп-мылтыклы регуляр гаскәргә каршы тора алмый. Тар-мар ителгән отрядның бер өлеше Келәүш урманына кереп кача. Бәхтияр Канкаев та, аның белән бергә булган Габделкәрим Кузкәев, Халит Әминов, Габдулла Мостаев, Балтач Сәетов та билгесез рәвештә юкка чыга. Бәхтияр Әби патшаның 1775 елның мартында игълан ителгән гафу ителүчеләр исемлегенә кертелми, әмма ничек кенә эзләп карамасыннар, каһарман юлбашчыны таба алмыйлар...

Кабат Олы Ака язмышына кайтсак, Салават отрядына кушылган мишәр старшинасы Сөләйман Кузкәев 1774 елның җәй башында ук карательләр ягына чыга. Пугачев явы бастырылгач, генераллар Әби патшага «яуда 200 мең крестьян катнашты», дип рапорт юллый. Оренбург губернаторы да «фетнә барышында бездә 41 меңгә якын башкорт, 36 меңнән артык татар баш күтәрде», дип хисап тота. Бүгенге Мәчетле районының бер өлеше булган һәм составына Олы Ака авылы да кергән Кущин волосте буенча «Фетнәдә 573 башкорт катнашты», дип саны нык киметелгән рапорт бирәләр, әмма аның асыл составын тикшереп торучы булмый. Чынлыкта ул 573 санын С.Кузкәев кул астында йөргән 76 мишәр, Олы Акадан 42 типтәр, Кызылбайдан 26 мишәр, Габдулла авылыннан 57 типтәр дә тәшкил итә. Монда әле Урта Ака белән Әзекәй крестьяннары телгә дә алынмаган...

Волостьтагы идарә дилбегәсе карательләр сафына кушылган Сөләйман Кузкәев токымына күчә, аның улары гына түгел, хәтта оныклары да гомер буе йорт (берничә авыл) старшиналары һәм муллалар булып, халыкны талап яши. Галим тиешле А.Усманов әле 1945 елда ук «Салават батыр» атлы китап чыгарып, анда «Салават 15 көн буе Олы Акада туктап торган, аның монда штабы да булган, хәтта үзе киткәннән соң да, авылның бер йортында дары склады сакланып калган», дип язуга карамастан, әлеге уйдырманың шул сүзендә дә хакыйкать юк. Без югарыда вакыйгаларны бөртекләп хәбәр иттек, нәтиҗә чыгару – сезнең хөкемдәдер...

1834 елгы җанисәп вакытында Олы Ака авылындагы 134 йортта 998 җан иясе яши, аларның 761 е – мишәр, 202 се – типтәр, 35е башкорт катламына языла. 1859 елда халык саны инде 1417 гә җитә. Ләкин мөселманнарның бу рәвешчә үрчүе тәхет һәм Синод хуҗаларының үтенә тия, ахры, XIX гасырда ук алар Кущин, Дуван, Тырнаклы, Морзалар волостьларына аеруча Пермь төбәгендә яшәүче урыс крестьяннарын күчереп һәм татар авыллары белән аралаштырып утырта башлый. Җир дә – бер үк, адәм баласының куллары да фәкать икәү генә, ләкин менә Ыктамак урыслары елына – 3 сум 33 тиен, ә типтәр һәм мишәрләр бер тәңкәгә күбрәк ясак түләргә мәҗбүр ителә. Бүген дә Татарстан ел саен берәр триллион сумга кадәр салымны үзәккә озатып, урыс өлкәләрен туендырып яши. Тарих тәгәрмәче алга тәгәри, тик аның тешләре безнең бугазга басып әйләнә шул һаман...

Бәхтиярнең эзе һәм истәлеге Красноуфимск каласында беркеп калмаганмы? – дигән өмет белән без Екатеринбург өлкәсенә дә барып кайттык. Салават исеме бар, хәтта аны Сарапулны яулап алган, дип тә күзгә төтен җибәрәләр. Ә Красноуфимск, Бөре калаларын тәүге булып яулаган татар каһарманы турында сыңар сүз дә юк. Шулай, «ир какканны – мир какканн», дип дөрес әйтәләр ул. Үзебез кадерен белмәгәч, кайсы милләт зынҗырлы татар халкының каһарманын күккә чөйсен инде?..

**Вахит ИМАМОВ.**
**Автор фотолары.**

● Җиргә төшкәннән соң.

# ГАГАРИННЫ ТАТАРЛАР

**Җиргә әйләнеп кайткан Ю.Гагарин Саратов өлкәсенең Тарновка районындагы Смеловка авылы янына, Шевченко исемендәге колхозның сөрелгән кырына килеп төшә...**

1964 елда нәшер ителгән «Космонавты рассказывают» китабының 37-38 битләре. Анда Юрий Гагарин тарафыннан язылган «Вижу Землю» бүлегендә мондый җөмләләр бар:

«Җете кызыл-сары скафандрда мин сәер булып күренгәнмендер, ахры. Җирдә очраткан тәүге кешеләр - бер хатын-кыз һәм кыз бала - миңа якын килергә курыкты. Алар Анна Акимовна Тахтарова һәм аның онкгы Рита иде. Аннары кыр буйлап механизаторлар йөгерешеп килде, без кочаклаштык, үбештек. Космоста үткәргән ике сәгатькә якын вакыт эчендә, радио биргә дә, Җирнең бар почмакларына корабль очышы хәбәрен җиткергән. Мине каршы алучыларга минем фамилиям билгеле иде инде.

«Восток» язгы сулар шаулап аккан тирән чокырдан берничә дистә метр читкә төште. Корабль караланган, янган, ләкин шушы рәвешендә ул миңа очышка кадәргедән дә матуррак һәм якынрак булып тоела иде.

Урман каравылчысының оныгы Рита Тахтарова хәзер инде мәктәпкә йөри. Мин аның һәм әбисенең космостан әйләнеп кайткач мине каршы алган беренче кешеләр булуын беркайчан да онытмаячакмын».

Космонавтның әнисе А.Гагаринаның 1983 елда, үзе исән чакта нәшер ителгән «Слово о сыне» китабында да шул ук сүзләр: «Әй Юраның җирдә беренче күргән кешеләре – урманчы хатыны Анна Акимовна Тахтарова белән аның оныгы Рита булган. Шушы урында ул сөйләвен бүлеп: «Синең адашың, әни!» – дип билгеләп үтте... Чуар бозау янында бу хатын-кыз оныгы белән Юрага кызыксынып карап торган, аннары кыюсыз гына аның янына юнәлгәннәр».

Ю.Гагаринның үзе исән-сау чагында, 1961 елда ук нәшер ителгән «Дорога в космос» китабында да әлеге тарихи вакыйга искә алынган.

Мәскәүнең Космонавтика музеенда, Смоленск өлкәсендәге Гагарин шәһәренең Ю.Гагарин музей-тыюлыгында үткәрелүче экскурсияләрдә дә, алар күрсәткән документаль фильмнарда, һәммә җирдә... шушы ук хәл раслана. Бу дәлил Гагаринның ихлас кеше булуын раслый. Чөнки аның Җиргә әйләнеп төшкән беренче сәгате хакындагы информация, аның үзе тарафыннан язылып, махсус инсаннар булышлыгы белән редакцияләнгән беренче китаплары... башкачарак башланып китәргә дә мөмкин замана бит. Шушы дәлилләргә матбугатта очрамаган бер тарихи фотосурәтне дә өстәргә кирәк. Әлеге фотосурәтне Саратов өлкәсенең туган як музее хезмәткәрләре юллады. Бу 1965 елның гыйнварындагы тарихи вакыйга сурәтләнгән фотография әлеге музей фондында саклана. Аңлатмасы шушы: «Ю.Гагарин Космостан Җиргә әйләнеп төшкән урынында. Аның янәшәсендә КПССның Саратов өлкә комитетының беренче секретаре Алексей Иванович Шибаев, уң якта космонавтның җәмәгате Валентина Ивановна. Уртада – Ә.А.Тахтарова».

●Беренче космонавт янәшәсендә – Саратов өлкә комитеты беренче секретаре Алексей Шибаев, үзәктә – Ә. Тахтарова, уңда – Ю. Гагаринның хатыны Валентина. 1965 ел гыйнвары.

Җиргә әйләнеп кайткан Гагаринны иң беренче булып күргән татар кызы Румия Нурсканова белән күрешергә ниятләгән идек тә бит, ләкин 2021 елның 30 июнендә ул якты дөньядан киткән булып чыкты...

Планетаның иң тәүге космонавты, галәмнән исән-сау әйләнеп кайта алган Ю.Гагаринга карап әйтелгән беренче сүзләр – Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Гагаринга карап мөселман догаларын укыган ханым – Әнихәят Аким кызы Тахтарова – шушы Саратов өлкәсенең Смеловка авылы янында үз йортлары белән яшәгән татар хатыны. Әнихәят ханымның оныгы Румия 1961 елның 12 апрелендә кечкенә бала булган әле. Румия Кудашова – 1956 елның 27 июлендә туган, милләте буенча татар. Кечкенә булуына карамастан, Румия бу көнне бик яхшы истә калдырган! Якты хатирәләрен үзенең мөңнәрчә чыгышларында, әңгәмәләрендә яңарткан. Ни өчен Гагарин аның әбисен Анна исеме аша хәтердә калдырган дип уйласак, шулкадәр авыр очыштан соң ук каһарман зат беренче күргән хатын-кыз исемен үзенең газиз әнисе исеме белән бәйләп истә калдырырга тырышкан, минемчә. Моны аңлау өчен Гагарин очышының ничек башланып, ничек тәмамлануы, аның нинди авырлыкларга таруы хакындагы мәгълүматларны уку да җитә. Бу очракта ул язган китапларның цензура аша үтүен дә искә алырга кирәктер...

Румия Нурскановaның ягымлы тавышы, мөлаем йөзе, хатирәләре... барысы да видеоязмаларда гына сакланып калган. Шулардан өзек:

«Ул көн бик гадәти генә башланып китте. Әбиемә ияреп бакчага чыктым һәм аңа бәрәңге утыртырга булыша башладым. Әбием җир казый, ә мин чокырларга бәрәңге салам... Көн гаҗәеп җылы һәм көяшлы. Кечкенә бала булганга күрә, бераздан бәрәңге утыртудан ялкып, барлык балалар кебек үк, уйныйсым килде. Мин башымны боргалап, як-якка карана башладым. Кинәт күктән җиргә таба кызыл төстәге ике әйбер очып төшүен күреп алдым. Һәм: «Әбием, кара, Күктән ике кызыл баш төшә!» – дидем. Ул чакта мин татарча гына сөйләшә идем. Ләкин әбием моңа гомумән игътибар итмәде, ышанмады да, уем уенда булуны ошатмыйча, фантазияләрем өчен ачуланып: «Күккә карама, бәрәңге утырт!» – диде. Ләкин мин барыбер шул шарлардан күземне алмадым, чөнки ул якты, матур күренеш

● Әнихәят Тахтарова үзенең оныгы Румия белән.

# КАРШЫЛАГАН

● Сулда Әнихәят ире белән. Румия Гелий Непогодин кулында.

иде. Хәтта алар белән бераз уйный да башладым: мин кыр буйлап йөгерәм, алар да минем арттан бара, мин туктап торсам, алар да туктап тора кебек тоелды миңа ул чакта. Ягъни мин хәрәкәтләнсәм, алар да хәрәкәтләнә кебек... ә бер мизгелдә мин аларны үзем үк хәрәкәткә китерәм төсле булып та тоелды әле.Тагын шунысы да истә: ул көнне көчле шартлау тавышы ишетелде, күкнең яртысы кызыл төскә кереп, яктырып китте... Мин бәрәңге утыртыша башладым, игътибарымны башкага юнәлттем һәм ул объектны онытып бетердем. Бераздан әйләнеп карасам: кырда бик күп баулар ята, һәм кызыл-сары төстәге ниндидер җан иясе... җирдән күтәрелә иде. Белмим, ул чак башыма нинди уйлар килгәндер... Хәзер инде мин аның кеше булуын беләм... Ә ул чакта, билгеле, аңламадым. Аннары кызыл-сары киемле шул ниндидер бер «нәрсә», гомумән, кем икәне аңыма сыймаслык зат кыр буйлап безгә таба атлап килә башлады. «Минә Күккә карарга теләмәгән идең, менә хәзер кара инде! Ул үзе безгә таба килә!» – дидем мин әбием Әнихәяткә. Шул да исемдә, баштарак мин бу заттан бер тамчы да курыкмадым. Бала күңеле бит бар дөньяны игелек аша кабул итүчән. Аякларын киң итеп куеп, аяк-кулларын сәер хәрәкәтләндереп, авыш-түешрәк адымнар белән безгә таба атлап килүче затны күргәч, әбием аңа карап: «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!» – диде. Мине кулымнан тотып алды да, догалар укый башлады. Әйе, әбием ул чакта Юрий Гагаринга туп-туры карап, мөселман догаларын укыды. Моны күргәч кенә, мин дә куркып калдым. Чөнки әбием догаларны куркыныч булган очракта гына укый иде. Аннары әбием мине кулымнан тоткан килеш кире борылды, без агачлыкка таба йөгерә башладык. Ни дисәң дә, йортыбыз янында тынычрак булачак. Бу урында шул хакта да әйтергә кирәк: без яшәгән өйдә телевизор, радиоалгыч юк иде. Смеловка да йортыбыздан ерактарак, тирә-якта колхоз кырлары гына. Дәү әтием Ибраһим белән дәү әнием Әнихәят үзләре генә яши, ә мине аларга кунакка кайтарып куйганнар иде. Дәү әтием ул көнне агач үсентеләрен карарга китте. Без дә бортында кеше булган беренче космик корабльнең Күккә очуы турында ишетмәгән идек. Гомумән, илдәге яңалыкларны без соңрак белә идек.

Мин Юрий Гагаринны чыннан да бу Җирдәге кешеләр өчен мәгълүм булмаган берәр заттыр дип уйладым. Без йөгереп киткәч, шул чак әлеге гомер күрмәгән зат безгә атап кычкырды: «Мамаша, стойте, свои!» Бу сүзләрне ишетүгә, мин әбием Әнихәяткә: «Әбием, тукта, ул русча сөйләшә. Кешедер, бәлкем!» – дидем. Без туктадык. Әбием кире борылды һәм без агачлыклар яныннан чыктык, ләкин аңа таба бер адым да атламадык. Аның безгә кадәр килеп җиткәнен көттек. Тавышы тонык булып, кисмәктән чыккан кебек ишетелсә дә, без инде аннан беренче мәлдәге кебек курыкмый башладык.

Әлеге зат безнең янга килеп җитте. Әбием, аның үтенече буенча, гермошлемын ычкындырырга да булышты. Шуннан соң безгә аның йөзе ачылды. Без бик арган, ләкин шулай да бик сөйкемле кеше йөзен күрдек. Аның тавышы да бик матур, йомшак, бәрхет тавыш, елмаюы да игелекле иде. Һәм без куркырга сәбәп калмавын аңладык. Юрий Алексеевич әбиемнән:

– Сезнең исемегез ничек? – дип сорады.

Әбием:

– Мин – Әнихәят Акимовна Тахтарова. Урманчы хатыны. Ә бу – минем оныгым, – диде.

Шуннан соң ул миңа карап:

– Ә аның исеме ничек? – дип сорады.

Әбием:

– Румия! – диде.

Юрий Гагарин минем исемемне аңадан кабатлап сорады: «Ничек?» Ахрысы, ул минем татарча исемемне бик аңлап бетермәде. Шуннан соң әбием:

– Мәктәп өчен русча исеме дә бар аның – Рита, – диде.

Гагарин үзенең барлык интервьюларында да диярлек мине Рита дип искә ала башлады. Мин тарихка шушы исем белән кереп калдым.

Ә әбием аннан:

– Ә син кем? Кайдан син? – дип сорады.

– Мин корабтан... – дип җавап бирә башлады Гагарин.

– Нинди кораб? Бирердә су да юк бит безнең.

Әбием аның сүзләренә ышанып бетмәде яисә үзенең дә шул корабны күрәсе килде, ахрысы...

Гагарин әбиемә:

– Мин – күктән. Мин сезгә кабинамны күрсәтермен, әйдәгез киттек, – диде.

Шуннан соң әбием Юрий Гагарин белән ул күктән төшкән капсула янына таба атлады. Мин дә аларга иярергә, артларыннан йөгерергә теләгән идем дә, ләкин шулвакыт бозавыбыз чиләктәге, утыртырга дип ярган бәрәңгене ашарга кереште. Моны күргән әбием миңа бозауны сакларга, бәрәңгене аңа ашатмаска кушты. Шулай итеп, бәрәңгене саклап калдым. Ул мизгелләрдә бәрәңге әбием өчен барыннан да кадерлерәк булган, күрәсең.

Әбиемә капсула эчендәге кнопкаларга кадәр иелеп, кулы белән күрсәтү, читен булгандыр. Соңрак Әнихәят әбием болай дип сөйләде: ул Гагариннан рөхсәт сорап, читенсенеп тормыйча, капсула-кабина эченә кәлүшле аякларын тыккан һәм аяклары белән кнопкаларга төртә-төртә күрсәтеп: «Бу нәрсә? Ә бу нәрсә өчен кирәк?» – дип сорашкан. Гагарин да әбием сорауларына җавап биреп, күпмедер аңлаткан.

Гагарин әбиемнән: «Мин кайдан үзем турында хәбәр итә алам? Сездә кайда да булса якында телефон бармы?» – дип тә сораган. Әбием исә: «Безнең Смеловкада телефон бар, ләкин анда кадәр машина белән барырга кирәк. Машина юк. Безнең атыбыз, арбабыз бар. Әгәр дә җигәргә булышсаң, ат белән Смеловкага илтеп куярмын», – дигән. Ә Юрий Алексеевич: «Мин, әлбәттә, ат җигә беләм. Ләкин бу – озак, миңа үзем турында тизрәк хәбәр итәргә кирәк», – дигән.

Алар кайтуга таба юнәлгәч, күктән нидер төшүен ишеткән колхозчыларның безгә таба йөгерүен күрдем. Менә шулчак мин куркып еладым, чөнки аларның йөгерү сәбәбен аңламадым... Халык дәү әнием белән Юрий Гагаринны уратып алды. Мин үзем дә шул якка таба йөгердем, халык төркеме арасыннан үтеп, уртага кердем. Карыйм: Гагарин инде җирдә, парашютлар өстендә ята, аның скафандрыннан, куллрыннан нидер ычкындыралар... Аннан соң тирә-юнь хәрбиләр, машиналар белән тулды, вертолет та очып килде...»

Әнихәят Тахтаровага ул вакытта 44-45 яшь булган. Гагарин үз китабында Ә. Тахтарованы, Румияне күргәч, үзен бик бәхетле сизүен, хәтта дулкынлану хисе кичерүе турында язган.

«Ә без моның планета өчен нинди зур вакыйга булуын бик аңламадык та, – дип искә алган Румия ханым. – Әти белән әни Энгельста эшли һәм аена бер тапкыр гына кайта иде. Бу вакыйгадан соң өч көн үткәч, әтием белән әнием газеталар алып кайтты. Фотосурәтләребез урнаштырылган газеталары күрсәтеп, әти-әнием безгә: «Менә нинди тарихка кердегез сез! Менә кемне күрдегез!» – диде.

Румиянең әнисе – Агильшира Садр кызы. Әтисе – Әбдрәшит Мәхмүд улы. Кудашевлар өч бала үстергән: Румия – 1956 елны, Нурия – 1957 елны, Шамил 1959 елны туган. Кызганыч, хәзер аларның өчесе дә исән түгел. Бу хакта миңа Румия ханымның ире, Амангали Кайрадин улы Нурсканов әйтте.

Румия Әбдрәшит кызы болай дип тә искә алган: «Гасыр вакыйгасы – Җир шары тирәли орбиталь очыш ясап кайткан Гагарин нәкъ янібызга төшкәннән соң, безгә күп журналистлар килә башлады. Әбиемнең кан басымы күтәрелә, ул инде өйдән дә бик чыгарга тырышмый. Ә журналистлар сүзләрен: «Без сезгә бүләкләр дә алып килдек», – дип башлый иде. Әбиемнең бүләкләргә исе дә китми, ә без, балалар, сөенә идек. Шул сөенүләребез хакына гына әбием өйдән чыга да иде инде.

Мин үземне Рита дип тә таныштыра идем. Чөнки бу исемне миңа Гагарин бирде бит! Шуңа күрә ул исем минем өчен кадерле иде. Өйдә дә, мәктәптә дә: «Миңа Рита дип дәшегез», – дим. Без гаиләдә татар телендә генә сөйләшә идек. Гагарин турында да сөйләргә кирәк булганга күрә, әти-әнием мине русча яхшы сөйләшергә өйрәтте. Мәктәптә класстан класска йөртеп, бу тарихи вакыйга турында һәр ел саен кабатлатып сөйләтәләр иде».

1962 ел якынлашканда, Ю. Гагарин радио аша Саратов халкына мөрәҗәгать итеп, болай дигән: «Ул истәлекле көнне мине Җирдә каршылаган беренче кеше Анна Акимовна Тахтарова булды. Җиргә кадәр баш иям сезнең алда, Анна Акимовна! Оныгыгыз Ритага да сәлам! Котлавыгыз өчен рәхмәт! Хат юлладым. Сез аны алгансыздыр инде. Ә хәзер мин сезгә мөрәҗәгать итәм, Саратов аэроклубы очучылары һәм курсантлары! Инде күп тапкырлар әйткәнем булды: бернәрсә белән дә чагыштырмаслык очу халәте шатлыгын беренче тапкыр сездә – Саратов җирендә татыдым. Мондый вакыйгалар гомерлеккә истә кала. Беренче тапкыр миңа күккә күтәрелергә булышучыларның һәммәсенә тирән рәхмәтләремне җиткерәм! Кем белә, бәлкем, нәкъ менә сезгә, саратовлыларга, тагын бер тапкыр космик кораб пилотларын каршыларга туры килер. Яңа очышларга инде ерак булмыйча, шундый очрак туры килсә, һәм мин янә искиткеч Саратов җирләренә төшсәм, миңа үзгезнең Идел буендагы кунакчыллыгыгызны күрсәтерсез инде. Ә әлегә сау булыгыз. Очрашканга кадәр!» Әлеге мөрәҗәгатьнең аудиоязмасы әле дә кадерләп саклана.

**(Ахыры киләсе санда).**

*Зилә* **НИГЪМӘТУЛЛИНА.**

АТНАНЫҢ СӘЯСИ МИЗГЕЛЛӘРЕ

## ӘЛЕ БАШЛАНМАГАН ДА ИКӘН

Россия тышкы эшләр министры С.Лавров узган җомгада «егермелек» (G20) илләре тышкы эшләр министрларының Балида (Индонезия) үткән утырышында катнашты. G20 төркемендә бүген рәислек иткән Индонезия утырышның көн тәртибенә ике мөһим теманы хәл кылырга тәкъдим иткән: дәүләтләрнең күпьяклы хезмәттәшлеген ныгыту; азык-төлек һәм энергетика иминлеге өлкәсендәге яналарга бергәләп җавап бирү. Әмма очрашуда ике теманың берсе буенча да уртак фикергә килә алмаганнар. Соңыннан үткәрелгән матбугат очрашуында С.Лавров боларның барысы өчен дә Көнбатыш илләрен гаепләгән. Аның әйтүенчә, алар БМО уставын какшата һәм дөньяви тәртипкә дә начар йогынты ясый икән. Көнбатыш илләрен ул әлеге очрашуны да «шашынган русофобия»не күрсәтү урыны итәргә тырышуда гаепләгән, сессиядә сүз алуга, Украинадагы хәлләргә күчеп, Россияне шунда ук «агрессоры, захватчики, оккупанты» дип тәнкыйтьли башлыйлар, дип зарланган. Ә очрашуда, чыннан да, Россиянең Украинада үткәрә торган хәрби операциясенә тискәре мөнәсәбәттә булу сәбәпле, күп кенә илләр С.Лавровка бойкот игълан иткән: аның белән уртак фотога төшмәгән, ул катнашкан чараларда катнашмаган, эш нәтиҗәләре буенча уртак коммюнике да хәтта кабул ителмичә калган. Күпләр әлеге хәлне башкача да бәяли. Алмания тышкы эшләр министры А.Бербок, әйтик, киресенчә, G20 илләре белән диалог вә хезмәттәшлекне дәвам итәргә теләмәүдә С.Лавровның үзен гаепли һәм моны аның, беренче сессиядә өлешчә генә катнашып, икенчесенә бөтенләй дә килмәве белән дәлилли.

Игътибарны, әлбәттә, Россия президенты В.Путинның Дәүләт Думасы җитәкчелеге һәм фракция лидерлары белән очрашканда әйткән сүзләре дә җәлеп итә. Украинадагы хәлләргә карата ул: «Сегодня мы слышим, что нас хотят победить на поле боя, ну что тут сказать, пусть попробуют. Мы уже много раз слышали, что Запад хочет воевать с нами до последнего украинца. Это трагедия для украинского народа, но, похоже, все к этому идет. ... Все должны знать, что мы по большому счету всерьез пока еще ничего не начинали», - дип кисәтте. Моңа Киевтән дә шундый ук өслүбтәге җавап алынган булып чыкты. Украина дәүләт иминлеге һәм саклану шурасы секретаре А.Данилов «Твиттер»да үзенең Көнбатыш коралын куллануга кагылышлы фикерен: «И это мы еще не начинали», - дип төгәлләгән... Бу атнада Россия, Украина һәм Төркия Истанбулда БМО химаясендә Украинадан Кара диңгез портлары аша ашлык чыгару буенча очрашу үткәрде. Россия-Украина сөйләшүләре өзелгәннән соң, бу ике арада күзгә-күз карап үткәрелгән беренче сөйләшү дә булган.

**Фоат УРАЗАЙ.**

# Ташларда

## (Ш.МӘРҖАНИ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНЫҢ ТАТАР ЭПИГРАФИК МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ)

Соңгы елларда тарихи-мәдәни истәлекләргә игътибар артты. 2009 елда Казанда Бөтенроссия тарихи һәм мәдәни истәлекләрне саклау җәмгыятенең Татарстан бүлеге ачылды, 2018 елда ТР Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты оешты. Әлеге оешмалар республикада яшәүче халыкларның мәдәни мирасын саклау, популярлаштыру өлкәсендә зур эшчәнлек алып бара, әмма эпиграфия белгечләре булмау сәбәпле, татар эпиграфик истәлекләрен ачыклау, өйрәнү эшләрен башкара алмый. Болар белән, нигездә, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ТР Милли китапханәсе хезмәткәрләре шөгыльләнә.

2015 елда Мәрҗани исемендәге Тарих институтында ТР халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге ачылды һәм анда эпиграфик истәлекләр эзлекле һәм күләмле рәвештә өйрәнелә һәм популярлаштырыла башлады. Моның өчен ел саен татарлар яшәгән төбәкләргә эпиграфик экспедицияләр оештырыла, чөнки әби-бабаларыбыздан сакланып калган бер генә эпиграфик ядкәрне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый.

Институттагы иң яшь бүлекнең тәүге мәртәбә өйрәнгән төбәге Арча районы булды. Андагы татар авылларының зиратларында һәм аерым каберлекләрендә хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча сакланган ташъязма истәлекләрне барлау, өйрәнү өчен 2015 елның яз һәм көз айларында берничә фәнни экспедиция оештырылды. Аларның барысында да шушы юллар авторы гына катнашты. Эш барышында 1939 елга хәтле вафат булган кешеләргә куелган гарәп язулы кабер ташларының һәрберсен табып, фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Барлыгы 93 авыл зиратында 1288 борынгы кабер ташы табылды. Иң күп ташъязма истәлек ачыкланган авыл Яңа Кенәр булды (154 таш), чөнки анда өч зират бар. Икенче урында Түбән Оры саласы: 116 ташбилге. Иске Ашыт авылының ике зиратында 112 борынгы кабер ташы сакланып калган. Кызылъяр, Яңа Кишет, Югары Оры авылларында да шактый күп эпиграфик истәлек табылды. Без ачыклый алган иң борынгы кабер ташы Казан ханлыгы чорына туры килә, 1520–1521 елларга карый. Эшебезнең нәтиҗәсе булып, 2016 елда «Арча районы эпиграфик истәлекләре» дигән китап дөнья күрде. Шулай ук кайбер борынгы ташбилгеләр хакында мәгълүмат рус телендә нәшер ителгән «История селений Ашитского джиена Заказанья» коллектив монографиясендә дә китерелде.

Әтнә районы эпиграфик максатта тулысынча өйрәнелмәгән иде, андагы татар авылларының зиратларында һәм аерым каберлекләрендә хәзерге көннәргә кадәр сакланган бөтен ташъязма истәлекләрне ачыклау өчен 2016 елның яз һәм көз айларында без институтның фәнни хезмәткәре С.Р.Хәмидуллин белән бергә берничә фәнни экспедициягә чыктык. Барлыгы 48 авыл (юкка чыкканнарын да кертеп) зиратында 1567 борынгы кабер ташы табылды. Иң күп ташъязма истәлек ачыкланган авыл Олы Әтнә булды (ике зиратында 200 таш). Икенче урында Олы Мәңгәр саласы: 85 ташбилге. Иске Өҗем авылында 82 (икесе авыл басуында) эпиграфик истәлек сакланган, димәк, әлеге сала ташлар саны буенча өченче урында. Югары Бәрәскә авылы хәзерге вакытта Түбән Бәрәскә составына кереп, атамасын югалткан, шул сәбәпле, әгәр дә аларны бергә кушып санасак (Югары Бәрәскәдә – 47, Түбән Бәрәскәнең ике зиратында – 47 таш), барлыгы 94 борынгы кабер ташы сакланган. Яңа Өҗем, Кышлау, Мамыш, Олы Бәрәзә, Күлле-Киме, Күңгәр, Күәм, Иске Йогып авылларында да шактый күп эпиграфик истәлек табылды. Иң борынгы кабер ташы Казан ханлыгы чорына, 1476–1477 елларга карый. Гомумән, Әтнә районында XV–XVIII гасырга караган җиде дистәгә якын эпиграфик истәлек яки аларның фрагментлары бүгенге көнгә хәтле сакланган. Экспедицияләрнең нәтиҗәләре 2017 елда нәшер ителгән «Әтнә районы эпиграфик истәлекләре» китабында урын алды. 2015-2016 елларда ТР Фәнни китапханәсе хезмәткәрләре Р.Мәрданов һәм И.Һадиев эпиграфик максатта Әтнә районындагы ташъязма истәлекләрне тикшергән, әмма алар барлыгы 1477 ташбилге генә таба алган. Димәк, калган 90 таш (шул исәптән Казан ханлыгы дәверенә караган кайбер кыйммәтле ядкәрләр) алар игътибарыннан читтә калган.

Мәркәзебез Казанда сакланган зиратлар ни өчендер галимнәр тарафыннан бик аз өйрәнелгән иде, фәкать борынгы эпиграфик истәлекләрнең берникадәр өлешен генә кайбер белгечләр фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән. Анда сакланган бөтен татар ташъязма истәлекләрен барлау өчен, 2017 елның апрель-июнь айларында институт тарафыннан экспедиция оештырылды. Анда А.Гайнетдинов, А.Ногманов, С.Хәмидуллин, О.Владимиров катнашты.

Казанның Бишбалта бистәсендәге татар зиратын өйрәнгәннән соң, анда барлыгы 25 борынгы кабер ташы (шул исәптән фрагментлары) табылды. Без зиратта хәзергәчә сакланган барлык эпиграфик истәлекләрнең текстларын укыдык, тулы каталогын төзедек һәм 2018 елда үз хисабыбызга «Казанның Бишбалта бистәсе эпиграфик истәлекләре» дип аталган китапны чыгардык. Бистә зиратының Казан ханлыгы дәверенә каравы хакында фаразлар булса да, хәзер анда бу чорларга нисбәтле эпиграфик истәлекләр сакланмаган. Иң борынгы ташлар эшләнеше һәм палеографик билгеләре буенча XIX гасыр ахырына карый, аларының да, ватылу сәбәпле, күбесенең текстларына зыян килгәнгә күрә, төгәл куелу елын ачыклап булмый. Датасы язылган ташлар арасында иң борынгысы 1910 елның апрель аена карый. Кемгә куелганлыгы билгесез, чөнки аның өске өлеше – исеме язылган урыны ватылган.

Казанның Дары бистәсендәге татар зиратында 146 борынгы ташбилге ачыкланды. 1929 елга хәтле вафат булган кешеләргә куелган гарәп язулы кабер ташларының һәрберсен табып, фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Бистәдә сакланган иң борынгы эпиграфик истәлек 1841 елга карый. Ул шул елда вафат булган Әхмәди Габдерәхим улы каберенә куелган. Шулай ук 1843 елда вафат булган Маһи Рәхмәтулла кызына куелган кабер ташы да иң борынгыларыдан саналырга хаклы. Зираттагы ташбилгеләрнең текстлары, фотолары «Казанның Дары бистәсе эпиграфик истәлекләре» китабында 2019 елда дөнья күрде.

Татар халкының төп некрополе башкалабызның Яңа Татар бистәсендә. Бирелә миллләтебез үсешенә өлеш керткән атаклы шәхесләр җирләнгәнлектән, андагы эпиграфик истәлекләр – галимнәр өчен иң кыйммәтле өйрәнү объектлары. Бистә зиратында без барлыгы меңъ ярымга якын ташъязма истәлек таптык. 1330 кабер иясенең исемнәре ачыкланды һәм исемлеге төзелде. Йөздән артык ташбилгеләрнең кемгә куелганлыгын ачыклап булмады, чөнки алар инде ватылган һәм текстларына зыян килгән, күбесенең фрагментлары гына сакланып калган. Шул ук вакытта, тарихчылар Е.В.Липаков һәм Е.В.Афонина бөтенләй югалган дип санаган эпиграфик истәлекләр (мәсәлән, педагог Ш.Әхмәров, сәүдәгәр И.Юнысов һ.б. кабер ташлары) дә ачыкланды. Яңа бистә зиратындагы иң борынгы кабер ташы 1813 елга карый, ул

# – тарих

сәүдәгәр Йосыф Бикбау улына куелган. Шулай ук 1823-1824 елларда вафат булган Салих исемле кешенең һәм билгесез ир-атның кабер ташлары да чагыштырмача борынгы. Хәбибҗамал Исхак кызына куелган кабер ташы исә 1825 елга, Мортаза Нәзир улыныкы 1826 елга нисбәт ителә. 1820 елда бакыйлыкка күчкән Бибизөләйха Муса кызының, 1825-1826 елларда вафат булган Бибизөһрә Йосыф кызының кабер ташларын да югарыда искә алынган ташлар белән бер рәткә куяр идек, тик аларныкы XIX гасырның 30 нчы елларында куелган. Иң күп ташлар 1921 елга карый. Бу аңлашыла да, чөнки бу вакытта зур ачлык булган. Бистә зиратында бик күп атаклы шәхесләргә куелган истәлекләр табылды. Мәсәлән, олуг галимнәребез Ш.Мәрҗани, Г.Баруди белән бәйле кабер ташлары, шулай ук Аитовлар, Апаковлар, Апанаевлар, Әҗимовлар, Борнаевлар, Замановлар, Субаевлар, Үтәмешевлар, Юнысовлар, Яушевлар һ.б. мәшһүр татар нәселләренә нисбәтле затларның ташбилгеләре сакланган. Зират эпиграфик планда тикшерелде, дип санарга тулы нигез бар. Мәгълүм ки, мәшһүр галимебез Ш.Мәрҗани, аның хатыннары, балалары, оныклары Казанның Яңа бистә зиратында, ә ата-анасы, әби-бабасы, туганнары Арча төбәгендә җирләнгән. Җыелган материал нигезендә 2018 елда галимнең 200 еллыгына багышланган «Мәрҗани белән бәйле эпиграфик истәлекләр» китабы дөнья күрде. Аның үзенең, туганнарының каберләренә куелган истәлекләрнең текстлары һәм фотолары әлеге хезмәттә урын алды. Шулай ук 2019 елда үз хисабыбызга «Эпиграфические памятники Ново-Татарского кладбища Казани: краткий реестр» дип аталган рус телендәге китабыбызны чыгардык. Анда Яңа Татар бистәсе зиратында XX гасыр башына хәтле җирләнгән шәхесләрнең исемлеге, аларның борынгы кабер ташлары хакында мәгълүмат китерелде.

2021 елда А.И. Ногманов төзегән «Ново-Татарское кладбище Казани» китабы нәшер ителде. Каталог рәвешендә эшләнгән хезмәт мәшһүр шәхесләрнең кабер ташларына багышланган. Анда Яңа Татар бистәсе зиратының кыскача тарихы, 720 ташбилгенең фоторәсемнәре, кабер ияләре хакында белешмә һәм зиратның план-схемалары китерелгән. Анда урын алган 50 дән артык шәхеснең кабер ташларын шәхсән үзебез ачыкладык һәм атрибуцияләдек, чөнки әлеге шәхесләр XIX гасырда һәм XX гасыр башында вафат булган һәм ташларының текстлары гарәп графикасында язылган.

Яшел Үзән районының борынгы кабер ташлары тиешле дәрәҗәдә тикшерелмәгәнгә, андагы татар авылларының зиратларында хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча, сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау өчен, 2018 елның яз айларында без С.Хәмидуллин белән берлектә экспедициягә чыктык. Эш барышында 36 авыл (юкка чыкканнарын да кертеп) зиратында 384 борынгы кабер ташы табылды. Иң күп ташъязма истәлек ачыкланган авыл Олы Күлбаш булды (зиратында 41 борынгы ташбилге сакланган). Аннан бераз гына Уразлы саласы калыша: зиратында 36 таш табылды. Олы Җәке авылы зиратында 30 эпиграфик истәлек сакланып калган. Норлат, Чирүчи, Каратмән, Олы Карагужа, Акъегет, Олы Шырдан, Мулла иле, Үтәнгеш салаларында да байтак эпиграфик истәлекләр табылды. Без ачыклаган иң борынгы кабер ташы Казан ханлыгы чорына, 1481 елга карый. Нәтиҗә буларак, 2019 елда «Яшел Үзән районы эпиграфик истәлекләре» дип аталган китабыбыз дөнья күрде. Кайбер ачышларыбыз «История татарских селений Горной стороны» дип аталган коллектив хезмәттә дә урын алды.

2019 елның язында институт тарафыннан Әлмәт, Лениногорск һәм Биектау районнарына фәнни экспедицияләр оештырылды. Әлмәт районының Миңлебай, Кичүчат һәм Тайсуган авылларында - 106, Лениногорск районының Зәй-Каратай һәм Түбән Чыршылы авылларында 77 борынгы ташбилге ачыкланды. Алар турында 2019 елда рус телендә басылган «Татарские селения Юго-Восточного Закамья: очаги просвещения и культуры» коллектив монографиядә язылды. Биектау төбәге зиратларында исә тарихи әһәмияткә ия булган 1100 дән артык эпиграфик истәлек табылды. Бу районда Алтын Урда чорына караган ташбилгеләр Ямаширмә авылында сакланган. Биредә ачыкланган эпиграфик истәлекләрнең тасвирламасын төзү эше тәмамланып килә, тиздән әлеге төбәкнең ташъязмаларына багышланган хезмәт тә дөнья күрер. Сүз уңаеннан, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре В.Усманов, И.Гомәров, А.Ахунов 2019 елда безнең белән бер үк вакытта Биектау районында эпиграфик истәлекләрне барлау белән шөгыльләнде, тик алар, ТР Фәннәр академиясенең 2019 елгы отчетында язылганча, 230 кабер ташы гына ачыклаган.

2021 елда без Актаныш төбәгенә сәфәр кылып, дистәдән артык авыл зиратлары тикшердек, йөздән артык борынгы кабер ташларын ачыкладык. Киләчәктә районның бөтен татар авылларында сакланган ташбилгеләрне өйрәнү һәм аларның каталогын төзү планлаштырыла.

Шулай итеп, институт тарафыннан Казан шәһәрендә һәм Арча, Әтнә, Биектау, Яшел Үзән, Әлмәт, Лениногорск районнарында урнашкан 400 гә якын татар зираты тикшерелеп, 6000 нән артык борынгы кабер ташы өйрәнелде. Эпиграфик материаллар нигезендә ун хезмәт язылды. Вакыт узган саен эпиграфик истәлекләрнең саннары кими бара һәм без табып өйрәнгән ташларның кайберләре берничә елдан соң инде табылмаска мөмкин.

**Айдар ГАЙНЕТДИНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# Айга кырын карама

**Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!**

**16 июль (шимбә).** ***Зөлхиҗҗә аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,22.10 сәгатьтә калка, 7.57 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.57 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

## Петрушка дәвалый

Шешенгәндә, 1 стакан вакланган петрушка сабагы һәм тамырын 2 стакан кайнар суга салып, төнгелеккә калдыралар, иртән сөзеп, 1 лимон согы кушалар да, көненә 5 тапкыр 1әр аш кашыгы эчәләр. 2 көн эчкәч, 2 көн ял итәләр, аннары кабат дәваланалар.

**17 июль (якшәмбе).** ***Зөлхиҗҗә аеның 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,22.20 сәгатьтә калка, 9.26 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.54 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

## Гөлбадран шифасы

Баш авыртканда, буыннар сызлаганда, 2 г гөлбадран чәчәген 1 стакан кайнар суга салып, ярты сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 2-3 тапкыр, ашар алдыннан, чирегешәр стакан эчәләр. Холецистит, фурункулез, салкын тию, нервлар таушалу, туберкулез булганда, 1 аш кашыгы гөлбадран чәчәген термостагы ярты литр кайнар суга салалар, төн буена төнәтәләр, көненә 2-3 тапкыр, ашарга 15-20 минут кала, чирегешәр стакан эчәләр. Гөлбадранлы препаратларны йөкле хатыннарга һәм балаларга кулланырга ярамый.

**18 июль (дүшәмбе).** ***Зөлхиҗҗә аеның 19 нчы көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 22.29 сәгатьтә калка, 10.51 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.51сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

## Күпме сок эчәргә?

Шикәр авыруыннан интегүчеләргә сок белән мавыкмау хәерле. Сау-сәламәт кешегә дә чикләнмәгән күләмдә сок эчү зыянлы. Беренчедән, ул сусауны басмый. Икенчедән, сок куллануның тәүлеклек нормалары бар: нейтраль сокларны (алма, груша, слива) көненә 2 стаканнан (400 грамм), кишер, чия, цитрус сокларын исә көненә 1 стаканнан (200 грамм) артыграк эчәргә ярамый. Кишер согын күп эчкәндә, бета-каротин нормадан арта, тире "саргая". Чия согы ашказанының кислоталылыгын арттыра. Цитрус сокларыннан исә аллергия башланырга мөмкин.

(Дәвамы 18 нче биттә).

## Айга кырын карама

**19 июль (сишәмбе).** ***Зөлхиҗҗә аеның 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,22.37 сәгатьтә калка, 12.12 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.48 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң уңай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

**20 июль (чәршәмбе).** ***Зөлхиҗҗә аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,22.45 сәгатьтә калка, 13.33 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.44 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

### Инҗир – йөрәккә шифа

Инҗирдә калий һәм клетчатка күп, шунлыктан ул эч кипкәндә, канда холестерин микъдары артканда файдалы. Ул ачлык хисен яхшы баса. Инҗирдә тимер алмадагыдан күбрәк, шуңа ул анемиядән интегүчеләр өчен менә дигән дару булып тора. Тахикардия, бронхиаль астма, ютәл, ангинадан дәвалангандa да, инҗир – алыштыргысыз җимеш.

**21 июль (пәнҗешәмбе).** ***Зөлхиҗҗә аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 22.55 сәгатьтә калка, 14.53 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.42 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

### Диатездан – кишер согы

Кишерне юып, уалар, марля аша согын сыгалар (яки сок сыга торган җайланма аша чыгаралар) да, тәндәге диатез тапларына сөртәләр. 2 сәгатьтән соң ук нәтиҗә күренә башлый. Көненә 3-4 тапкыр сөрткәндә, 2 көннән соң диатез бетә. Кишер согы тиредәге аллергиягә бәйле теләсә нинди тапларны дәвалый ала.

**22 июль (җомга).** ***Зөлхиҗҗә аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 23.07 сәгатьтә калка,16.11 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.38 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

### Чия кайнатмасы

Зур савытка 1 стакан су салып, кайнатып чыгаралар. 1 стакан чия, 1 стакан шикәр өстәп, болгаталар, кайнатып чыгаралар. Аннары тагын 1 әр стакан чия белән шикәр салалар. 9 стаканга хәтле шулай эшлиләр, аннары 15 минут кайнаталар, күбеген җыялар. Газны сүндергәч, тагын 4 стакан шикәр кушалар. Болгата-болгата эретеп бетергәч, җылы килеш банкаларга тутыралар. Болай кайнатканда, чия бөрешми.

# Дан яулаган татар

**Казанны күптәннән инде «Россиянең спорт башкаласы» дип йөртәләр. Асылда да спортның һәр төре буенча диярлек бик талантлы спортчыларыбыз бар.**

Футболчы милләттәшебез, якташыбыз Галимҗан Хөсәенов – шундыйларның берсе. Бу исемне өлкән буын вәкилләре яхшы хәтерли. Галимҗан – совет футболында күп илләр гизгән, атказанган Лев Яшин, Анзор Кавазашвили, Виктор Шустиков, Игорь Нетто, Эдуард Стрельцов, Слава Метревили, Михаил Месхи, Виктор Понедельник, Олег Блохин һәм Казанда үсеп чыккан Виктор Колотов белән бергә уйнаган спортчы. Алардан соң дөнья тоткан татар егетләре Ринат Дасаев һәм Вәгыйз Һидиятуллин да СССР җыелма командасында уйнап, дөнья күләмендә танылды.

Галимҗан – республикабызның Норлат районы Яңа Иглай авылында туып-үскән, җанлы һәм әдәпле егет иде. Егерменче гасырда, татарлардан беренче буларак, Олимпия уеннарында бронза медаль алды. Үзе уйный торган Мәскәү «Спартаг»ын да, СССР җыелма командасын да күп тапкыр авыр хәлдән чыгарды.

Г.Хөсәенов кечкенә буйлы иде, нибары 164 сантиметр. Авырлыгы да бәләкәй – 64 килограмм. Менә шушы спортчы дөньядагы иң атаклы футбол капкачыларының котын алып яшәде. «Кечкенә булса да, төш кенә», дип нәкъ аның кебекләр турында әйтәләр. Бу төз сында көчле рух, таза куллар, киң күкрәк, җитез аяклар! Нык кул һәм йөгерек аяк мускуллары балачактан ук туган як җилләре җегәрен сеңдергән. «Көч һәм җитезлек, түземлелек һәм чыдамлык сыйфатлары аңа бала чагында ук йөзү белән мавыгудан килгәндер. Малайлар арасында ук Куйбышев (хәзер Самара) чемпионы исемен ала. Буе кечкенә булса да, баскетболга йөри, җиңел атлетикада көчен сынап карый, – дип яза журналист Мәгъсүм Гәрәев бер мәкаләсендә. – Сәламәт рух әнисе Зәмзәмия апа сабырлыгы аша сеңгән. Калкан күкрәк – әтисе Салих абыйдан, хәрби кешедән. Кыюлык, тәвәккәлек сыйфатлары ягыннан да Галимҗан әтисе ягына тарткан».

Өлкән буын спорт сөючеләр хәтерлидер, ул чорда, сезон тәмамлангач, һәр елнең 11 иң оста футболчысы игълан ителде. Милли чемпионатлар, кубоклар өчен ярышларда, халыкара турнир-очрашуларда алган бәяләр буенча эшләнде бу. Теге яки бу уенчы үзе уйнаган чорда ничә мәртәбә шушы исемлеккә эләккән? Шуларны санныйлар һәм осталар сафында иң күп булганы гасыр командасында үз урынын ала. Бик гади һәм үтә гадел принцип!

Гасыр командасы менә шушы уенчылардан торган: Анзор Кавазашвили, Валентин Афонин, Михаил Фоменко, Виктор Шустиков, Виктор Матвиенко, Валерий Маслов, Галимҗан Хөсәенов, Анатолий Исаев, Валентин Иванов, Эдуард Стрельцов, Эдуард Малофеев. Гасырның җыелма командасы безнең илдә генә төзелгән һәм ул футбол тарихында уникаль вакыйгалардан санала. Үз заманнарының атаклы унбер уенчысы, атказанган спорт остасы исемен алган унбер кеше, соңыннан тренерларның югары мәктәбен тәмамлаган, футбол турында бик тә күп мәгълүматлы унбер шәхес. Мәгъсүм Гәрәев белдергәнчә, алар үз командаларының «баш мие» дә, «йөрәге» дә була ала иде. Һәм уеннары һәм акыллары белән. Алар – футболда классиклар.

Милләттәшебез Галимҗан Хөсәенов «Спартак»та ил күләмендә, СССР җыелма командасында уйнап, халыкара аренада танылды. Һәр ике команданың данга күмелеп йөргән чагы нәкъ менә Хөсәенов дәверенә туры килә.

Г.Хөсәенов 1937 елның 27 июлендә туган. Егерме яше тулган елны ул Куйбышевта гидротехника техникумын тәмамлый. Белеме физика, математика фәннәре белән бәйле. Димәк, егетнең хәтере яхшы. Ул авыр мәсьәләләрне катлаулы формулалар ярдәмендә җиңел юл белән чишәргә өйрәнә.

Техникумны тәмамлауга, Галимҗанны совет футболының иң югары классында уйнаучы «Крылья Советов» (Куйбышев) командасына чакыралар. Икенче эшелон саналган «Б» классында бөтенләй уйнамыйча шундый коллективка эләгү, әлбәттә, зур дәрәҗә була.

«Крылья Советов» Мәскәүдә «Спартак», «Динамо», «Торпедо», «Локомотив», «ЦСКА» кебек атаклы клублар белән очрашканда шул заманның күпне күргән тренерлары яшь уенчы уенына игътибар итми калмый. 1957 елның көзендә Г.Хөсәенов СССР җыелма командасына чакырыла. Әмма ул илнең төп командасында ике тайм уйнарлык дәрәҗәдә булмый әле. Яшел мәйданга унбиш минутка гына чыгып керә, шулай да тренерлар аның уенынын канәгать кала. Аның тырышлыгына, тиз йөгерүенә, кара эштән тартынмавына игътибар итәләр.

Куйбышев белән Мәскәү арасын таптый-таптый өч сезон үтеп китә, «Крылья Советов» өчен кара көннәр килә. 1960 елда ул «А» классыннан төшеп кала. Ә Хөсәеновны «Спартак»ка чакыралар, ул ризалаша, бер үк вакытта илнең җыелма командасында да даими катнаша башлый.

Әдәпле, командашларына игътибарлы булуы, ягымлы сөйләшүе өчен яраталар аны. Җан җылысы бөркелеп тора аннан. «Спартак»ны чемпион һәм кубок иясе иткән уеннарда да Хөсәеновның өлеше зур була. Гадәттә көндәшләре капкасына хәлиткеч тупны ул кертә, яисә иптәшләренә шундый мөмкинлек тудыра. 1965 елда ил кубогы финалында «Спартак» Минск «Динамо»сын 2:1 исәбенә җиңә. Ике тупны да капитан Хөсәенов кертә.

1962, 1963, 1965 һәм 1969 елларда ил күләмендә балкып йөргүче «Спартак» командасын Г.Хөсәеновтан башка күз алдына китереп булмый. Уенчы буларак кына түгел, капитан буларак та Галимҗан гомере буе моның белән горурланып яши. Татарстанның кечкенә генә авылыннан чыккан малай Мәскәү командасын җитәкли, аның җиңүләрен тәэмин итә.

СССР җыелма командасының Европа һәм дөнья күләмендә иң зур казанышлар яулаган чоры узган гасырның алтмышынчы елларына туры килә. Европа кубогын яулап алу, ике тапкыр дөнья чемпионаты финалында катнашу һәм Англиядә бронза медаль алып кайту кебек сөенечле көннәр бар иде безнең. Татар футболчысы Г.Хөсәенов шушы вакыйгаларның үзәгендә кайнады.

1960 елда СССР командасы Испаниядә Европа кубогына ярышлар финалында югославлар белән очрашты. Безнекеләр 2:1 исәбе белән җиңде. Бу совет футболы тарихында Европада беренче тапкыр кубок алуыбыз иде.

Г.Хөсәенов – татар футболчыларыннан ике тапкыр дөнья чемпионаты финалында катнашкан бердәнбер спортчы. Чилида аны (1962 ел) Уругвай командасына каршы уенга чыгаралар. Англиядә (1966 ел) ул барлык уеннарда катнаша. Лондоннан безнең команда дүртенче урын һәм бронза медальләр белән кайта. Шул медальләрнең берсе Галимҗанда иде.

Г.Хөсәенов бала чагыннан бирле чәй яраткан икән. 1967 елда башкалада футбол сезоны ачылуга багышланган турнирда «Спартак» «Динамо» белән уйнаганда «Вечерняя Москва» газетасы редакциясе иң яхшы уенчыга махсус приз рәвешендә самавыр бүләк итәргә була. Ул чорда электр самавырларын табу да җиңел булмый әле. Бөтен сәләтен, көчен биреп тырышып уйный Галимҗан. Стадиондагы 100 мең кеше алдында самавыр аңа тапшырыла.

Галимҗан яшь футболчылар белән эшләргә ярата. Моның җитди сәбәбен дуслары аларның бер генә балалары булуы һәм аның вакытсыз үлемендә күрәләр. Кызлары матур гына үсеп килгәндә гаиләләрендә фаҗига була. Мәктәпкә керәсе елында кызлары тугызынчы кат балконыннан егылып төшеп үлә. Любовь Матвеевна һәм Галимҗан Салих улы бу фаҗигане бик авыр кичерә. Бер атна эчендә яши торган урыннарын һәм фатирдагы җиһазларының һәммәсен алыштыралар. Бу вакыйга Хөсәеновның зур футболдан киткән чорга туры килә һәм ул аның эшчәнлегенә зур йогынты ясый.

Англиядә футбол уенына 100 ел тулу уңаеннан белешмә китап чыгарыла. Ул шушы чорда иң атаклы булган һәм уен үзенчәлекләре белән башкалардан нык аерылып торган футбол талантларына багышлана. Китапта «Нәни гигантлар» дигән бүлек тә бар икән. Анда инглиз Алек Джеймс, Италия клубларында уйнаган аргентин Омар Сивари һәм татар егете Галимҗан Хөсәенов турында язылган. Өчесенең дә буйлары 165 сантиметрдан ким була. Ярым сакчылар булсалар да, капкачылар өчен иң дәһшәтле һөҗүмчеләр булып калалар. Баш белән бәреп уйнауда да гулливерлардан калышмыйлар.

**Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.**

# Бәйрәм дәвам итә...

**Идел буенда ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгы бәйрәме тантаналары бөтен ил буенча бара, кайда фәнни җыеннар, кайда дини-мәдәни чаралар булып дәвам итә. Бу көннәрдә Кукмара районында да шундый чаралар узды. Өркеш авылында «Тарихи вә рухи мирас, халкыбызның гореф-гадәтләре», дигән фәнни-гамәли конференция үтте.**

Җыенда тирә-як авылларның имамнары һәм абыстайлары, районның мөслимәләр берлеге һәм «Ак калфак» оешмасы җитәкчеләре, музей хезмәткәрләре, журналистлар, җирле зыялылар катнашты. Бу фәнни конференциядә төп докладларны галимәләр Фәүзия Бәйрәмова, Резеда Сафиуллина, Ләйлә Алмазова ясады. Җыенда шулай ук Зиннур хәзрәт Сәмигуллин, Өркеш авылының «Фәниябикә» мәдрәсәсе мөдире Фәния Җәләлиева, Кукмара мәдрәсәсе ректоры Ришат Курамшин, мәдрәсә шәкертләре һәм башкалар чыгыш ясады.

Фәния абыстай җитәкчелек иткән бу мәдрәсә аның нәселе нигезендә, Хәбибрахман бабайның оныклары тарафыннан салынган, анда инде егерме елдан артык тирә-күрше авыллардан балалар дини белем ала, җәйләрен мөслимәләр өчен ислам лагере эшли. Ирле-хатынлы Җәләлиевләр тырышлыгы белән, мәдрәсә янәшәсендә өч катлы «Нур» мәчете төзелгән, ул 2016 елны үзенең ишекләрен ача. Рәшит хаҗи элеккеге хәрби табиб, медицина фәннәре кандидаты, Фәния абыстай да табибә. Туган авылларында башкарган игелекле эшләреннән тыш, Рәшит Җәләлиев озак еллар буе Татарстаннан хаҗга баручыларның рәсми табибе була, ә Фәния абыстай бүген дә Казанның «Гадел» мәчетендә әдәп-әхлак дәресләрен укыта, дин темасына китаплар авторы. «Фәниябикә» мәдрәсәсенең бик бай китапханәсе һәм бик матур милли музее да бар, ул бөтен тирә-як өчен мәгърифәт үзәгенә әйләнгән. Фәүзия Бәйрәмова исә сәфәрен дәвам итеп, Рудник бистәсе мәчетендә дә очрашу уздырды, Идел Болгарстанында ислам кабул итүнең 1100 еллыгы турында тәфсилле чыгыш ясады.

Әйе, бу як татар авыллары тарихында фаҗигасе дә, батырлыгы да күп булган. Өркеш авылының тарихы да бик борынгы, ул 1553 елда чукындырудан качып килгән өч татар гаиләсеннән башлана. Пугачев восстаниесендә бу авылдан 200 кеше дин иреге өчен көрәшкә күтәрелә. Бирердән ерак булмаган Пычак авылыннан Пугач явында катнашкан, көчләп чукындыруларга каршы көрәшкән Мәсәгуть Гомәровны җәза отрядлары тотып алып, ат койрыгына тагып, татар авыллары буйлап сөйрәп йөртәләр. Аннары тәне тетелеп беткәнче камчы белән яралар, күзләрен чукып алалар, маңгаена һәм битләренә, утта кыздырып, «вур» тамгасы сугалар, ярым үле хәлдә, сукыр Мәсәгуть Гомәровны Таганрог якларына сөрәләр... Өркештә үткән фәнни җыенда бу милли һәм дини каһарман да зурлап искә алынды, милләтебезнең бәйсезлеге өчен шәһит киткәннәр рухына дога кылынды.

Биредә һәр татар авылында диярлек динебез хакына корбан булган шәхесләр бар. Фәния ханым үзе дә шәһит киткән муллалар нәселеннән, аның әнисе ягыннан Галәветдин бабасын да 1937 елда атып үтерәләр. Ул имамлык иткән мәчетнең манарасын узган гасыр урталарында трактор белән өстерәп төшерәләр, ярымайны Фәния ханымның әбисе Мәсрүрә абыстай яшереп саклап кала. Хәзер ул ай мәдрәсә түбәсендә балкый... Ә теге вакытта мәчетне сүтеп, мәктәп ясыйлар, әмма ул бер ай эчендә яна. Мәчетне җимергән кешеләр озак еллар буе үлә алмый газапланып ята...

Сталин чорында сөргенгә сөрелгән данлыклы Үтәмешевләрнең йортлары һәм мәчетләре бүген дә Мәчкәрәдә саклана, хәзер ул тарихи мәчетне торгызу эшләре бара. Пычак авылы янәшәсендәге Арпаязда исә ерак Австралиядән кайтып, татар хатыны Фатыйма апа үз акчасына мәчет салдырган, аның да кардәш-ыруларын заманында Себергә сөреп, юк иткән булалар...

Кукмара төбәге – Казан артындагы иң дини һәм иң тырыш районнардан. Монда Кукмара мәдрәсәсенең дә роле гаять зур. Районда 72 мәхәлләнең иллесендә шушы мәдрәсәне тәмамлаган имамнар эшли. Шунысын да әйтергә кирәк, бу мәдрәсәдә тирә-күрше районнардан да күп укыйлар, чөнки ул бу төбәктә бердәнбер лицензияле, кануни мәдрәсә. Ф. Бәйрәмова мәдрәсә шәкертләренә татар тарихы, бирәк тә төбәк тарихы да укытылсын иде, динебез һәм ирегебез өчен көрәшкән каһарман шәхесләребезне алар да белсен иде, болар турында китаплар язылсын иде, вәгазьләрендә бу шәһитләрнең дә исеме телгә алынсын һәм рухларына дога кылынсын иде, дигән теләкләрен җиткерде.

**«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.**

# Тел фаҗигасе

Татарстанда рус телен саклау һәм үстерү өчен аерым комиссия төзелүне, татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе үзгәртелеп, хәзер ул татар телен генә түгел, Татарстанда яшәүче барлык халыкларның туган телләрен саклау һәм үстерү белән шөгыльләнәчәк икән дип аңладым. Татарстан Конституциясе буенча, республиканың дәүләт теле булуга карамастан, татар теле республикада яшәүче башка халыклар телләре белән бер дәрәҗәдә калдырылуын ничек аңларга? Бусы тагын нинди адәм көлкесе икән?

Туган телне мәсхәрә иткән фәрманның кем тарафыннан тәкъдим ителүе турында әйтелмәгән һәм ул серле рәвештә генә кабул ителгәнгә охшап тора. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясен Премьер-министр Алексей Песошин җитәкләячәк. Аның урынбасары, гомумән, бу комиссия составында 36 кеше булуы турында әйтелгән. Монысы тагын нинди могҗиза була инде? Бу кадәр күп кешедән торган комиссия әгъзалары ул рус телен тагын да ничек итеп үстерә алырлар икән? Рус теленә карата бер яктан да бетү куркынычы янамый бит, югыйсә. Аның болай да дөньяда иң алга киткән телләр арасында булуы белән горурланып язып торалар бит.

Россиядә рус булмаган башка халыкларның телләрен бетерүгә багышланган законнар эшләп торганда, телләрне үстерү буенча (үзгәртелгән) комиссиянең бу халыклар телләрен ни рәвешле үстерә алачагы турында әйтелмәгән. Ул телләрне үстерү кирәк булгач, телләрне бетерүгә багышлап, мәктәпләрдә ана телендә укуларны тыюлар нигә кирәк булды икән? Шуның кебек баш катыра торган сәерлекләр бик күп монда. Конституция буенча, Татарстанда татар теле дәүләт теле булуы турындагы закон гамәлдән чыгарылмаган вакытта, безнең туган телебезнең шул дәрәҗәдә кыерсытылуы сәбәпле, тагын да зур фаҗигаләр китереп чыгармасмы дип уйландыра.

Бездә яшәүче башка халыкларның телләре, аларның үз илләрендә саклана. Безнең телебезнең башка җирдә саклану мөмкинлеге юк. Шулай булгач, үз телебезне үзебезнең илдә саклый алмасак, телебез юкка чыгу алдында калачак. Ул вакытта үз телебезне өйрәнү өчен Финляндиягә яки башка илләргә барырга туры килмәгәе безгә.

Телне саклау комиссиясенең булдырылуы кеше башын бутар өчен уйлап чыгарылган шикле гамәл икәне алдан ук күренеп торды бит инде. Бу комиссия рәисенең никадәр булдыклы, тырыш кеше булуына карамастан, телне саклап калуга багышланган мөмкинчелеге юк иде. Ана телен балаларга мәктәпләрдә укытканда гына, саклап калу мөмкинлеге тудырылачагы, аңлашылмаслык әйбер түгел. Телне саклап калуны кирәк дип санасак, мәктәпләрдә элеккеге милли телдә уку системасын кире кайтару кирәк безгә. Шулай булганда гына, өмет уяначак.

Ә бу үзгәртелгән комиссия дигәннәре телне саклап калу өчен түгел, киресенчә, телне бетерү өчен эшләнгәне, фикерли белгән кешегә аңлашылмаслык түгел.

Хәзерге вакытта барган фаҗигале хәлләр дә күрше илдә рус халкының теле кыерсытылу сәбәпле килеп чыкты түгелме? Шулай булгач, үзебезнең илдә яшәүче рус булмаган милләтләрнең телләре кыерсытылуын ничек аңларга? Илдә яшәүче халыкны сортларга бүлеп, мәктәпләрдә балаларга үз ана телендә укуларның тыелуы гадел булмаган ният белән, халыклар арасындагы татулыкны бетерү өчен эшләнә кебек күренә?

**Рәфкать ИБРАҺИМОВ.**
Казан.

## Спрайтмы, сумы?

Розалар бүләк иткәнне бөтен кеше ярата. Әмма алар бик тиз сула. Чәчәк гомерен озайту буенча киңәшләр бик күп. Интернетта It’s Maxim исеме белән танылган видеоблогер шул киңәшләрне тикшереп караган. Сынау 9 көнгә сузылган. Марганцовка, май һәм чәйгә куелган чәчкәләр 12 сәгать эчендә сулган. Аракы белән шампан шәрабенә утыртылганнары бер тәүлек торган. Содалы суга куелган розаның икенче тәүлектә сабагы һәм яфраклары каралып ук чыккан. Аспиринлы судагысы дүртенче көнне шиңгән. Гади суга утыртылып, көн саен сабагын кыскартып торганы да бишенче көнне сулган. Чәчәк кибетендә сатыла торган махсус препаратка һәм ... спрайтка утыртылган розалар исә тугыз көнгә чыдаган! Әмма иң кызыгы шунда: гади суга чәчәге капланганчы чумырып куелган роза унынчы көнне генә ямьсезләнә башлаган. Видеоблогер сынавының нәтиҗәсе мондый: чәчкә гомерен озайту өчен, аны тулысынча суга батырып куярга кирәк икән.

(“Интересно.cc”).

## Эштәге төш ...татлырак

Финляндиядә гадәти булмаган “традиция” модага кергән – эш көне уртасында йоклау. Иң рәхәте шул: мондый ял өчен җитәкче ачуланмый, чөнки йоклап алганнан соң хезмәткәрнең эшкә сәләтлелеге һәм нәтиҗәлелелеге арта гына. Ярты сәгать кенә булса да, бу йокы кешегә рәхәтләнеп ял итәргә җитә. Махсус инструктор кирәкмәгән уйлардан арынырга һәм тиз арада йокыга китәргә өйрәтә. Кайбер оешмаларда көндезге ял өчен аерым кабинет җиһазлана. Башка һөнәр ияләре кебек үк, йоклатучы инспектор да хезмәт хакы ала һәм, Финляндиядә тормыш дәрәҗәсенең никадәр югары булуын исәпкә алганда, шактый күп акча эшли. Релакс чараларын оештыру белән Sofia Future Farm компаниясе шөгыльләнә.

(“Die Presse”).

## Бәрәкәтле булган

Хәзер акчаның бәрәкәте юк, дип зарланырга яратабыз, бер тапкыр кибеткә кереп ризык алганда бер-ике мең сумның беткәнен сизми дә каласың. Үткән гасыр акчаларын сагынып сөйләүчеләр күп. 1961 елда әйләнешкә кертелгән 1 сумга, мәсәлән, телефон-автоматтан 50 тапкыр шылтыратырга, ашханәдә туйганчы ашарга, 4 кирпеч ак ипи, 100 кап шырпы, 10 стакан туңдырма, 5 литр сөт, 8 кап “Памир” тәмәкесе, җәй азагында 6 килограмм карбыз яки 3 килограмм кавын, 33 стакан лимонад сатып алырга, көндезге сеанска 20 тапкыр кинога барырга, 5 тапкыр чәч кистерергә яки мунчада юынырга, 20 тапкыр троллейбуста йөрергә мөмкин булган. 3 сум яхшы китап яки курчак сатып алырга, 5-6 кешегә ашханәдә яки бер кешегә ресторанда рәхәтләнеп сыйланырга җиткән. 5 сумга базардан 1кило, кибеттән 2 кило ит, кабымлыгы белән 1 шешә аракы, 1 кило бик яхшы кәнфит сатып алырга, 1 айга фатир өчен түләргә мөмкин булган. Ленинградтан Мәскәүгә самолет бәясе 18 сум торган. 50 сумга велосипед сатып алып булган, айлык иң аз пенсия һәм уку алдынгыларына стипендия шулкадәр түләнгән. 100 сум исә – бик яхшы пенсия, югары уку йорты тәмамлаган инженерның айлык хезмәт хакы. Бу акчага көньякка самолетта барып кайтырга мөмкин булган. Профсоюз юлламасы белән Эльбрус итәгендә 2 атна ял итү нибары 30 сумга төшкән.

(“Лента.ру”).

## Яшелчә акыл өсти

Яшелчәләрнең кеше организмы өчен гаять сихәтле булуы һәркемгә мәгълүм. Чикаго университеты профессоры Марио Моррис тикшеренүләре исә түтәлдән табынга менгән яшел дусларның тагын бер файдалы үзлеген ачкан. Галим 5 ел дәвамында 65 яшьтән өлкәнрәк ир һәм хатыннарның туклану рационын, төрле ризыкның сәламәтлеккә тәэсирен өйрәнгән. Яшелчәләр өлкән яшьтәгеләрнең хәлен яхшыртып кына калмый, бәлки акыл ачыклыгын да озаграк сакларга булыша икән. Тикшеренүче күзәткән төркемдәгеләр көненә 3 тапкыр яшелчә ашаган. Көненә 1 тапкыр гына яшелчә кулланучылар белән чагыштырганда, алар интеллектының 40 процентка акрынрак начарлануы ачыкланган. Моррис фикеренчә, түтәлдә үскән сихәтчеләр акылның тулы куәткә эшләү чорын уртача 5 елга озынайта, бигрәк тә салат кебек яфраклы яшелчәләр файдалы икән.

(“The Local”).

## Ашыкма! Ләззәтлән!

Икигай – үзеңнең язмышыңны кабул итүне аңлата торган япон төшенчәсе. Әлеге тормыш фәлсәфәсе үзенең йөзьяшәрләре белән дан тоткан Окинава утравында барлыкка килгән. “Икигай: озак һәм бәхетле яшәү серләре” китабы авторлары Эктор Гарсия һәм Франсеск Миральес, Окинавада булып кайткач, берничә кагыйдә чыгарган. Беренчесе: мөмкин кадәр күбрәк вакытны табигатьтә үткәрү зарур – Окинавада һәркемнең диярлек яшелчә бакчасы бар, үзләренә кирәкле бөтен яшелчәне диярлек алар үзләре үстерә. Икенчесе: беркайчан да туйганчы ашарга ярамый, 80 процентка кына тукланырга кирәк. Японнар иң кечкенә тәлинкәләрдән ашый, ризыкларының 30 процентын яшелчә һәм җиләк-җимеш тәшкил итә. Диңгез кәбестәсе, батат, суган, соя, дөге, яшел чәй – яраткан ризыклары. Баллы тәм-томны өнәмиләр. Икигай фәлсәфәсе кешенең картайгач та актив булуын таләп итә. Окинавада яшәүчеләр беркайчан һәм беркая да ашыкмый, стресслардан саклана, тормышның һәр мизгеленнән ләззәт алып яшәргә омтыла.

(“Daily Mail”).

## Урманлы һәм шугалаклы кораб

***Symphony of the Seas (инглизчәдән “Диңгез симфониясе” дип тәрҗемә ителә) – Royal Caribbean International компаниясенең Oasis классындагы круиз корабы – дөньяда иң зур пассажир судносы. Ул Франциянең Сен-Назер шәһәрендәге верфьтә ясалган һәм 2018 елдан бирле суда. Озынлыгы 361 метрлы, 18 палубалы кораб 5518 пассажирны сыйдыра, 2200 кешелек экипаж әлеге исәпкә керми. Анда барлыгы 22 ресторан, 24 бассейн, 2769 каюта, аквапарк, баскетбол мәйданчыгы, шугалак, 20 мең төрле тропик үсемлек үскән парк бар. Беренче круизы Урта диңгез буйлап булган. Хәзер Майами портында тора һәм пассажирларны Кариб диңгезе буйлап круизда йөртә.***

**(“Fishki.net”).**

*Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.*

## Дүшәмбе

### 18 июль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00, 22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Ком сәгате». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
23.50, 0.40 «Семь дней+». 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Шаян хәлләр». 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Нәҗибә Ихсанова турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
20.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+

### «ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Битва коалиций. Вторая Мировая война». 12+
16.15 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 0.50 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Соломон Волков. Диалоги с Евгением Евтушенко». 12+

### «РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «Славянский базар в Витебске».

### «КУЛЬТУРА»

6.30 «СУЕТА СУЕТ».
8.00, 19.15 «Забытое ремесло».
8.15 Легенды мирового кино.
8.45 «ГОСТИНАЯ, СПАЛЬНЯ, ВАННАЯ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Андрей Воронихин. Казанский собор.
10.45 Academia. Валерия Мухина. «Человек на пересечении созданных им реалий».
11.30 К 65-летию Павла Любимцева. Линия жизни.
12.25 Моя любовь - Россия! «Пронзительная мелодия для курая».
12.55, 21.30 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
14.10, 23.35 «Разочарованный Аракчеев».
15.05, 22.45 «Мост над бездной. Джотто. «Поцелуй Иуды».
15.35 Мастер-класс. Давид Герингас.
16.30 Спектакли-легенды. Е.Лебедев, К.Лавров, О.Басилашвили в постановке Г.Товстоногова «Дядя Ваня».
19.45 «Сергий Радонежский. Путь подвижника».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 90 лет со дня рождения Евгения Евтушенко. Линия жизни.

### «НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

## Сишәмбе

### 19 июль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00, 22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Без химии». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+
0.15 «Соотечественники». 12+
0.40 «Каравай». 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Родная земля». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Мансур Гыйләҗев турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+

### «ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Нулевая Мировая». 12+
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Соломон Волков. Диалоги с Евгением Евтушенко». 12+

### «РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 Торжественная церемония закрытия фестиваля «Славянский базар в Витебске».

### «КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Кукса - владетель мира».
7.30 «Лунные скитальцы».
8.15 Легенды мирового кино. Кэри Грант.
8.45 «УДИВИТЕЛЬНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ».
9.50 Цвет времени. Марк Шагал.
10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Александр Кокоринов. Академия художеств.
10.45 Academia. Валерия Мухина. «Человек на пересечении созданных им реалий».
11.30, 20.30 Абсолютный слух.
12.15 Моя любовь - Россия! «Русская народная игрушка».
12.50, 21.30 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
14.05 «Забытое ремесло».
14.20, 23.35 «Бенкендорф. О бедном жандарме замолвите слово...»
15.05, 22.45 «Мост над бездной. Иероним Босх. «Корабль дураков».
15.35 Мастер-класс. И-Пинь Янг.
16.30 Спектакли-легенды. А.Ширвиндт, В.Васильева, А.Миронов в постановке В.Плучека «Безумный день, или Женитьба Фигаро».
19.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Первые в мире».

### «НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

## Чәршәмбе

### 20 июль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

Телевизор караучылар игътибарына! Чәршәмбе, 20 июль, профилактика чаралары үткәрү сәбәпле, «ТНВ» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында 2.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр тапшырулар трансляцияләнми.
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00, 22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Без химии». 12+
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
9.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рестәм Маликов турында телеочерк. 6+
13.00 «Манзара». 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+

### «ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Нулевая Мировая». 12+
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Соломон Волков. Диалоги с Евгением Евтушенко». 12+

### «РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «Иван Зубков. Спаситель Ленинграда». 12+

### «КУЛЬТУРА»

10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Франческо Фонтана, Иоганн Готфрид Шедель, Жан-Батист Леблон. Меншиковский дворец.
10.45 Academia. Юрий Александров. «Мозг и культура».
11.30, 20.30 Абсолютный слух.
12.15 Моя любовь - Россия! «Ростовский Кремль как вершина древнерусской культуры».
12.50, 21.30 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
14.00 «Забытое ремесло».
14.20, 23.35 «Игнатий Стеллецкий. Тайна подземных палат».
15.05, 22.45 «Мост над бездной. Казимир Малевич».
15.35 Мастер-класс. Михаил Дзюдзе, Фридрих Липс, Александр Цыганков.
16.15 Цвет времени. Николай Ге.
16.25 Спектакли-легенды. М.Ульянов, В.Лановой, Ю.Борисова, Е.Добронравова в постановке Е.Симонова «Антоний и Клеопатра».
18.50 «Андреевский крест».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Первые в мире».

### «НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

## Пәнҗешәмбе

### 21 июль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 Прямая трансляция литургии из Казанского собора Богородицкого монастыря в честь праздника обретения Казанской иконы Божией Матери.
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45, 0.40 «Каравай». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
17.00 «Биляр. Кладовая наследия». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.50 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Аулак өйгә дәшкән егет». Айдар Фәйзрахманов турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

### «ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Нулевая Мировая». 12+

16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

### «РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «Чёрное и белое торпедовца Стрельцова». 12+

### «КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Наследство для Екатерины».
7.30 «Pгоневесомость».
8.15 Легенды мирового кино.
8.45 «ПОКА ПЛЫВУТ ОБЛАКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Павел Сюзор. Дом компании «Зингер».
10.45 Academia. Юрий Александров. «Мозг и культура».
11.30, 20.30 Абсолютный слух.
12.15 Моя любовь - Россия! «Хороводы северной Ижмы».
12.50, 21.30 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
14.00 Дороги старых мастеров. «Мстёрские голландцы».
14.10, 23.35 «Парадокс Грибоедова».
15.05, 22.45 «Мост над бездной. Ренуар-Ярошенко».
15.35 Мастер-класс. Ильдар Абдразаков.
16.30 Спектакли-легенды. Г.Жженов, Н.Дробышева, В.Талызина, Г.Бортников в постановке Р.Виктюка «Вечерний свет».
19.00 «Казань. Дом Зинаиды Ушковой».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Первые в мире».

### «НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

## Җомга

### 22 июль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». 6+
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00 Телефильм. 12+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
23.00 «АМЕРИКАНЕЦ». 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Садри Максуди һәм Әхмәтһади Максуди турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

### «ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ВСЕ ПУТЕМ». 16+
14.45 «Наша марка 2». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Нулевая Мировая». 12+
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
23.25 К 60-летию Романа Мадянова. «С купеческим размахом». 12+

### «РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «СТРЕЛЬЦОВ». 6+
23.20 «СТИЛЯГИ». 16+

### «КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Преступление и покаяние».
7.30 «Молнии рождаются на земле. Телевизионная система «Орбита».
8.15 Легенды мирового кино. Фрэнк Синатра.
8.45, 23.35 «ПОКА ПЛЫВУТ ОБЛАКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Андрей Михайлов, Ипполит Монигетти, Андрей Белобородов. Юсуповский дворец.
10.45 Academia. Алексей Осипов. «Оценка теории эволюции».
11.30 Абсолютный слух.
12.15 Моя любовь - Россия! «Нижегородские красавицы».
12.45, 21.00 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
15.05 «Врубель».
15.35 Мастер-класс. Дмитрий Алексеев.
16.30 Спектакли-легенды. А.Степанова, О.Стриженов, И.Мирошниченко в постановке Б.Ливанова «Чайка».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Искатели. «Загадка дома с грифонами».

### «НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ». 16+
22.30 «Возвращение легенды». Юбилейный концерт группы «Земляне». 12+

## Шимбә

### 23 июль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Синең Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары» концерты.
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 Зөфәр Харисовның юбилей кичәсе. 6+
15.30 «Үткәннәрне барлар...» Айдар Фәйзрахманов. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Ватандашлар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «ДЕТКИ НАПРОКАТ». 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Фоат Әхмәтҗанов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Синең Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Спектакль «Нәзер». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Гомер бик сизгер икән». Ринат Мөслимов җырларыннан концерт. 12+

### «ЭФИР»
5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30, 0.40 «Вместе по России». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Спасите, я не умею готовить!» 12+
8.45 «ОПАСНОЕ ЗАБЛУЖДЕНИЕ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЕКАРЬ: УЧЕНИК АВИЦЕННЫ». 12+
15.30 «Инвиво». 12+
16.00 «Еда. Правильное питание». 12+
16.30 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БОЛЬШАЯ АФЕРА». 16+
23.00 «СВЕТ И ТЕНЬ». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «Сергий Радонежский. Заступник Руси». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.25, 15.15 «ПИРАТЫ ХХ ВЕКА». 12+
16.20 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ПРОРЫВ». 12+
18.20 «На самом деле». 16+
19.25 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «КРАСОТКА В УДАРЕ». 16+

### «РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «КРОВНАЯ МЕСТЬ». 12+

### «КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.35 «ПРЕМЬЕРА В СОСНОВКЕ».
9.50 «Обыкновенный концерт».
10.15 «Передвижники. Иван Крамской».
10.45, 21.25 «ОШИБКА ТОНИ ВЕНДИСА».
12.55 «Узбекистан. Сплетение солнечных культур».
13.25 Диалоги о животных.
14.05 «Дом ученых». Дмитрий Иванов.
14.35 Легендарные спектакли Большого. Наталья Бессмертнова и Михаил Лавровский в балете «Ромео и Джульетта».
16.55 «Михаил Лавровский. Продолжение следует...»
17.45 «Энциклопедия загадок».
18.15 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА».
19.45 «Приключения Аристотеля в Москве».
20.30 К 100-летию российского джаза. Линия жизни. Анатолий Кролл.
23.35 «Вспоминая Эллу Фицджеральд». Оркестр имени Олега Лундстрема.

### «НТВ»
5.00 «Кто в доме хозяин?» 12+
5.35 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ». 16+
22.15 «Маска». 12+

## Якшәмбе

### 24 июль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Сагынырлык булсын...» Марат Кәбировның иҗат кичәсе. 6+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Без». 6+
12.00, 19.00 «Каравай». 6+
12.30 «Мәңгелектән исә җил». Ләис Зөлкәрнәйнең юбилей кичәсе. 6+
14.30 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.30 «Әдәби хәзинә». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Республиканский конкурс красоты Мини Мисс Татарстан». 6+
23.00 «РУД И СЭМ». 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Татар халык көйләре». Рамил Курамшин. 6+
7.00 «Җырым булсын бүләгем». Гали Ильясов җырлый. 6+
7.25 Спектакль «Ташкын». 12+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Сәҗидә Сөләйманова турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Яшәү- мизгел». Нәфкать Нигъмәтуллин концерты. 6+
15.20 Спектакль «Сихерче». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Акча корты». «Мунча ташы» спектакле. 12+
22.50 «Йөрәктән-йөрәккә». Фоат Әхмәтҗанов турында телеочерк. 6+

### «ЭФИР»
5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Инвиво». 12+
8.30 «Прокуроры 5. Без срока давности. СВОИ среди чужих». 16+
9.30 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БОЛЬШАЯ АФЕРА». 16+
15.00 «Удиви меня». 12+
15.45 «ОПАСНОЕ ЗАБЛУЖДЕНИЕ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛЕКАРЬ: УЧЕНИК АВИЦЕННЫ». 12+
23.30 «НЕ СТУЧИ ДВАЖДЫ». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»
5.05, 6.10 «ОТЧАЯННЫЕ». 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Ирина Мирошниченко. «Я знаю, что такое любовь». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
13.50, 15.15, 18.20 «Краткое пособие по тому, как устроен мир». 16+
19.00 «Леонид Кравчук. Повесть о щиром коммунисте». 16+
19.55 «Парни «с Квартала». 16+
21.00 «Время».
22.35 «ЭТО СЛАДКОЕ СЛОВО - СВОБОДА!» 12+

### «РОССИЯ»
5.35 «ЛЕТОМ Я ПРЕДПОЧИТАЮ СВАДЬБУ». 16+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

### «КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 «Василиса Прекрасная».
7.25, 23.35 «ДОЖДЬ В ЧУЖОМ ГОРОДЕ».
9.35 «Обыкновенный концерт».
10.05 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА».
11.40 Диалоги о животных.
12.20 «Коллекция».
12.50 Концерт оркестра народных инструментов им. Н.П. Осипова.
14.20 «Волга-Волга». Была бы песня!»
15.00 «ВОЛГА-ВОЛГА».
16.45 «Наедине с мечтой. Федор Конюхов».
17.25 «Секреты виртуального портного».
18.05 «Монастыри».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Юбилей Ирины Мирошниченко. Линия жизни.
20.25 «НЕ СОШЛИСЬ ХАРАКТЕРАМИ».
21.45 Большая опера- 2016 г.

### «НТВ»
5.00 «Кто в доме хозяин?» 12+
5.35 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.50 «ПЕНСИЛЬВАНИЯ». 16+
21.40 «Ты не поверишь!» 16+
22.25 «Маска». 12+

**Газиз Гобәйдуллин - татар тарихында тирән эз калдырган шәхесебез. Ул беренче профессиональ татар тарихчысы, профессоры. Казанда Шәрекъ академиясен нигезләүчеләрнең берсе буларак билгеле. Г.Гобәйдуллин - Казан университетының татар һәм филология факультетын тәмамлаган, аспирантурада белем алган галим. Быел халкыбыз татар тарихы буенча беренче булып диссертация яклаган галим Газиз Гобәйдуллинның тууына 135 ел тулуны билгеләп үтте. Шушы уңайдан Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтында төбәкара фәнни-гамәли конференция узды.**

# Татарның беренче профессоры

Күп санлы йортлар хуҗасы, сәүдәгәр Салих Гобәйдуллин гаиләсендә дөньяга килгән Газиз белем алуын Казанның Зәңгәр мәчете каршындагы «Халидия» мәдрәсәсендә башлап җибәрә, аннары грек, немец, француз, латин телләрен өйрәнеп, гимназия буенча өлгергәнлек имтиханнарын тапшырып, Казан университетының юридик факультетына укырга керә, әмма бер елдан, тарих-филология факультетына күчеп, М.Хвостов, Н.Катанов, Н.Фирсов кебек күренекле галимнәр җитәкчелегендә эшли.

Газиз Гобәйдуллин - киңкырлы тарихчы. Белгәнебезчә, революциягә кадәр заманнарда татар тарихына кагылышлы күп мәсьәләләр тикшерелмәгән була. Г.Гобәйдуллинның язмалары бик күпләр өчен яңалык буларак кабул ителгәннәр. «Мәкаләләреннән Г.Гобәйдуллинның тарихыбызга, әдәбиятыбызга кагылышлы мәсьәләләрне, шул ук вакытта укыту системасын һәм аның проблемаларын да яхшы белүен дә күрәбез», - ди филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университет доценты Диләрә Галиуллина. Галимне Алтын Урда, милләт, телләр, татарларда сыйныфлар тарихы мәсьәләләре кебек темалар аеруча кызыксындыра. Аның революциягә кадәрге татар халкы тарихы турында студент чагында ук язылган хезмәтләре дә хәтсез. Һади Атласи исемендәге иҗтимагый фонд җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Алсу Мөхәммәтдинова Г.Гобәйдуллин 1915 елда Ш.Мәрҗанинең 100 еллыгына багышлап җыентык әзерләвен, аны чыгаруга шулкадәр ихластан алынуын, һәр фактны, истәлекләрне бөртекләп җыюын да искә төшерде.

Галимнең күп мәкаләләре революциядән соң язылган. «Аның «Емельян Пугачев явында һәм Степан Разин явында татарларның катнашуы турында» бик саллы мәкаләләре бар. Ул анда кызыклы нәтиҗәләргә килә», - диде Д.Галиуллина. Галимнең эшчәнлегенең бер юнәлеше җәдидчелеккә багышланган. Бу уңайдан аның Исмәгыйль Гаспралы турында өйрәнеп язылган хезмәтләре игътибарны җәлеп итә. «Исмаил Гаспринский и язык» дигән мәкалә кульязма хәлендә безнең көннәргә кадәр сакланган. Ул 1990 елларда гына басылып чыккан. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Эльмира Сәлахова Газиз Гобәйдуллинның тел турында әйткән фикерләре бүген дә актуаль икәнлеге турында сөйләде.

Бу галимнең алдан күрүчәнлеген, акыллы, зирәк кеше икәнлеген дә күрсәтә. Г.Гобәйдуллин 1921 елда аспирантураны да тәмамларга өлгерә. Бу елларда ул университетның Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә хакыйкый әгъза итеп тә сайлана. Шул елларда галим фән өлкәсендә гомуми тарих, диннәр тарихы, татар тарихы, татар әдәбияты һәм мәдәнияте, иҗтимагый фикер үсеше тарихына караган хезмәтләрен, дәреслек китапларын язып бастыра.

Газиз Гобәйдуллин студент чагында ук, ягъни 1914 елдан хакимиятләр рөхсәтеннән башка гына «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих укыта башлый. Галим, 1916 елда университетны беренче дәрәҗәле диплом белән тәмамласа да, патша Россиясендә татар милләтеннән булган белгечкә эш урыны табылмый. Егет губернатор тәкъдиме белән Троицкига китәргә мәҗбүр була, биш классы «Вазифа» мәдрәсәсенең мөдире булып эшли,1922-1925 елларда Казанда Шәрекъ педагогика институтында укыта, шул ук вакытта ТАССРның гыйльми үзәк хезмәткәре була.

Газиз Гобәйдуллин әдәбият сөючеләр арасында язучы буларак та танылып өлгерә. Аның беренче хикәясе 1907 елда ук дөнья күрә. Галимнәр 1913-1917 елларда аның каләме аша туган әсәрләр көндәлек матбугатта аеруча күп очравын әйтә.

Газиз Гобәйдуллин 1925 елда Казанны ташлап Бакуга китә. Галимнәр моның төгәл сәбәбен белми, аның гаиләсенә карата эзәрлекләү башлануы белән аңлаталар. Ихтимал, моңа, ул чорга хас булганча, тарихчы галимнең сыйнфый чыгышы да сәбәп булгандыр. Галимне Баку университетының Шәрекъ факультетына приват-доцент итеп эшкә алалар, ул шул ук вакытта Бакуның педагогика институтында да студентларга белем бирә, аны декан итеп билгелиләр, ике елдан Г.Гобәйдуллинны университетның төрки халыклар тарихы буенча профессор итеп раслыйлар. Бу - Россия шартларында татарлар арасында профессор дәрәҗәсе алган беренче очрак. Г.Гобәйдуллин 1928 Сәмәрканд, 1930 елдан Мәскәү университетларының штаттан тыш профессоры да була. Үзбәкстан Фәннәр академиясенең тарих институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Р.Шигабдинов чыгышында ассызыкланганча, тарихчы галим әледән-әле Мәскәүгә, Сәмәркандка, Ташкентка барып лекцияләр укып, семинарлар, курслар үткәреп кайта, рус, әзәрбайҗан, үзбәк телләрендә фәнни хезмәтләрен бастыра, конференцияләрдә, симпозиумнарда чыгышлар ясый. «Хатларына караганда, аның бик Казанга кайтасы килә. Их, кайтасы иде, дип яза», – дип искә төшерде Д.Галиуллина.

● Сулдан уңга: Кашшаф Тәрҗемани, Габдулла Гыйсмәти, Салих Гобәйдуллин, Газиз Гобәйдуллин, Шәһәр Шәрәф, Таһир Ильясов, Габдрахман Гомәров.

Г.Гобәйдуллин 1930 еллар башыннан әкренләп үзенә мөнәсәбәтнең үзгәргәнен сизә башлый. Аның мәкаләләрен дә басмый башлыйлар. Көндәлек матбугатта галимне гаепләгән язмалар да күренгәли. Билгеле ки, Г.Гобәйдуллин барысын да аңлап ала. Д.Галиуллина тарихчы галимнең Мәскәүдә яшәүче улы Сәлман Гобәйдуллин исән чагында аның белән хатлар алышкан. Ул әтисенең үзен кулга алачакларын белеп торуы турында яза. Сәлман әфәнде истәлекләрендә язып калдырганча, ишек төбендә әзер котомка басып торган, киемнәр дә әзерләп куелган булган. Галимнең фаразы дөрес булып чыга, аны 1937 елның язында Әзәрбайҗан Фәннәр академиясенең бер төркем галимнәре белән бергә кулга алалар, ә бер елдан ул ГУЛАГ зинданында һәлак була. Газиз Гобәйдуллин улына китапханәсен Баку университетына бирергә куша. Улы әтисенең әманәтен үти. Шуңа күрә галимнең китапханәсе пыран-заран килми, сакланып кала. Алсу Мөхәммәтдинова Газиз Гобәйдуллинның Һади Атласи белән дә язышып, хәбәрләшеп торуы турында сөйләде. Әмма, кызганыч ки, бу хатлар югалган, эзләп-эзләп тә табылмаган.

Г.Гобәйдуллинның Иске Минзәләбаш мәдрәсәсендә укытуы турында филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Яхиннның искә алуы исә гыйльми җыенда катнашучы галимнәр өчен зур яңалык булды. Аңлашыла ки, бу – архив документлары белән расланмаган факт. Ф.Яхин моны Газиз Салих улының «Шура» журналында «Минзәләбаши» дигән исем белән шигыре басылуын һәм якташларының истәлекләренә нигезләнеп әйтә. Бу инде тарихчыларыбыз тарафыннан олуг галимебезнең биографиясе дә, хезмәтләре дә, иҗаты да начар өйрәнелүе турында сөйли. Башка халыкларда патша Россиясе заманнарында ук Г.Гобәйдуллин кебек шәхесләр булса, аның тормышын, эшчәнлеген энәсеннән җебенә кадәр тикшереп калын-калын хезмәтләр язарлар, мәктәпләрдә, фәнни оешмаларда аңа багышланган киң колачлы конференцияләр уздырылар иде. Ә хәзерге вакытта тарихчы галимебез турында мәктәп балалары бөтенләй хәбәрдар түгел, аны хәтта югары уку йортларында белем алучы яшьләребезнең дә сирәге генә белә. Бу хакта Тарих институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ләлә Мортазина да кереш сүзендә искәртеп үтте.

Газиз Гобәйдуллин туып-үскән йорт Казанның татар бистәсендә сакланып калган. Д.Галиуллина анда мемориаль такта гына эленеп торуын әйтә. Бу - халкыбыз, әдәбиятыбыз тарихларын барлап зур хезмәтләр язган, телебезне кайгырткан галим турында бердәнбер истәлек. Г. Гобәйдуллинның туган җирендә, йортында әлегә кадәр музей да булдырылмаган.

Галимнең барлык хезмәтләрен туплаган җыентыгы турында да кызыксындым. Андый тулы хезмәт тә юк икән. 1989 елда Татарстан китап нәшриятында «Тарихи сәхифәләр ачылганда» дигән сайланма тарихи хезмәтләре, 2002 елда «Рухият»тә галимнең улы С. Гобәйдуллин, Э.Кульпин-Гобәйдуллин, Р.Мәрданов, И.Һадиев туплаган фәнни-биографик җыентык укучылар кулына килеп ирешкән. Гомумән, Г.Газизнең (тәхәллүсе) әдип буларак та өйрәнү генә түгел, барлык әсәрләре тупланган китабы да басылганы юк.

Көндәлек матбугатта төрле елларда З.Буниятовның («12493 номерлы тикшерү эше»), Р.Вәлиевнең («НКВД тоткыны»), С.Гобәйдуллинның («Безнең әтиебез»), галимнәр С.Алишевнең, Э.Галиеваның, Р.Шигабдиновның Д.Галимуллинаның мәкаләләре дөнья күргән.

Алсу Мөхәммәтдинова залдагыларның игътибарын бүген мәктәпләрдә татар тарихы бөтенләй диярлек укытылмавына юнәлтте. Ул Әлмәт районының бер урта мәктәбенең укытучылары белән сөйләшкән, мәсьәләне өйрәнгән. Галимә академик басмаларыбыз, Фәннәр академиясе, Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты, Татарстан мәгарифен үстерү институты булуы, әмма шул ук вакытта балаларыбызның тарихтан белемсез калулары турында ачынып сөйләде. Тарихка кагылышлы дәресләр ел буена күп дигәндә 7-10 сәгатькә туларга мөмкин икән. Әле алар да тулысынча Татарстан тарихына кагылмый. Россиядә рус телен саклау һәм рус тарихын өйрәтү буенча бик гайрәтләнеп эшкә тотынуларын, «Белем җәмгыяте»н дә оештыруларын беләбез. «Әйдәгез, без дә калышмыйк. Мәктәпләрдә төбәкне өйрәнү предметын кертергә кирәк», - ди Алсу ханым. Аннары хәзер мәктәпләр белем бирү сәясәтен үзләре билгели ала. Ә милли җанлы директорлар Татарстаныбызда күп түгел. «Шуңа да рәсми һәм иҗтимагый оешмалар, галим-голәмалар бердәм булып мәсьәләне уртага салып сөйләшик, киңәшмәләр үткәрик, мөрәҗәгать белән чыгыйк. Әгәр битараф булмасак, тәгаен гамәлләр кылсак, кыю адымнар ясасак, милләт файдасына гамәлләр кылып була», – ди А.Мөхәммәтдинова.

Тарих институты директоры урынбасары Марат Гыйбатдинов бүген мәктәпләргә һәм ата-аналарга бик зур мөмкинлекләр бирелүен, һәр уку йортының нинди фәннәргә мәктәп компонентын бирү мәсьәләсен үзе хәл итүен искәртте. Тарихка, аеруча татар тарихына әһәмият биргәннәре аз. Шуңа да урынбасар хәзер балаларына белем бирүдә ата-аналар гына үз сүзен әйтә алуын белдерде. «Ата-аналарга ни өчен балаларга татар тарихы кирәклеген аңлатырга тиешбез. Алар җыелып таләп итсә, мәктәп җавап бирергә тиеш», - диде М.Гыйбатдинов.

**Сөембикә КАШАПОВА.**

Мәдәни җомга
15 июль
№27, 2022



# Казанның нурлы мизгелләре

**12 июль көнне бар дәүләтләрдә дә Фотограф көне бәйрәм ителә. Әлеге бәйрәм 2009 елны Австралия фотографы Корске Ара тарафыннан тәкъдим ителде, 2010 елдан башлап бар дөнья фотографларының иң яхшы хезмәтләре аерым бер халыкара сайтның интерактив онлайн-галереясына да урнаштырылып килә.**

Казан каласы фотографы Луиза Шәмсетдинова белән аның интернеттагы сәхифәсен карап чыккач танышырга булдым. Башкаланы кем генә сурәткә төшерми, ә менә Луизаның фотолары аны шулкадәр дә матур итеп күз алдына китерергә булыша! Моны социаль челтәрләрдә төрле сәхифәләрне алып баручылар да абайлап алды, шунлыктан алар да, күреп алуга ук, Луиза Шәмсетдинованың Казан фотолары белән үз битләрен бизәп куя. «Мин моңа сөенәм генә, – ди фотограф ханым. – Әиң шатландырганы шул – яңа фотосурәтләремне урнаштыру белән үк, миңа без бу атнада Казанга юл тотарга, сезнең эзләр буенча татар башкаласын күреп кайтырга булдык әле дип язалар. Андыйлар шулкадәр күп, әлеге хәбәрләрдән соң күңелем сөенеч белән тула».

Луиза һөнәри фотограф түгел, ул – исәп-хисап дөньясы белгече. Әмма аның бу талантын һәркем мактап телгә ала.

«Нигә блог алып бара башладың, вакытың күп, ахры?» – ди кайберәүләр. Чыннан да, пандемия айларында буш вакытым күбәйде. Мөмкин булгач та, саф һава сулап, урамнар буйлап йөреп кайтырга чыктым. Шул айларда үз блогымны ачтым да инде. Башта сәяхәтләрдә төшергән фотоларымны куйдым. Чөнки мин моңа кадәр беraз чит илләрне күргән идем. Әмма төрле сәфәрләр темасы үз актуальлеген югалтканга күрә, Казанны күпләп фотога төшерә башладым. Кала тарихын көннән-көн күбрәк белә, көннән-көн күбрәк ярата барам, бу ярату хисе башкаларга да фотосурәтләрем аша сизелеп торадыр, мөгаен... Мине күпләр аңлар булыр, блогерларның да куллары салынган чорлары була, илһам килми, вакыт юк, идеяләр аз... Ә менә миңа һәр көн хатлар юллыйлар: кемдер Казанны сагына һәм аның яхшы якка үзгәрүен күреп куана, кемдер нәкъ мин йөргән урыннарны күрергә тели. Ә иң мөһиме, кызганыч булса да, Казан урамнары буйлап үз аякларында йөри алмаучылар бар бит, алар каланы шушы фотоларым аша күзәтә. Шуңа күрә эшем юкка түгел дип уйлыйм, – ди Луиза. – Мин шуны да аңладым: барсын да кәеф белән эшләргә кирәк. Һәм фотоларыңны башкалар фотолары белән чагыштырмаска. Үзеңне бары тик теге яисә бу чордагы үз-үзең белән генә чагыштырырга кирәк. Аудиторияне үзеңә мәҗбүриләп беркетеп куеп булмый. Ул йә бар, йә юк. Таланты булганнар моны белә. Һәр талантлы фотограф та үз тамашачысын таба дип саныйм. Мин инде Казанны да, Казан янындагы бистәләрне дә, Иделне, Казансуны да, тарихи архитектуралы биналарыбызны һәм табигать күренешләрен дә күпләп төшерәм. Алдагы көннәрдә бирегә килүче туристлар өчен шушы фотоларым буенча сувенирлар әзерләргә телим, әйтик, аларны пазлларга бүлепбүлеп тәкъдим итәсем килә. Бәлкем, матур китап итеп тә нәшер итәрмен әле, ә бәлкем, Казанга багышланган шәхси фотокүргәзмәмне дә ачармын дип уйлыйм.

Ни гаҗәп, фотоларга төшерү күңелемне көннән-көн үзенә күбрәк җәлеп итә, ахрысы, миңа инде шушы һөнәргә үк күчәргә вакыттыр...»

Сүз дә юк, Луиза Шәмсетдинованың зәвыгы, үз күзаллавы, сәнгати карашлары, гаҗәеп ракурсларны, кадрларны бик яхшы тоемлавы, барсы да бар, шуңа күрә аның бу планнары да тормышка ашмый калмас. Иң мөһиме, ул инде тәвәккәлләп, кулына фотоаппарат алган. Бу нисбәттән язучы Марк Твен сүзләре дә искә төшә: «Егерме елдан соң сез нәрсә эшләгәнегез өчен түгел, ә нәрсә эшләмәгәнегез өчен үкенәчәксез. Шуңа күрә төеннәрне алып ташлагыз, тын гаваньнардан чыга башлагыз. Җилкәннәрегезне юлдаш җил белән тутырыгыз. Уйланыгыз. Анализлагыз. Хыялланыгыз».

**Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.**

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ**

**«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир**

**Вахит Шәих улы ИМАМОВ**

**Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ**

**Шылтыратыгыз:**

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

**Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)**

**Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды**

**Индекс П2355**

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

**Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:**

**ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124**

**НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ**

**420097, Казан, Академия урамы, 2**

**Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:**
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
**E-mail: m-jomga@mail.ru**

**«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru**

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратыгыз

**Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 15.07.2022**

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2761

16+